# Казан утлары

АПРЕЛЬ

4 1968

# ФОТО 66»

Шушы елның март аенда Казанда бөтендөнья фотокүргәзмәсе (Интерпресс-фото 66) булды. Түбәндә без шул күргәзмәдән берничә эшне тәкъдим итәбез.



Фантастик мандарин.
Ева Келети *(Венгрия)*.

Мәхәббәт.
Джиакомелли Марио *(Италия)*.





Беркатлылык һәм тормыш. Фернанд Хелинкс *(Бельгия)*.



бомбасына протест» фото-очеркыннан.
Кор Яринг *(Нидерландия)*.



Вернер Моженсон *(Дания)*.
карашы.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

4
АПРЕЛЬ
1968

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

С. ХӘКИМ. Таулар, таулар; Татарлар елмаеп үлделәр; Изге бер ут; Дүрт яран; Кайгым төрле чикләр аша узды; Озын чылбыр; Тышта буран; Янып, син кал; Хисап бирәм. Шигырьләр . . . . . . . 3
М. МАЛИКОВА. Казан каласы — таш кала. Повесть . . . . . . . . . . . . .
Н. АРСЛАНОВ. Сагындым; Диңгездә; Көлеп бакса иде; Нигә; Өмет; Айга карап; Уникс батыр турында баллада. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 45
А. АЗИМОВ. Шөкәтсез малай. Фантастик хикәя . . . . . . . . . . . . . 48

НАҖАР НӘҖМИГӘ 50 ЯШЬ

Н. НӘҖМИ. Куркам; Татар теле; Карлар ява; Төн уртасы. Шигырьләр . . . . . 79

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Я. КОЛМЫЙ. Каен да мин; Кем бай! Елмай әле. Шигырьләр . . . . . . . . 81
Ф. ЯННАКОПУЛУ. Сандугач һәм бөркет; Син дустыбыз безнең. Шигырьләр . . 83

ЛЕНИННЫҢ КӨРӘШТӘШЛӘРЕ

В. СКВОРЦОВ. Кырыс марксист . . . . 85

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Р. НАДИЕВ. Архитектор. Очерк . . . . 88

ИСТӘЛЕКЛӘР

Н. ИСӘНБӘТ. Унсигезенче елдан бер сәхифә . . . . . . . . . . . . . 95

ТУКАЙ КӨННӘРЕНӘ

А. ШӘРИФ. Тукай һәм әзербәйҗан әдәбияты . . . . . . . . . . . . . 110
Э. СӘГЫЙДОВА. К. Сәгыйд архивыннан. . 115
Б. САЛИХОВ. Бер рәсемнең тарихы . . . 120

МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Р. МОСТАФИН. Алман илендә. Очерк . . 121

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

И. НУРУЛЛИН. Мәгърифәтчелек реализмы турында . . . . . . . . . . . . 133

ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕНӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘСӘРЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

М. МАННУРОВА. Ибраһим Гази — портрет остасы . . . . . . . . . . . . 140

БЕЗНЕҢ САФКА

С. ХӘКИМ. Яхшы җыр сирәк туа . . . . 143
Ш. ГАЛИЕВ. Уйлана, эзләнә . . . . . . 143

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Бармак-карандаш; «Керпе гөл»; Яңа мылтык; Төрле тавышлар; «Кәбестәсе кайда!» Тәмле чәчәк; Алма; Кызык. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 144

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Атаклы кешеләр тормышыннан чын хикәяләр . . . . . . . . . . . . . . 148

Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . 154
Художник С. КАРПЕНКО рәсемнәре . . 156
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . 158
Иң яхшы әдәбият һәм сәнгать әсәрләре өчен Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләрен булдыру турында . . . . . . . . . . . . . . 160

**Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Җаваплы редактор **Рафаэль Мостафин**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/II-1968 ел. Басарга кул куелды 21/III-1968 ел. ПФ 09011. Кәгазь форматы 70×108/16. Учетн.-изд. табак 12.2. Басма табак 10(14). Тираж 65346 экз. Заказ Д-260. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казань, Бауман урамы, йорт 19, 1968 ел.

## Сибгат Хәким

### Таулар, таулар

Таулар, таулар,
Мәһабәт зур таулар...
Әйт, кешелек, торып тарихтан:
Әллә таулар алдан!
Әллә Ленин алдан!
Әллә алар бергә калыккан!

Таулар, таулар,
Мәһабәт зур таулар...
Әйт, кешелек, ашып күкләрдән:
Әллә таулар аны,
Әллә Ленин тауны
Җилкәсендә биек күтәргән!

### Татарлар елмаеп үлделәр

Өемнең янында җил елый,
Бик ерак юл узган ул, беләм;
Мусалар турында хәбәр бар:
«Татарлар елмаеп үлделәр».
Хәбәрдә тоткыннар авазы,
Меңнәрнең йокысын ул бүләр:

Без шаһит, без күрдек аларны,
«Татарлар елмаеп үлделәр».
Җил илләр буенча китәр дә
Таулардан тауларга ул менәр;
Тыңлагыз, тыңлагыз, дияр ул:
«Татарлар елмаеп үлделәр».

### Изге бер ут

Хатынны да яшь баласы белән
Искә алдым бик еш фронтта.
Ржев читләрендә, кар өстендә
Туңып-өшеп яткан минутта.
Саф сугышта гына булуыма
Инде хәзер дүрт ай тулуын
Исәплим дә кинәт сагына идем
Үзебезнең Тукай клубын.
Сүс, кабаңны ал да ракеталар
Яктысында утыр җеп эрләп...
Ракетаның түгел, шул клубның
Бер кечкенә уты җемелдәп

Күренә иде кар-бураннар аша
(Бураннарның җирдә күп чагы),
Сүндерәм дип минометлар атты,
Минометлар... алты көпшәле.
Өстә туның, кыска туның синең,
Җәннәт гүя тыштан ул тун, әй,
Эчтән җылыта туган якның уты,
Яктыртса да тычкан утыдай.
Бүрәнәдән җиде катлы итеп
Блиндажлар булдым салмакчы,
Изге бер ут кирәк икән бары
Яшәр өчен сиңа сәбәпче.

## Дүрт яран

Синең тәс, синең истәлек —
Тәрәзәдә дүрт яран.
Югалдың сугыш кырында,
Күңелдә бетми ярам.
Тәрәзә ачсам, еракта
Күренә син киткән юлан...

Онытмый сине дүрт яран,
Дүрт яран ул — дүрт балаң.
Үсте, зурайды дүрт яран,
Һәркайсы өчен янам,
Җилләр катырак иссә дә
Тәрәзәм куркып ябам.

## Кайгым төрле чикләр аша узды

Пушкин өчен гафу итә алмыйм
Тарихның шул кара елларын,
Кайгым минем чорлар кичеп килә
Буйларыннан Кара[1] елганың.
Пушкиннан соң бөек шагыйрь эзләп,
Лермонтовның үзенә ашыктым...

Кайгым минем борыла-сарыла килә,
Буйларыннан килә Машукның...[2]
Карамадым үлчәп иҗатыма
Йогынтысын минем шартларның,
Кайгым төрле чикләр аша узды,
Зурлыгына аның шатландым.

## Озын чылбыр, бик күп боҗралар

Безнең буын — озын чылбыр ул,
Кырлар буйлап узган юлдыр ул.
Озын чылбыр. Бик күп боҗралар.
Ул боҗралар — бар да без алар...
Мәмкә торган буын башында,
Бер сүз белән әйтсәк: межачы...
Авыл белән авыл арасын
Ярып үткән дөнья нужасы.
Җир — икмәгең, җир ул — язмышың,
Һәр адымың читкә, ялгышың
Кемнәрнеңдер өзгән сыныгын,
Күз яшьләре тамган солының...
Хәзер дә бар Мәмкә елгасы,
Бар да дөрес, бар да чын монда,

Җир бүлгәндә шушы елгада
Елаган ул ятып чылбырга.
Дөреслекне сөргән алга ул,
Бар авырлык төшкән Мәмкәгә...
Сөйли иде әнкәй бу хакта,
Рәхмәт укыйм һаман әнкәмә.
Буын-буын озын чылбырны,
Һич өзелмәс моңлы шул җырны,
Ничә еллар инде, ни заман
Үзем сөйрим хәзер межадан.
Язлар шаулар алда, боз агар,
Чыңлавыннан тынмас боҗралар...
Дөрес сызып микән узасың
Заманыңның син дә межасын!

## Тышта буран

Кая алып чыгарын да белмим
(Кызык өчен әйтмим арттырып),
Шигырь мине ат күк сөйри кайчак,
Буран эчендәге ат кебек.
Я фермага шунда илтеп ташлый,

Я юлдагы берәр музейга,
Я мәктәпкә, кыскача, мин көнгә
Йоз кешегә җитәм, йөз өйгә.
Картлыгымнан туеп бара идем
(Әй, каптык та бүген каптык та),

---

[1] Пушкин дуэльдә үтерелгән урын.
[2] Лермонтов дуэльдә үтерелгән урын.

Картлар йорты икән кергән өем,
Башым идем килеп картлыкка.
Урыннары янарына тезелеп
Утырганнар, тегә, чигәләр...
Төн буена шигырь сөйләр идең
Шагыйрьлегең әйтсәң син әгәр.
Тумбочкада яшьлек рәсемнәре,
Ак кәгазьгә салып рамлыйлар:
Карый рамнан йөргән егетләре:
Әмирханнар, Сәгыйт, Рәмиләр...
Аксыл йөзле, аксыл чәчле карчык
(Әйбәт яши монда, борчылма).
Охшаттым мин язын бала-чага
Кардан ясап куйган бер сынга.
Күрсәтә ул үзенең кул эшләрен,
Миңа бары кала хупларга.
Горький белән савыт-саба юган
Иделдәге пароходларда.
Кардан койган, боздан койган һәйкәл,
Күзләр инде берни шәйләми.
Пароходлар тавышын сагынган ул:
— Бик еракмы әле җәйгә, — ди.
Юлга гүя алдан әзерләнгән,
Киган юлга өстен алмашып.
Тышта буран. Сәлам эскертләре —
Пароходлар калган адашып...
Тышта буран, бер тына да кинәт
Тотына ул тагын уларга.
Шул адашкан пароходлар тавышын
Ишеттерә сыман ул аңа.

## Янып, син кал

Яулыкларың
Әллә синең,
Әллә синең
Чигелгән,
Юлларыңа
Әллә сирень,
Әллә сирень
Сибелгән.

Сине күреп
Һәммәсе дә,
Һәммәсе дә
Сөенгән,
Шатлыкларын
Әле дә сөйли,
Әле дә сөйли
Сиреньнәр...

Оныта күрмә
Үзең, зинһар,
Үзең, зинһар,
Үзең, зинһар,
Син бу җирдә
Эзеңне сал,
Эзеңне сал,
Эзеңне сал.

Бу дөньяда
Ярым, син бар,
Ярым, син бар,
Ярым, син бар,
Йолдыз кебек
Янып, син кал,
Янып, син кал,
Янып, син кал.

## Хисап бирәм

Элеккедән күп нечкәрде күңел,
Күп үзгәрде, тулы сер белән...
Үзем һаман туган якка карыйм,
Арыш ауган якка сөрлегәм.
Бик мөкиббән китмәсә дә халык,
Шагыйренең кадере бар монда.
Хисап бирәм елына бер кайтып,
Басып әнкәй кабере алдында.
Бик мөкиббән китмәсә дә, рәхмәт
Каршылаган өчен тиз танып.
Хисап бирәм, яңа җырларыма
Хәзерләнәм рухи чистарып.
Рөхсәт алам яңа эшләремә,
Алам аның хәер-догасын.
Бер түйганчы җан еласын, әйдә,
Янда торган каен еласын.
Әйләнәмен бүтән кешегә мин,
Күңел нурлы, җиргә нык басам,
Җирдә иң зур батырлыкка әзер,
Суларга сал, кирәк утка сал.
Чыгам дөнья каршысына, тимә,
Яшьләреңне сөртмә, юма, дим.
Җырның биек урнын эзли күңел,
Кабат әзер авыр юлга мин.

*1968*

— — ◆ — —

## Мәдинә Маликова

# КАЗАН КАЛАСЫ — ТАШ КАЛА

ПОВЕСТЬ

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Яңалык

Казан урамнарында буран уйный. Каршы җил тын алырга ирек бирми, вак кар бөртекләре битне чәнчеп-чәнчеп ала. Урамда кеше бик әз, җилгә аркан барганнары ирексездән йөгерәләр, ә аларга каршы килүчеләр башларын иеп әкрен атлыйлар, әледән-әле борылып тын алалар. Көн уртасы булуга карамастан, эңгер-меңгер чактагы кебек күз бәйләнә.

Мондый көннәрдә самолетлар очмый. Мәрьям Нижнекамскидан мең бәла белән, әйләнеч юллардан кайтып төште. Поездан төшүгә, кечкенә чемоданын селкеп трамвай тукталышына йөгерде. Кием-салымын кар сырган, күшеккән халыкның этешә-төртешә трамвайга утырганын читтән генә күзәтте. Инде кузгалып китәм дигәндә генә трамвай басмасына басып, уң кулы белән ишек яңагына тотынды. Аннары кысыла-кысыла эчкәрәк үтте.

Трамвайда тагын да караңгырак иде. Тәрәзәләргә калын бәс сарган. Кешеләрнең йөзләре соры, кәефсез күренә.

Тик Мәрьямнең генә күзләре дулкынланудан ялтырый, җилдә бераз ярылган битләре уттай яна.

Трамвайдан төшкәч, каршы искән җилдән башын да капламыйча, проект институтына йөгерде ул.

Ерак юлдан әйләнеп кайткач, үз өеңне дә өр-яңадан күргәндәй буласың. Таныш коридорлар, моңа чаклы күреп туйган бүлмәләр үзгәргәндәй, сиңа билгесез серләр яшергәндәй тоела.

Проект институтының биек коридорларында иртәсен-кичен электр лампочкалары янып тора. Тәрәзәләр юк биредә, һәр ике якта бүлмә ишекләре.

Тыштан килеп кергәч тә, бу караңгылыкка ияләшә алмый торасың. Бу да Мәрьямгә бик таныш иде, коридор караңгылыгы да күңелгә якын тоела. Ул, өс-башын каккалап, гардеробта чишенде дә мастерскойга юнәлде. Менә хәзер ул ишекне ачып җибәрер дә барысы белән берьюлы кычкырып исәнләшер. Барысы да Мәрьямнең исән-сау кайтуына сөенеп елмаерлар, сикереп торып янына килерләр.

Мәрьям мастерской ишегенә житәрәк, аннан таза гына гәүдәле, шадра битле, илле яшьләрдәге апа килеп чыкты.

— И-и, Мәрьям, синме бу, әллә күземә күренәсеңме? — диде ул ягымлы тавыш белән һәм кочаклап, йомшак күкрәгенә кысты. — Бу буранда ничек адашмый кайттың?

Үзе Мәрьям жавабын да көтмичә, аны ишектән читкәрәк алып китте:

— Юкка монда килеп йөргәнсең. Мин ачкычны күршедә калдырган идем. Хәер, кызлар да мәктәптән кайтканнардыр инде. Өйгә кайтып, рәхәтләнеп ял гына итәсең калган...

Хатын читкә карап, быдыр-быдыр сөйләнде. Аның күп сөйләшүеннән, мастерскойдан читкәрәк китәргә тырышуыннан Мәрьямнең күңеле нидер сизенгәндәй булды.

— Әллә бер-бер хәл булдымы соң, Сажидә апа?

— Юк ла, берни булмады... — Үзенең тавышы ук хәвефле. — Бар син, Мәрьям, начальство күзенә күренеп торма, кайт та ялт ит. Барыбер рәхмәт әйтмәсләр...

Болай булгач инде бигрәк тә кайтып китә алмады Мәрьям. Эшнең асылын белми жан тынмый инде хәзер.

— Килгәч, күрешеп кенә чыгыйм инде, Сажидә апа. Аннары кайтып китәрмен.

— Ярый алайса... Үз жаеңны үзең беләсеңдер... Мине директор чакыра әле... — дип, Сажидә апа яратып Мәрьямнең беләгеннән кысты да ашыгып китеп барды.

Мәсьәлә ачык: ниндидер күңелсезлек булган, ләкин Сажидә апа бу турыда беренче булып әйтергә кыймый. Мәрьямнең шатлыклы дулкынлануы бердән юкка чыкты. Кинәт талчыгып киткәндәй булды ул. Юләр, поезддан төшкәч тә монда йөгерүнең кемгә кирәге бар иде соң? Кеме сагынып көтә аны монда шул чаклы?

Ул ишекне каты япмаска тырышып, киез итекләре белән тавыш-тынсыз гына басып мастерскойга керде һәм сак кына үз өстәле янына узды. Мастерскойда унбиш кеше утыра. Берничә кеше өстәлләреннән баш күтәреп аның белән исәнләштеләр.

Мәрьям киез итекләрен салып, өстәл тартмасыннан биек үкчәле туфлиләрен алып киде.

Аның янына Шәфикъ абый килде.

— Кәефләрең ничек, Мәрьям?

— Яхшы, рәхмәт.

Шәфикъ абый пеләшен ике куллап сыпыргалады да кечкенә зәңгәр күзләрен Мәрьямгә сынаулы төбәп сорады:

— Соңгы хәбәрләрне ишеттеңме әле?

— Юк. Әле генә поездан төштем. Әллә сез шәһәр үзәген миннән башка гына проектлап та бетердегезме?

— Проект бетмәс, башың исән булсын. Әйдә, коридорга чыгыйк әле, монда комачаулыйбыз.

Коридорны тагын да тарайтып, зур теннис өстәле тора. Алар шул өстәлнең аргы башынарак бастылар. Биек үкчәле туфли кигән, пөхтә, кара костюмлы Мәрьям Шәфикъ абыйдан шактый калку тоела, шуңа күрә ул озын керфекләре белән күзләрен ярым каплап, абзыйның пеләшенә өстән карый. Ул үзен тыныч тотарга тырышса да, дулкынлануы йөзенә бәреп чыккан.

— Шәфикъ абый, ни булды?

— Әллә ни юк югын. Безнең институтның эшен тикшерәләр. Комиссия эшли.

— Эшләсә соң...

— Анысы ничего. Менә шул комиссия кулында жалу хаты бар, анда синең турыда кайбер нәрсәләр язылган.

— Бәй, ни язганнар?

Мәрьям чын күнелдән аптырады. Шәфикъ абый, моны күреп, бераз вакыт ләззәтләнеп торды.

— Минем сиңа белми торма, дип кенә әйтүем. Анда синең эшеңдәге житешсезлекләр турында да сүз бар, шәхси тормышыңа кагылган нәрсәләр дә бар... — Шәфикъ абый әйткәннәренә җавап булмагач, тавышын әкренәйтә төшеп, өстәп куйды: — Шәүкәт турында да диюем.

Бу исемне ишетүгә Мәрьямнең йөзе кызарды, керфекләре дерелдәп китте. Ул, кулларының калтыравын сиздермәс өчен, учлары белән терсәкләрен кысты.

— Шаяртмый торгансыңдыр, Шәфикъ абый? Бүген беренче апрель түгел, бишенче февраль бит.

— Шаярудан узды эшләр, җаным. Итәгеңне җыебрак йөр.

Шәфикъ абый керфек тә какмыйча, көлемсерәп Мәрьямнең йөзенә карап тора. Юри үрти диярсең. Юри генә үртәсә ярар иде дә ул, кызганычка каршы, аның ялган сөйли торган гадәте юклыгын бик яхшы белә Мәрьям.

Ул, Шәфикъ абыйга рәхмәт тә әйтмичә, местком председателе Ирина Сергеевна янына кереп китте. Мәсьәләнең асылын аннан гына белеп булачак иде, чөнки ул туп-туры сөйләшә торган кеше, кыек-мыекны яратмый.

Конструктор Ирина Сергеевна өченче мастерскойның нәкъ ишек турысында утыра. Олы гәүдәле, төеп тутыргандай тыгыз тәнле, иллегә якынлашып килсә дә искиткеч энергияле хатын. Ул хәзер бик тырышып Мәрьямне агарту эшенә керешәчәк.

— Ә, Мәрьям, уз әйдә, утыр.

Мәрьям як-ягына каранды, әмма Ирина Сергеевнаның янына керүчеләр өчен дип куйган урындыгын тагын әллә кая алып киткәннәр. Утырыр урын юк, басып торырга туры килә. Төшке аш сәгате булганга, мастерской буш. Кеше-кара ишетүдән курыкмыйча, рәхәтләнеп сөйләшергә була.

— Бездә ниләр булганын ишеткәнсездер инде, Мәрьямкәй.

Мәрьям ике учы белән өстәлгә таянды:

— Комиссия килгән, диләр...

— Килде генә түгел, тикшерә!

Ирина Сергеевна бусына басым ясап әйтте. Ул Мәрьям бирәр сүз әйтмәсме дип бераз көтеп торды да, җавап булмагач, янә алтын тешләрен күрсәтеп авызын ачты.

— Үзең дә беләсең, мондый гауга безнең коллективны бизәми. Но рас мондый хәлгә төшкәнбез икән, без бу гаугадан пычранмыйча, буялмыйча чыгу ягын табарга тиешбез. Син комиссия алдында ни сөйләячәгеңне алдан ук уйлап куй. Алдыңны-артыңны карамыйча, теләсә ни сөйләп ташлый торган гадәтең бар синең.

Мәрьям керфекләрен сирпеп әйтә куйды:

— Сорауларына җавап бирермен инде, шул булыр. Дөресен әйтермен.

— Дөресен дә төрлечә сөйләп була бит аның. Рәтен белеп сөйләмәсәң, дөресен әйтәм дип, үзеңне хур итеп ташлавың бар. Менә ул жалобадан кайбер өзекләрне язып та алган идем. Кая соң әле? — дип, Ирина Сергеевна өстәлендә өелеп яткан кәгазьләрне туздырып ташлады, өстәл тартмаларын ачып япты, ахырда кирәк кәгазен алдында яткан газета астыннан тартып чыгарды да бераз иелебрәк укый башлады:

— «Инженер Закирова үзен архитектор дип атап, соңгы вакытта тәмам бәйдән ычкынды. Төзү мәйданнарында тәртип бозуга барып житте. Мәсәлән, «Чулпан» кинотеатрында...» — Бу урында ул башын күтәреп, Мәрьямгә текәлде. — Монысын язып шәп иткәннәр. Жалоба язган кешеләрнең үз башына бу. Син проектыңны алып кер, «Чулпан»га үзләренең барганнары да бардыр, кинога йөриләрдер әле. Монысы куркы-

ныч түгел. Дальше, анда сине Аитов белән чуала дип язганнар. Некрасиво, Мәрьям, некрасиво. Мин сиңа сак бул дип элек тә әйтмәкче идем, үзе дә сабый түгел бит дип, батырчылык итмәдем. Юкка гына әдәп саклап торганмын. Гомумән, түзә алмаслык гашыйк булган очракта гына барырга кирәк андый эшкә. Ирләр әшәке алар, соңыннан гомер үткәч, барыбер артыңнан сөйләп йөриләр. Син яшь әле, мин олырак кеше, әйткән иде, диярсең әле миңа... Үзең гаепле, бернишләп булмый. Хәзер инде бу урында ни әйтәсеңне бик яхшылап уйларга кирәк.

Мәрьям аның сүзен бүлдерде:

— Бу минем шәхси эшем лә... Чит кешегә отчет бирәсем килми минем!

— А юк! Комиссия членнарын алай үзеңә каршы куярга ярамый. Анда горсоветтан да, обком союздан да кешеләр бар. Син болай диген: «Мин пляжга коенырга барган идем, Аитов белән көтмәгәндә очрашып, бераз сөйләшеп тордым», диген. Бетте-китте. Так, дальше. «Закирова белән Лотфуллинның коридорда үбешеп торганнарын ип. Гаделшина күреп торган». Ну Гаделшинаның сүзе әллә ни абруйлы түгел, булмады, дисәң дә вәссәлам.

— Әгәр булган булса?

— Тем хуже для тебя! Комиссия алдында синең, мин шулай да, мин болай дип сөйләп торуыңның беркемгә дә файдасы булмаячак. Так что мин әйткәннәр турында аркылысын-буен үлчәп, иренмичә уйла әле син.

— Ирина Сергеевна, кем язган соң ул жалобаны?

— Гаделшина, тагын бер-ике кеше кул куйган бугай.

— Кемнәр?

— Анысын миңа әйтмәделәр. Менә күрдеңме, кешеләр нишли, ә? Теләсә нинди чарадан да тартынмыйлар. Ә син җебеп йөрисең. Аңла: тормыш — көрәш ул. Көрәшә белергә кирәк бу дөньяда, шунсыз тормыш итеп булмый!

Ирина Сергеевна яныннан Мәрьям бик кәефсезләнеп, гарьләнеп чыкты.

Ул үз мастерскойларына кергәч кая барып бәрелергә белми, аргы башка, мөдир Морат янына, барып басты. Аның күләгәсе өстәлдәге эскизларга төшкәч, Морат башын күтәрде, калын пыялалы күзлеген салып, сабыйлар кебек, кызарган күзләрен йодрыгы белән ышкыды да, күзлеген кире киеп, Мәрьямгә текәлде:

— Нәрсә?

— Менә кайттым.

— Ну?

— Шуны әйтергә килдем.

— Бик әйбәт. Бүгеннән үк эшкә тотын.

— Нишлим соң?

Моратның түземлеге бетә башлады.

— Заданиең бармы синең? Бар. Ундүрт катлы гостиница. Эшлә шуны, аяк астында чуалма, зинһар. Эш күп.

Морат алдында яткан кәгазь кисәгенә төртелде. Кәгазьгә кара карандаш белән гөмбәз сурәте ясалган. Цирк! Индивидуаль проект төзергә рөхсәт алгач, Моратның дөньядан хәбәре бетте, ул гел шул цирк белән хыяллана. Ул гына да түгел, бөтен мастерской эшчеләреннән шул циркны эшләтә. Моратның яше инде кырыкның теге ягына авышкан, ул тизрәк эшләп калырга ашыга. Аның өчен Мәрьямнең шәхси тормышында килеп чыккан буталчыклар игътибарга лаек булмаслык вак эш, билгеле.

Эшлә, имеш! Эшләрлек хәлдә ди сиңа монда — Мәрьям, тәмам хәтере калып, урынына барып утырды. Ул уйланып үз алдында утырган Камәрия Гаделшинага карый. Гадәттә Камәрия Мәрьямгә яны белән утыра иде, хәзер өстәлен борган да Мәрьям ягына аркасын куеп утыр-

ган. Камәрия Мәрьямнең карашын сизә, аның сирәк, көл төсле чәче арасыннан күренеп торган колаклары алсулана, сөякчел, тар иңбашларының сер бирмәскә тырышудан таш кебек хәрәкәтсез калганлыгы сизелеп тора. Ниһаять, ул түзми, әкрен генә борылып карый. Арттан караганда Камәрияне яшүсмер кыз дип белерсең, үзе юка гына, чәче кыска итеп киселгән. Өстендә мәктәп формасына охшаган ак якалы күлмәк. Менә ул борыла, аның кечкенә груша сыман борыны һәм жыерчык баскан йөзе күренә. Сәер кеше ул, бичара!

Моңарчы Мәрьям Камәрияне кызгана иде. Ул карт кыз, инде кырыкка якынлашып килсә дә, кияүгә чыга алмаган. Хәер, сугыштан соңгы чорда әз булдымыни андыйлар?

Дөрес, Камәрия аңа бик ямьсез, мәхәббәтсез тоела иде. Шуңа күрә дә, сөйкемсез булганы өчен дә кызгана иде Мәрьям аны.

Ә менә Камәрия Мәрьямне кызганып тормаган. Ярый әле, Мәрьям, хәзерге заманда тугансың. Элекке заманда туган булсаң, Шәукәтне ятратуың өчен сине муеныңнан жиргә күмеп, башыңа таш белән бәреп үтерерләр иде. Беренче ташны Камәрия ыргытыр иде.

Хәзер кешегә таш атарга ярамый, әмма каләм алып, жалоба язуны тыймыйлар. Жалобаны укымаса да, Мәрьям Камәриянең ни язганын әйтә ала: «Без шәһәребезне чиста куллар белән төзергә тиешбез, ә менә Закирова кебек әхлаксыз кешеләр архитектор исеменә тап төшерәләр һ. б.» Камәрия үзенең бәхетсезлеге өчен кешеләрдән үч ала...

Мәрьям алдында үзен ким кеше итеп тоя Камәрия. Инде Мәрьямнең тормышы чуалса, исеме пычранса, ул жиңел сулап куячак: «Дөньяның бәхетсезе бер мин генә түгел бит әле. Әнә, бик бәхетле дигәннәрнең дә тормышы түгәрәк түгел». Шул рәвешле янындагы кешеләрне кимсетеп, пычратып, ул үзен күренеклерәк, чистарак кеше итеп күрсәтәчәк. Бар бит дөньяда шундый кешеләр: очарлык канатлары булмагач, башкаларны түбәнсетү бәрабәренә үзләрен биек күрсәтергә тырышалар...

Их, юкка гына килде лә Мәрьям бүген институтка! Менә башта әллә нинди ямьсез, күңелсез уйлар чуала... Хәер, эш урынына килмичә, кая барсын соң ул? Торыр почмагы да юк бит аның хәзер. Тагын шул Сажидә апаларына бара инде, нишләмәк кирәк...

## Күңелгә кыршау юк

Урамда буран тынган. Табигать, зур мәшәкатьләрдән арынган кешедәй, ял итә. Караңгы төшүгә карамастан, урам себерүчеләр тротуардан кар көриләр, аларга олы агач көрәкләр тоткан эреле-ваклы балачагалар ярдәм итә. Көрт ерып бата-чума кайту бик рәхәт. Юкка алай ашыгып көриләр бу карны.

Кешеләр эштән кайтсалар да, башка вакыттагыча ашыгып-кабаланып узмыйлар, үз көйләренә генә атлыйлар. Карның аклыгыннан, дөньяның пакьлыгыннан, һаваның чисталыгыннан күңелләр ачылып китә, үткән гомернең рәхәт минутлары гына искә төшә. Әнә кардай ак башлык кигән яшь кенә бер хатын коляскасы белән сабыен тротуарга чыгарган да борын эченнән генә моңлы көй суза:

— Ай, лә-лә-лә-лә!

Зур йөк машинасы трамвай юлына аркылы килгән һәм кузгала алмыйча карда буксовать итә. Аның янына ике яктан ике трамвай килеп туктаган, әледән-әле урамны яңгыратып кыңгырауларын зыңгылдаталар. Менә трамвайларның ишекләре ачылды, алардан ир-егетләр төште. «Жәяү китәләр инде»,— дип уйлады Мәрьям. Юк икән, ирләр әлеге машинага ябыштылар да һай-һулап аны этә башладылар: «Раз-

два, взяли!» Машина үз юлы белән китеп баргач, ирләр пальто итәкләрен каккалап, кире трамвайга утырдылар.

Мәрьям кольцога кадәр җәяү генә барырга булды.

Бутлеров урамы — Казанның иң матур урамнарыннан берсе кебек тоела аңа. Элеккедән калган агач өйләр дә, күптән түгел салынган таш пулатлар да бар биредә. Яшел бакчалар дисеңме, аны аркылыга кискән тын урамнар, серле тыкрыклар дисеңме — барысы да бар. Өстәвенә аларның күбесе Мәрьямнең яшьлек истәлекләрен саклый. Ачыктан-ачык әйткәндә, ул истәлекләр Шәүкәт белән бәйле. Әйе, жалобада телгә алынган Шәүкәт Аитов белән.

Аның исемен ишеткәндә Мәрьям йөзенә кызыллык йөгергәнен, йөрәгенең дөп-дөп типкәнен кешеләрдән әле хәзер дә яшерә алмый. И-их, ник чәнчелеп китми шунда барлык жалобалары! Иң бәхетле минутлар Шәүкәт белән узды, Мәрьям моңа тамчы да үкенми, әгәр кирәк икән, мең жалобаны тикшерүче мең комиссиягә үз сүзен әйтеп чыгарга әзер ул.

Тик үз вакытында очрашуларның кадерен белеп житкермәгәнсеңдер кебек...

Нәкъ шушындый, әз генә яз исе килеп торган жылы кышкы кичләрнең берсендә, цирктан кайткач, нәкъ шушы тротуарларда шактый вакыт житәкләшеп йөргәннәр иде алар. Әйе, бу моннан шактый күп еллар элек булды, ул чакта әле Казанның иске циркы эшли иде. Менә хәзер архитектор Морат Шәехзадин гаҗәеп бер гөмбәзле яңа циркка проект сыза. Бик матур булыр инде бу цирк, мөгаен. Тик ул барыбер Мәрьямгә иске цирк кебек якын, матур тоелмас. Анда башка гашыйклар йөрер, ул башкаларга истәлекле булып калыр.

Шәүкәт билетларны беренче рәткә үк алган иде. Мәрьям сизелер-сизелмәс кенә Шәүкәткә таба авышыбрак, дулкынланып, рәхәтләнеп көлеп утырды. Хәзер нәрсә караганы истә калмаган инде, тик ул кичне Мәрьям бик бәхетле иде, шунысы гына хәтердә. Тамаша беткәч, аллы-гөлле ыштан кигән, бит очларына иннек яккан клоун Мәрьямгә кызыл шар бүләк иткән иде. Мең кеше арасыннан шул мәзәк клоун ничек Мәрьямне күреп алды икән, ә?

Мәрьям урамда гел шул шарын болгап йөрде. Соңыннан капка төбендә шактый вакыт басып тордылар. Әнә ул капка тау өстендә, финанс институты белән янәшә үк диярлек. Ә ишек алдында ике катлы агач йорт. Мәрьям шул йортта яшәүче ялгыз карчык Дуся түтәйдә фатирда яши иде ул чакта.

Алар дәшми озак тордылар. Дулкынланудан һава эсселәнгәндәй булды. Мәрьям шарны Шәүкәт белән ике арада тотарга тырышты. Кинәт Шәүкәт шарга җиңелчә генә сукты да, Мәрьям аны-моны абайлап өлгергәнче, кайнар учлары белән аның ике яңагыннан тотып, иреннәреннән үбеп алды.

Мәрьям, оялуыннан, дулкынлануыннан бер сүз әйтә алмыйча, йөгереп капкадан кереп китте. Беренче үбешүләре иде бу аларның...

Урамнар шул ук, тик Шәүкәт кенә юк, тик Мәрьям генә үзгәргән... Ул кольцога килеп житкән иде инде. Чират торып, беренче троллейбуска утырды. Алга узып, троллейбус йөртүче кабинасының тәрәзәләре аша карап барды. Бауман урамында халык гадәттәгедән дә күбрәк. Халык арасыннан әкрен генә юл ерып барган троллейбус, Ленин күперен үтеп, дамбага чыккач, бик кызу элдертә башлады. Тәрәзә артында, электр фонарьларыннан төшкән яктылыкның теге ягында, караңгылыкта, тынлыкта, калын кар-боз катлавы астында Казанка йоклый.

Казанка! Вак, назлы дулкыннарында Шәүкәт белән Мәрьямнең көймәсен тибрәткән елга. Аларның бәхетле минутларын күргән, эчке серләрен, канатлы хыялларын тыңлаган бердәнбер шаһит. Җәй уртасында, иң аяз, эссе көннәрнең берсендә, Максим Горький паркы янын-

дагы причалдан көймә алып, авыр, уңайсыз ишкәкләр белән ишеп шушы дамба янына кадәр килеп җиткәннәр иде алар. Диңгездәй җәелгән елга өсте тулы көймә, пляж янында — коенучылар йөзә, аклы-кызыллы көймәләренең койрыгы белән генә суны ертып, кояшта чуен кебек янган «коткаручылар» тыз-быз чаба. Үләсең килеп суга ташлансаң да, өстерәп чыгарасыларын көт тә тор: коткаручыларның чырайлары бик җитди һәм тәвәккәл.

Шәүкәт ишүдән туктаган. Мәрьям үрә басып, тирә-яктагы хозурлыктан авызын ерган. Ул кремль яныннан югарыга үзып барган «Москвич»ка чуар косынкасын болгый. «Ә-әй, хәерле юл!» Трамвай әллә башка берәүгә, әллә Мәрьямгә сигнал бирә: «Ту-ту-ту!» Шәүкәт тә үрә баса, тик кул болгамый, ул җитди кеше бит.

Ак пароход биек күпер астына кереп китә. Ул калдырган озын дулкыннар көймәне йомшак кына тирбәтәләр. Шәүкәт утыра да елганың уң як сөзәк, чирәмле ярына ишә. Анда берәү дә юк. Көймәне икәүләшеп ярга сөйриләр. Шәүкәтнең суга чумган минутыннан файдаланып, Мәрьям чуар сарафанын салып ташлый һәм шундый ук ситсыдан тегелгән су коену костюмыннан гына кала. Ул әчкәрәк йөзеп керә, зәңгәр күккә карап су өстендә чалкан ята һәм күзләрен йомып, йөзен кояшка куя да елмая.

Бераздан алар судан чыгып, яшел чирәмгә утыралар. Мәрьям ак кремль стеналарына, аксыл-зәңгәр күк фонында биек һәм мәһабәт күренгән Сөембикә манарасына карап уйга чума. Шәүкәт түшенә ятып, терсәкләренә таянган да кузгалак яфрагы чәйни.

— Шәүкәт, әйт әле, кулыңда чиксез кодрәт булса, нишләр идең син?

— Нигә миңа чиксез кодрәт? Мин болай да теләгемә ирешәчәкмен.

— Ә нәрсә телисең соң син?

— Мин теләгәнне кодрәт белән генә булдырып булмый шул. Талант кирәк.— Шәүкәт урыныннан кузгалмады, тавышын күтәрмәде. Әмма аның киң борын өстенә килеп кушылган куе кашлары бераздан җыерылдылар, кечкенә соры күзләрендә кырыс очкыннар кабынды, йөзе чибәрләнеп китте.— Мин сәнгатьтә үз сүземне әйтергә тиеш. Һәрхәлдә, Аитов дигән художникның үз «Джоконда»сы булыр.

— Икенче «Джоконда»мы?

— Нәрсәгә кирәк ул икенче «Джоконда»? Әһәмияте белән шуңа тиң картина булыр ул... Мин урта кул кеше булырга теләмим. Алай яшәүнең ни кызыгы бар, кемгә кирәге бар? Тормышта очкынланып янарга, үзеңнән соң мәңге үлмәслек эз калдырырга кирәк. Мин моңа омтылачакмын һәм, әлбәттә, ирешәчәкмен. Берничә елдан син минем турыда ишетерсең әле!

Мәрьям моңа ышанып җитми. Шулай да шикләрен сиздереп, Шәүкәтнең кәефен кырасы килми. Ул бераз иелебрәк, әкрен тавыш белән пышылдап диярлек сөйли:

— Әгәр син чыннан да бөек художник була алсаң, мин шундый кеше белән дуслашуыма бик тә, бик тә горурланачакмын. Әгәр инде дан казана алмасаң... һәрхәлдә, ни генә булмасын, син минем өчен бердәнбер Шәүкәт булып калырсың.

— Рәхмәт!

— Ә мин шәһәр төзер идем. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән шәһәр булсын иде ул. Һәр йорт, һәр бина үзе бер көй кебек яңгырап торсын, һәм бер шәһәрдә алар бөтен симфония кебек табигый кушылсыннар иде. Мин ул шәһәрне бераз күз алдыма да китерәм. Ул шәһәрдә бәхетле кешеләр яшәсен иде. Алар бу каланы салган кешене — архитекторны белмәсләр дә, бәлки. Тик ул кала мәңге тузмаслык йортлардан булсын иде. Һәм шул йортларның берсендә үзем дә яшәсәм иде.

— Үзең генәме? — дип сорый Шәүкәт, җитди кыяфәтен үзгәртмичә.

— Бик теләсәң сине дә үз яныма алырмын.

— Юләр син. Синең кебек хыялыйга проект төзергә ирек куйсалар, шәһәрләр бик кыйбатка төшәр иде. Хәзер биналарны типовой проект буенча гына салалар. Аларның авторы да билгесез.

— Гел алай булмас! Ярый, мин шәһәр сала да алмам, бәлки. Әмма йортлар салачакмын. Минем проект белән төзелгән йортлар, әлбәттә, булачак, менә күрерсең!

Шулай дигән иде Мәрьям. Әмма ул чакта аның проектлары буенча нинди дә булса биналар төзеләчәгенә үзе дә ышанып бетмәгән иде. Чөнки ул елларны бөтен нәрсә гел типовой проектлар буенча гына салына иде. Үзең төзегән проект буенча йорт салдыру икенче Джокондаңы иҗат итүгә караганда да мөмкин булмаслык эш кебек иде. Чөнки картина ясау өчен кешегә талант белән тырышлык җитә. Ә архитектор өчен ул гына аз, аңа иҗат итәргә мөмкинлек тә кирәк бит.

Ул көнне алар караңгы төшкәч кенә паркка әйләнеп кайттылар. Көймә биреп торучы агай сукранып та алды:

— Тугызда өйгә кайтып китәргә тиеш мин, әлегә чаклы бер сезне көтеп утырдым.

Алар паркның асфальт җәелгән, кеше мыжлап торган аллеялары буйлап түгел, куе ябалдашлы, өрәңгеләр, топольләр белән капланган, текә ярлы, тирән, караңгы чокыр буйлап киттеләр. Мәрьям юри иркәләнеп: «Уф, ардым»,— диюгә, Шәүкәт аны күтәреп алды. Мәрьям, аның муеныннан кочып, колагына пышылдады: «Җибәр, син дә аргансыңдыр...» «Юк, җибәрмим... Җир читенә алып китәм мин сине».

Алай ук ерак алып китмәде тагын, чокырдан чыгып, яп-якты сукмакка аяк баскач, кулыннан төшерде. Кольцога кадәр житәкләшеп җәяү кайттылар. Электр лампочкаларыннан багана тирәләренә якты түгәрәкләр төшкән иде. Багана турыннан узгач та, күләгәләр алга төшә: түгәрәк башлы, кыска муенлы, киң җилкәле Шәүкәт шәүләсе, аннан шактый кыска, нечкә билле, озын муенлы, тар җилкәле Мәрьям. Шәүкәт тезләрен аерып, бераз киерелебрәк атлый. Һәр адымыннан яшьлек, тазалык, көч һәм ышаныч сизелеп тора...

Аннан соң Казанка ничәнче кат боз белән капланды бит инде. Алтынчымы-җиденчеме? Хәер, аны санап торуның ник кирәге бар? Ничә ел үтсә дә, мәңге онытылмаслык матур истәлекләр бит алар...

Менә троллейбус бер чакрымга сузылган дамбаны узып, урамга керде. Шушы юл буйлап биш ел эшкә йөри инде Мәрьям, әмма бу урам аның күңеленә һаман да чит булып кала. Чөнки бу йортлар, бу тыкрыклар, бу топольләр Мәрьямгә бернинди истәлек тә хәтерләтмиләр.

## Өйдән кире якка

Балалар бакчасында Мәрьям тезләнеп Фәйрүзәсен үбә. Кызчык кечкенә, кайнар гәүдәсе белән әнисенә сыенган, йомшак битен аның яңагына терәгән.

— Сагындыңмы мине, бәбием?

Бала, әнисенә тагы да ныграк сыенып, ияген кага. Әллә инде атнаун көн эчендә әнисеннән бизгән, читенсенә дә башлаган?

Ана белән кыз әкрен генә атлап урамнан кайталар. Ананың күңеле тыныч, барлык истәлекләр, уйланулар әллә кайда, еракта калган, онытылган кебек. Бала гына исән булсын, ул янында булсын — аңарга ни кирәк тагын бу дөньяда?

Әмма ул бала дигәнең дә тик тормый бит, сораулар биреп теңкәңә тия:

— Әни, кая алып барасың мине?

— Өйгә, бәбием.

Фәйрүзә, туктап, нәкъ әтисенеке кебек зур, коңгырт күзләрен шар ача.

— Безнең өй ә-ә-нә тегендә бит. — Ул ак йөнтәс бияләе белән урамның теге ягына төртә. Я, ни дисен, ничек итеп барын да аңлатасың инде бу сабыйга?

— Әйдә, кызым, апаларга барыйк әле бүген...

Фәйрүзә, аның тавышында ышанычсызлык сизеп, ахры, әнисе белән китәргә ашыкмый, нәрсәнедер аңларга тырышкандай уйланып тора.

— Әйдә, кызым...

Мәрьям артында карның йомшак кына шыгырдаганын ишетә. Алар турына житкәч, адым тавышлары тына. Мәрьям башын күтәрмәсә дә, ул кешене күрмәсә дә, белә, таный, бу — Вилдан.

— Әти! — ди Фәйрүзә аңа ташланып.

Вилдан кызын кулына күтәреп алды, дулкынлануын сиздермәскә тырышып, мөмкин кадәр битараф тавыш белән Мәрьямгә дәште:

— Кайтуың белән!

— Рәхмәт.

Мәрьям, ниһаять, аңа күтәрелеп карады. Әллә якындагы электр утын чагылдырып инде, Вилданның күзләре салкын ялтырыйлар. Озынча чибәр йөзе житди. Гадәттәгечә, йөнтәс бүрегенең колакчыннарын төшергән, пальто якасын күтәргән.

— Тагын өйдән кире якка китүеңме? — Аның калын тавышында көлемсерәү дә, әрнү дә сизелә.

— Мин өемнең кайда икәнен белмим әле.

— Ярый, син белмисең, ди. Ә Фәйрүзә соң, Фәйрүзә? Аның өе булырга тиеш лабаса? Ни өчен ул үз өен ташлап, кеше почмагында аунарга тиеш әле?

— Мин ардым, Вилдан. Башка вакытта сөйләшербез, яме?

Бу сүзләрдән аның кинәт кабынып китүен көткән иде Мәрьям, ләкин ул бары тирән көрсенде дә кызны жиргә төшерде. Фәйрүзә шундук бер кулы белән әтисен, икенче кулы белән әнисен житәкләп алды. Алар, шулай өчесе житәкләшеп, шау-гөр килеп торган зур урамнан аркылы чыгу өчен, светофорда яшел ут кабынганын көттеләр.

Тынычрак, аулаграк урамга кергәч, Вилдан тагын бер көрсенеп куйды.

— Гафу итәр идем, ичмасам. Неужели намусың юкмый синең, ә?

— Гафу ит, мин гаепле, — диде Мәрьям.

— Һе, үзем сорап алгач аны. — Бераз сүзсез бардылар, шунда Фәйрүзәнең такылдавы ишетелде:

— Бүген без өчебез дә апаларда йоклыйбыз. Шулай бит? Әти, әйе бит? Әни, әйе бит?

— Юк шул, кызым, мине әниең апаларга алып керми шул, — диде Вилдан. Аннары үз алдына сөйләгәндәй: — Синең кебекләргә гел контроль кирәктер, күрәсең. Мин шул чакта әллә кая китеп бармаган булсам, болай адәм көлкесенә калмаган булыр идек, бәлки. Иң кирәк чакта синең янында булмаганмын мин...

Бу яңалык. Вилдан моңарчы гел Мәрьямне генә гаепли иде, ганләнең пыран-заран килүен аңлый алмый гажиз иде. Хәзер нык уйлаганы, хәтта хатынын аңларга тырышуы сизелә. Аңа да жиңел түгел, аңа да бик авыр, күрәсең.

Аңа элекке тынычлыгын кайтарып бирү өчен, күп нәрсәдән баш тартырга әзер Мәрьям. Ул үзенең гаепле икәнен дә аңлый. Ләкин Вилдан янына кире кайта алмый, үзен мәжбүр итә алмый.

Алар биш катлы йортның караңгы подъезды янына килеп туктады-

лар. Ишек алды уртасында, йомшак карда чыр-чу килеп бала-чага уйный.

— Әллә соң кире кайтабызмы? — ди Вилдан карлыккан тавыш белән, үз сүзенә үзе ышанмагандай. Мәрьямнең кинәт бәгыре ката, чөнки Вилдан, ялварулы тавышы белән үзен аның алдында кимсетеп куйды.

— Юк. Ярый, хәерле төн.

Ул Фәйрүзәне кулына күтәреп алды да, уңайсыз ишекне берничә кат тартканнан соң көчкә ачып, кереп китте. Аны аңлаудан гаҗиз Вилдан:

— Баладан оялыр иден, ичмасам! — дип сөйләнеп калды.

Ул хаклы, әлбәттә, хаклы, ләкин нишләмәк кирәк, бала хакына дип аның янына кайтырга үзен мәҗбүр итә алмый Мәрьям. Күңел сүрелгән, аралар суынган, үткәннәргә кайту мөмкин түгел!

## «Ир—алтын багана»

Сажидә апа кофта бәйли. Мәрьям кучеп килгәч кенә дә ике кызына, үзенә бәйләп кигән иде. Инде хәзер ак ефәк җептән бәйли. Кулы күнегеп беткән, әнәсе үзе биеп тора кебек. Үзе алга иелебрәк диванга җайлап утырган, өстендә җылы, йомшак халат. Күзләре каршысындагы креслога урнашкан Мәрьямнең йөзендә. Мәрьямнең арган гәүдәсе дә, талчыккан күңеле дә ял итә кебек. Башында буталчык уйлар: ул уяу килеш тә төш күрә кебек. Сажидә апаның сүзләре дә бик ерактан ишетелгәндәй тоела. Бүлмә ярым караңгы, яшел абажурлы торшердан Сажидә апага гына яктылык сибелә. Балалар барысы да күрше бүлмәдә йоклыйлар.

— И-и, Мәрьям, гомер иткәндә әллә ниләр күрәсең икән бу дөньяда. Менә минем беренче иптәшем Арыслан чын егет иде инде. И яратыштык бер-беребезне, и-и яратыштык. Сугыш башлангач, бер көн булса да бергә торып калыйк дип, юри өйләнештек. Ансыз бер көн дә яши алмас кебек идем.

Сажидә апа бәйләвен диванның аргы башына ыргытты. Аның тормыш кыйссасын Мәрьям мең ишеткән инде, шулай да Сажидә апаның сүзе туйдырмый. Әллә инде үзе бик хисләнеп сөйләгәнгә, әллә һәрвакыт янача итеп сөйли белгәнгә, чын күңелдән аның хәленә кереп, аның белән бергә сагышланып тыңлый. Арысланның сугышта һәлак булуы, Сажидә апаның шул кайгыдан юләрләнә язуы, уйларга вакыт калмасын дип көне-төне эшкә җигелүе, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча сигез ел тол яшәве, ахырда тормыш үзенекен итүе, димләгән кешеләргә ышанып, күрмәгән-белмәгән Гамирга ияреп Казанга чыгып китүе — барысын да яна гына ишетәсең кебек.

— Гомерем буе Арысланны оныта алмадым, шулай да Гамирга чыкканыма тамчы да үкенмәдем. Бер ялгызым, ирсез-баласыз ничек яшәр идем бу дөньяда. Хәзер менә Гамир үлгәч, үткәннәрем турында кат-кат уйлыйм да, ирем барда бер кайгым да булмаган икән, дип куям. Ир — алтын багана икән, чыннан да. Иртәгә ничек яшәрмен, ни булыр дип уйлаганым да юк иде. Хәзер бер үземә шулхәтле авыр...

Сажидә апаның күзләренә яшь тула.

— Синең дә күңелең бер утырыр әле, — ди ул сүзне борып. Чөнки үз хәлен генә сөйләп утыру авыр аңа. — Бу болганулар тынар. Тормыш үз җаена салыныр. Әмма ирсез яшәп булмый, Мәрьям, бу дөньяда. Хатын кешегә бигрәк тә. Бер-береңә таянсаң гына җиңел була тормыш. Мин әйтәм, әгәр Вилдан җәй көне әллә кайларга китеп йөрмәгән булса, мөгаен, һаман шулай тыныч кына яшәр идегез әле.

Бу сүзләрдән Мәрьям уянып киткәндәй булды. Тукта әле, бүген Вилдан да шуңа охшашрак сүз әйтте түгелме?

— Әллә сез Вилдан белән сөйләштегезме?

Сажидә апа кыенсынып, әле күзләрендә кибеп тә бетмәгән яшь аралаш елмая:

— Күрешкән идек шул. Фәйрүзәнең хәлен белергә барган идем. Ир-ат бала карый беләмени ул. Шуны әйтәм әле, менә болай пыранзаран килеп бетмәгән булсагыз, синең өстән жалу язып, башыңны тинтерәтеп йөрмәсләр иде. Вилдан барып, өстәл сугып, ник минем семьяга катышасыз дип бер әйтсә, шып булырлар иде. Кая барсаң, нишләсәң дә ир кирәк шул. Ирсез хатынга сан юк инде аңа.

Мәрьям тагын изрәде, Сажидә апа сүзләре янә төш күргән кебек:

— И-и, тыңламыйсың ла син! Әйдә ятыйк инде алайса, тәмам күзләрең йомылган инде. Мин юләр дә юлдан кайткан, арган кешегә акыл сатып утырам тагын. Әйдә инде, әйдә, ят!

Сажидә апа диваннан кузгалып, анда Мәрьям өчен урын сала. Үзе каршы стена буендагы караватка ята, торшерны сүндерә.

Тиз йокыга китә ул. Гажәп түгел, бик иртә торып, кызларын ашатып-эчертеп, мәктәпкә караштырып озатасы бар.

Ә Мәрьямнең күзеннән йокы качты. Тегеләй дә, болай да ятып карады ул, һаман урынның җаен тапмады. Диван каты, юрган эссе кебек, аяклар сулкылдый. Артык арылгангадыр, ахры.

Караңгыда ялгызың калгач, төрле уйлар күңелгә килә. Тышта тагын җил купты, ахры, ыжылдаганы ишетелә. Йөрәкне нәрсәдер чәнчеп тора кебек, нидер тынгы бирми... Ә-ә, комиссия!..

Комиссия булгач, берничә кешедер инде ул. Кемнәр икән? Хәер, кем генә булмасын, өстәл артында утырган берничә кеше алдында ничек инде йөрәгеңне ачып саласың? Анда, мөгаен, пенсиягә чыккан олы яшьтәге карчыклар да бардыр әле. Алар кешенең шәхси тормышында казынуны бик яраталар бит. Яшь чагында алар да төрлесен кичергәннәрдер, билгеле, әмма картая башлагач, үткәннәре онытылган, үзләрен фәрештә кебек гөнаһсыз хис итә башлаганнар. Алар яшьләрне бозыклыкта, азгынлыкта гаеплиләр, һәртөрле шау-шулы вакыйгаларга кысылырга яраталар. Эч сереңне аларга сөйләгәнче, урамга чыгып мегафон аша кычкырганың яхшырак.

Тукта әле, ни гаебе бар соң аның, алай комиссияләр төзеп тикшерерлек? Кайчан ялгышты ул?

Унынчы классны тәмамлаганда, Мәрьям кем буласын белми иде әле. Ул математиканы ярата, бик яхшы сыза, рәсем ясый иде. Әмма кайсы юлдан китәргә? Математик булыргамы, художникмы? Моны хәл итә алмый шактый йөрде ул.

Ләкин бер нәрсәне яхшы тоя иде: асылда ул мәхәббәт өчен, өзелеп сөю өчен дөньяга килгән. Ул башка берәү өчен яшәячәк.

Төзү институтын тәмамлап, проект институтында эшли башлагач, инде егерме өч яшенә җиткәч, Мәрьям Шәүкәтне очратты.

Ул чакта кыз Шәүкәтнең аны яратуына һич шикләнмәде. Хәзер дә ышана: Шәүкәт Мәрьямне яраткан кебек башка беркемне дә ярата алмаячак. Мәрьям хәзер дә Шәүкәтнең кайнар иреннәрен тойгандай, көчле кулларын иңнәрендә сизгәндәй була. «Мәрьям... газаплама мине». Аның назлары кызның бөтен ихтыярын ала, эретә, үзенә буйсындыра иде. Шулай да Мәрьям ул чакта ахырынача аныкы була алмады. Бердән кызлык оялчанлыгы тыйса, икенчедән, акыл ирек бирмәде: Шәүкәтнең үзенә мәҗбүрияттән чыгып түгел, ансыз тора алмаганга өйләнүен теләде һәм шуны көтте ул.

Шәүкәт өйләнешү турында сүз кузгатмады. Хәер, бу аңлашыла иде, чөнки егет художество училищесын яңа тәмамлаган, фатирда тора, эш хакы да әз иде әле.

Булса соң! Мәрьям аны мәңге котәргә дә риза иде.
Киләчәккә планнар кормадылар. Шулай да күңелләрнең бер-берсенә тартылып торуы, гел бергә йөрү юкка гына түгел иде ләбаса, болар бер-береңә ант бирү кебек иде бит.
Шәүкәт укуы беткәч тә кайтып китмәде, җәй буе Казанда торды. Җәй буе дигәч тә, бик тиз үтеп китте ул айлар...
Август аенда Мәрьям ял алып туганнары янына авылга кайтып китте, Шәүкәт тә, ниһаять, әнисе янына кайтырга булды. Аерылганда, бер ай буе бер-беребезне күрми ничек түзәрбез, дип уйлаганнар иде.
Ахмаклар, диген. Хәзер менә ай түгел, еллар, бөтен гомер аерым уза, берни эшләр хәл юк, түзәсең.
Мәрьям авылдан Шәүкәткә озын-озын хатлар язып торды. Аларның берсендә: «Аерылышуыбыз яхшыга гына булды әле, мөнәсәбәтләребезгә читтәнрәк, аеграк карарбыз, дуслыгыбызны сынарбыз», — дип тә язган иде ул. Хәзер искә төшкәндә дә шул сүзләре өчен оялып, кыенсынып куя. Шәүкәт, ул хатны укыгач, аның беркатлылыгыннан көлгәндер кебек.
Шәүкәтнең нибары бер хаты килде. Ул иптәшләрчә коры гына язылган иде. Бу кызны һич тә шикләндермәде. «Кара син аны, хат язарга яратмый икән!» — дип кенә уйлады ул.
Шәүкәткә дип, шикәр комына буталган бер банка карлыган да алып килде...

## Бер генә аваздан торган көй

Хәзер, еллар ераклыгыннан торып караганда, ул чакта ук Шәүкәтнең күңелендә кара тап бар иде кебек тоела. Шәһәрнең баш художнигы Газиз Лотфуллин белән танышкан көнне беренче тапкыр сизде моны Мәрьям.
Төзү институтын тәмамлаганчы ук, Мәрьям проект институтында эшли башлаган иде. Морат янына Газиз еш керсә дә, Мәрьямгә игътибар итми иде.
Алар 8 март көнне таныштылар. Гадәттәге тәртипне бераз бозып, группа җитәкчесе Морат Шәехзадин эшне иртәрәк бетерергә рөхсәт итте. Мастерской ишегенең тоткасына урындык аягы тыгып куйдылар. Чит кешеләрдән Газиз белән Шәүкәтне генә керттеләр.
Өч өстәлне тоташтырып, өстенә ак кәгазь җәйделәр, шампанский ачтылар, кыйммәтле конфетлар, тортлар куйдылар. Камәрия, парлап утырмагыз әле, дигән булып Шәүкәтне үз янына утыртты. Мәрьям Газиз белән Морат арасына туры килде, Моратның бик кәефсез чагы иде: нәкъ шул көннәрдә яңа институт бинасына ул төзегән проектны кире кактылар. Бинаны Мәскәүдән җибәрелгән типовой проект буенча салачаклар иде. Морат, эчендәге утны сүндерергә омтылгандай, стаканына салган шәрабны йотып кына торды. Мәрьямнең күңелен күрү вазифасы ирексездән Газизгә йөкләнде. Бу урта буйлы, түгәрәк йөзле, зур авызлы, калын иренле һәм дулкынланып торган искиткеч куе коңгырт чәчле кеше иде. Газиз чәченә ике куллап сак кына кагылганда, аның озын бармаклы матур кулында никах балдагы ялтырап китте. Күзләрендә тирән акыл чагыла, ул бик оста сөйләшә һәм бер карауда кешене үзенә ышандыра иде.
— Гафу итегез, сез Мәскәүдән яки Ленинградтан килгән бер-бер вәкилме әллә?
— Ник алай уйлыйсыз? — диде Мәрьям гаҗәпләнеп.
— Чөнки мин биредәге архитекторларның барысы белән дә таныш, тик сезне генә күргәнем юк.

— Мин архитектор түгел бит, шуна белмисездер, — диде Мәрьям көлеп.

— Кем соң сез?

— Инженер.

Газиз, житди кыяфәткә кереп, сорау артыннан сорау яудырырга тотынды: югары белемең булгач, нишләп архитектор түгел син, төзегән проектларың бармы?

— Миңа түгел, тәҗрибәле архитекторларга да эш юк әле, — диде Мәрьям. Сул ягында утырган Морат, бу сүзләрдән соң борылып карады, ләкин дәшмәде.

Газиз Мәрьямгә житдирәк эш белән шөгыльләнергә кирәклеген әйткәч, бу турыда институт житәкчеләре белән сөйләшергә вәгъдә биргәч, Мәрьямнең, вакыт табып, үзенә позировать итүен сорый башлады.

— Мин позировать итә белмим, — диде Мәрьям.

— Зарар юк. Тик сез килегез генә.

— Әллә сез минем портретны мозаика итеп ясап, берәр кибет стенасына элмәкче буласызмы?

— Кыланып карарга булыр. Ләкин башта киндергә төшерергә кирәк.

— Вакытым юк шул минем.

— Шулай да тәмам өметсезләндермәгез. Югыйсә планшетымны бирегә алып киләм дә шушында ук эшлим.

— Юк-юк, — диде Мәрьям, куркып. Ул бу егетнең әйткән сүзендә тора торган кеше икәнен сизеп алган иде инде. Бер нәрсә белән дә исәпләшеп тормас, бөтен кеше алдында портретыңны ясарга тотыныр. Шул ук вакытта вәгъдә итү дә яхшы түгел: Шәүкәт ни дип әйтер бит әле. Өстәлнең аргы башында Камәрия белән кызып-кызып сөйләшеп утырган Шәүкәткә күз салды: «Ай алла, серләре килешкән икән!» — дип уйлады Мәрьям канәгатьсезләнеп.

— Вакытым булгач, үзем әйтермен, — диде ул Газизгә.

Көтмәгәндә Морат телгә килде һәм аларның дикъкатен үзенә тартты.

— Мин, әлбәттә, Мәрьямгә проект заданиесе бирермен. — Аның тавышы карлыккан иде. — Ул аны очлап та чыгар, бәлки. Ләкин мин сине аңламыйм, Мәрьям. Кая барганыңны, үзеңне нинди язмышка дучар иткәнеңне аңлыйсыңмы син? Кара миңа мин юләргә. Архитектор исеме күтәреп йөргән кеше мин. Хыяллары тормышка ашмаган, теләкләре үтәлмәгән, эшләре юкка чыккан кызганыч адәм мин! Без институтта элекке мисалларда тәрбияләндек: классика, готика, барокко! «Һәр йорт сәнгать әсәре булырга тиеш!» Мин эшкә тотынуга бөтен белгәннәрем, барлык идеаллар, изге принциплар жилгә очты. Йортлар сәнгать әсәре түгел хәзер, аларны заводларда штамповать итәләр. Шәһәрләр төзегәндә архитекторлар дигән кешеләрне искә дә алмый башладылар. Минем диплом проектым тузан жыярга гына яраклы кәгазь булып калды.

— Тынычлан, Морат, — диде Газиз, аның кулына кулын куеп. — Синең кәеф начар бүген...

Морат кулын тартып алды:

— Бүген генә түгел. Мин кыйналырга өйрәнгән инде. Син Мәрьямне проектлар төзергә өндисең. Кемгә кирәк безнең проектлар, нәрсәгә кирәк? Минем белән бергә укыган иптәшләр һөнәрләрен үзгәрттеләр яки яңабаштан салына торган калаларга китеп бардылар. Ә мин, ахмак, хыялый, калдым. Казанны бөтенләй архитекторсыз калдырып булмый, янәсе... Үземне корбан иттем, ләкин аннан беркемгә бернинди файда булмады.

Газиз тагын аны туктатырга тырышып карады:

— Син үзеңне юкка кимсетәсең. Эшләгән эшләрең әз түгел.

— Эшмени ул! — диде Морат рәнҗеп. — Типовой проектлар өчен нигез салу! Оскар Нимейер кебек бер талантка карандаш кына очлап торсам да, мин үземне бәхетлерәк сизәр идем. Архитектураны музыка белән чагыштыралар. Әгәр бу хак икән, безнең шәһәрләрнең яңа районнары бозылган камертон авазы кебек: бар да бер генә, ул да булса ялган нота уйныйлар: до-до-до-до... — дип иренен бөрештереп, пышылдап диярлек сузып көйләде Морат. — Ә безнең көнелләрдәге моңнар тумый кала. Дөрес, мин бәлки Чайковский кебек талант түгелмендер дә, әмма Алябьев «Сандугачы» кебек бер көем булса да калыр иде. Мин үз көемне җырлый алмадым, авызымны томаладылар.

Аның күзлек астында яшь күренде, ул пыяланы сөрткән булып, шакмаклы кулъяулыгы белән яшьләрен сөртеп алды.

— Шулай, Мәрьям, Газиз сүзен тыңлама, иҗади һәлакәткә өстери ул сине. Кулыңда менә дигән һөнәрең бар, инженер син. Кит шул юлдан, миннән бәхетлерәк булырсың. Әгәр төзелештә эшләргә дәртең юк икән, Газизнең икенче киңәшен тыңласаң да ярый: натурщица булып эшлә: буй-сының, килеш-килбәтең менә дигән.

Моратның аһ орып сөйләгән сүзләрен өстәл тирәсендәге халык ишетмәде бугай: кешеләр шаулаша-көлешәләр иде. Морат янына аккордеон күтәреп Шәфикъ абый килде:

— Әллә җырлый да башладың инде, моңлы тавышың ишетелгәндәй булды. Җырласаң елатырсың, лутчы гармун уйнап биет әле безне.

— Менә тагын юкка чыккан бер адәм, — диде Морат, әче көлемсерәп. — Бер ун ел бугай инде эшләгән эше юк, кайчандыр Бохарада искиткеч биналар салдым, дип мактанып, дәрәҗәсен күтәреп йөри...

Шәфикъ абыйның исе китмәде:

— Ярый ла минем мактанырлык Бохарам бар, кайберәүләрнең искә алып сөйләрлек Бохарасы да юк бит әле.

— Хак шулай, — диде Морат. — Синнән бәхетсез адәмнәр дә бар дөньяда.

— Юкка аһ орасың. Начар архитектурадан үлгән кеше юк бит әле. Хатын-кыз бәйрәмендә икәнеңне онытма. Даманы елар чиккә житкергәнсең ич!

Морат, аккордеонны сыздырып, Тукай маршын уйнап җибәрде.

Шәфикъ абый штиблет үкчәләрен шакылдатып Мәрьямгә баш иде.

— Марш ич бу, Шәфикъ абый!

— Фокстрот биеп була бит аңа.

— Шәфикъ абзый, зинһар, үпкәләмәгез. Бу көйне генә уйнап бетерсен инде. Икенчесенә биербез.

Аккордеон моңланды, зарланды...

Уйнап бетергәч, Морат аккордеонны куеп, урыныннан сикереп торды, кабаланып ишек тоткасыннан урындыкны алды да коридорга чыгып китте. Мәрьямнән гафу үтенеп, Газиз дә аңа иярде.

Күңелсез тынлык урнашты. Ләкин озакка түгел. Нык адымнар белән, күкрәген киереп, Шәүкәт килде, аккордеон каешын беләгенә киде дә телләргә басты. «Яшьлек вальсы». Шәфикъ абзый белән Мәрьям өстәлләр арасындагы иркенрәк урынга чыктылар. Шәфикъ абзый гадәтенчә Мәрьямгә үрелеп карады, ә кыз исә биек үкчәләре белән кавалерының аягына басудан куркып, туфлиләрен сак кына шудырды.

— Ниләр сөйләде сиңа теге тәти егет? — Шәфикъ абзыйның күгәргән иреннәре калтырап куйды.

— Моратны әйтәсезме?

— Газизне сорыйм... Кара аны, гашыйк булып куя күрмә тагын. Синнән чибәрләр дә күп йөрде инде аның артыннан. Тик ул берәүгә дә карамый. Һавадагы торнага ышанып, кулыңдагы чыпчыкны очыра күрмә, Шәүкәтеңә ныграк ябыш, диюем!

Алар таралышканда кояш та баемаган иде әле. Кичке шәфәкъ тәрәзә пыялаларында кызу учаклар кабызган. Җылы бүлмәдән чыккач, коры, салкын һава калтыратып куйды. Моратның сөйләгәннәре Мәрьямгә бик нык тәэсир иткән иде, ул барысын да Шәүкәткә сөйләде. Бигрәк тә аны Моратның күзләреннән яшь атылып чыгар хәлдә ачынуы хәйран калдырган иде. Кырыкка житкән ир кеше елый... Ләкин Шәүкәтнең моңа бер дә исе китмәде:

— Артыграк салып җибәргәндер. Өстәл астыннан гына шампанскийга акны өстәгәне сизелмәдеме? «Ак аю» күздән яшьне тиз чыгара ул.

— Ни сөйлисең син, Шәүкәт? Бүген аның бик кәефсез көне бит. Проектын кабул итмәгәннәр.

— Проектының ярар җире булмагандыр, юкса кире какмаслар иде. Талантым харап булды, үсәргә шартлар булмады дип елау хәзер бер модага кереп китте инде. Ә баксаң, андый кешеләрнең тамчы да сәләтләре юк. Талант теләсә нинди шартларда да үзенә юл яра ул. Ә Моратка ходай бернинди дә талант бирмәгән. Әмма кеше арасында ни белән булса да үзен күрсәтәсе килә, мин дә бу дөньяда артык җан түгел диясе килә. Эше белән үзен күрсәтә алмагач, кызгандырып күрсәтә...

Менә сиңа мә! Моңарчы Мәрьям Шәүкәт белән Моратны дуслар дип йөри иде тагын.

— Алай димә син, Шәүкәт. Моратның соңгы эше миңа бик ошаган иде. Аны бит начар булганы өчен түгел, расходны күп ясый дип кире какканнар. Күңеле китек аның...

— Шулай шул. Үзенне сәләтсез халык массасы арасында итеп сизү кыен...

— Менә тагын: сәләтсез халык массасы — ул ни дигән сүз инде? — Мәрьям чын-чынлап гаҗәпләнгән иде.

— Дөнья халкы ике өлештән тора: талант ияләреннән — алар санаулы гына була, — һәм кара халыктан — алар бихисап.

— Генийларның шул «кара халык»ның бер кисәге булуын онытма! Халык генийны тудыра, үстерә, тәҗрибә, акыл бирә, кулына корал бирә, аны ашата-эчертә, киендерә, ниһаять! Буш урында гений туа алмый!

— Әлбәттә. Мәк чәчәге үссен өчен туфрак кирәк бит!

Бусын инде Мәрьям үзен мыскыллау дип кабул итте. Димәк, барча халык, шул исәптән Мәрьям дә (чөнки аны берәү дә һәм ул үзе дә талантлы дип әйтми әле) — туфрак, ә Шәүкәт — талант иясе — мәк чәчәге икән.

— Синең бу чагыштыруың һич дөрес түгел. Туфрак бөтен тереклек ияләре өчен зарури нәрсә. Әмма мәк туфрак өчен чәчәк атмый, ә генийлар кешелеккә хезмәт итәләр.

— Алай бик акыллы булсаң, икенче чагыштыру тап.

— Кешелекне бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Чөнки ул бөтен нәрсәне беренче тапкыр эшли. Морат та үзенчә, беркемгә охшамыйча иҗат итәргә тели. Хәзергә аңа мөмкинлек юк, ләкин ул бирешми. Күпме архитекторлар киткән инде Казаннан, ә ул һаман эшли, һаман тырыша. Аны шул идеалына тугрылыклы булганы өчен генә дә ихтирам итәм мин!

Бәхәс зурга китте. Шәүкәт үзен кимсетелгәндәй хис итте булса кирәк. Мәрьям исә Шәүкәтнең бөтен дөньяга өстән каравын ошатмады.

Ахырда Шәүкәт үзен-үзе кимсетә башлады: ярый инде, янәсе, мин синең кебек үк күп укымаган, югары белемем юк, үз акылым белән генә

фикер йөртәм, ә син китаплардан цитаталарны күп укыган кеше. Кая инде миңа синең белән тарткалашырга!

Бәхәс мондый юнәлеш алгач, килешү, уртак тел табу мөмкин түгел иде. Мәрьям саубуллашып кереп китәргә ашыкты. Алар кайчан очрашулары турында сүз дә куешмадылар.

## Портрет

Шәүкәт чыннан да үпкәләгән булып чыкты, ахры, икенче көнне килмәде. Ул бер-ике көн килми торгач, Мәрьямнең эче поша башлады. Шунда ул Газизнең позировать итәргә үтенгәнен исенә төшерде. Эрудицияле, акыллы, төпле кеше күренә. Читләтеп кенә кайбер мәсьәләләрдә аның фикерен белеп булмасмы? Бәлки, Мәрьям бик үк хаклы да түгелдер?

Ул Газизгә шалтыратты.

Шәһәрнең баш художнигы кремль янындагы горисполком бинасының икенче катындагы бүлмәдә эшли. Зур, авыр ишекләрне ачып кергәч, тимер баскычтан менәсең. Челтәрләп эшләнгән баскыч аралары баскан саен даң-доң килә. Мәрьям рәсем пумаласы, карандаш һәм каләм сурәте төшерелгән ишекне шакыды. Тәрәзәләре көнчыгышка караган кысан бүлмәдә ике зур өстәл. Стена буйларында, идәндә, өстәлләрдә, шкаф өсләрендә бихисап планшетлар, кәгазь рулоннары, мәрмәр, жиз һәм пластилин фигуралар. Шулар арасында һәр чәч бөртеге үз урынына яткан, кершәндәй ак күлмәк кигән, чиста итеп кырынган Газиз басып тора. Ул исәнләшү белән урындыкка күксел киндер тартылган рамны куйды, люстраны кабызды, хәтта өстәлдәге бра төймәсенә басып, яктылыгын Мәрьямнең битенә юнәлдерде.

— Минем бүлмәдә тиз караңгы төшә, — диде ул. — Мин килерсез дип өметләнмәгән дә идем әле. Ярый, урындык табып утырыгыз да, эшкә тотынып алайса. Сезнең вакытыгыз әздер.

— Вакыт күп, — диде Мәрьям көлеп. — Тик мин позировать итәргә күнекмәгән. Арырмын.

— Сез иркенрәк утырыгыз, кыенсынмагыз.

— Сөйләшергә ярыймы соң?

— Ярый, ник ярамасын.

Газиз күлмәк җиңнәрен сызганды, буяу банкаларын ачып, палитра әзерләргә кереште. Мәрьям алсу төстәге агач төбеннән кисеп ясый башланган сынга текәлде: бик яшь кыз, башын артка ташлап, сөенеп һәм өметләнеп югары карый.

— Бу груша төбен каян алдыгыз?

— Урта Азиядән җибәрделәр. Күптән эшли башлаган идем дә, вакыт җитми. — Газиз көрсенеп куйды.

— Бу кыз «яшьлек» дип аталган инде, әйеме?

— Өстенә бастыгыз дияргә була. «Исәнме, кояш!» дип аталачак ул.

Газиз әледән-әле Мәрьямгә карый-карый кара буяуга манылган пумала белән киндергә сызгалый. Аның сабыйларча калын иренле йөзе бик житди, күзләре үтәли күрә кебек. Мәрьям бер кавым аны беренче тапкыр күргәндәй гаҗәпләнеп утырды. Аның Морат турында сорашасы килә, әмма, сүз башласа, комачаулар кебек тоела иде.

— Ә нигә сез оформитель булып эшлисез? Художник яки скульптор эше ошамыймыни? — диде Мәрьям.

— Архитектура, шәһәрләр төзелеше — минем мәхәббәтем. Ә инде гашыйк булгач, сөйгәнем тәкәббер, миңа баш бирми, гел ялындыра, дип, яки кимчелекләрен табып кына аннан ваз кичеп булмый. Авыр

булса да сөясең. Хәер, архитектурага гашыйк кеше калада бер мин генә түгел.

Әллә шаярта, әллә чынлап сөйли шунда. Теле такылдаганны колагы ишетми булса кирәк: тавышы төссез янгырый, үзе һаман эше белән мавыккан. Сүзе дөрес инде. Менә кимчелеген таптым дип кенә Шәүкәтне ташлап кара син...

— Сезгә задание бирделәрме соң әле?

— Юк. Хәер, Моратның теге кичәдәге чыгышыннан соң мин әллә чыннан да икенче якка тайпылыйммы дип торам.

Газиз, пумаласын палитрага куеп, Мәрьямгә кызыксынып карады:

— Башта үзегезне сынап карарга кирәк. Аннары Морат ул сүзләрне аптыраган минутында гына әйтте. Ул үзен күрсәтәчәк әле. Аның канатлары сынмаган, чөнки күп эшли, күп белә, күп уйлана...

Газиз тагын эшенә тотынды.

— Ул эшләр иде дә, бәлки, мөмкинлекләр юк бит, — диде Мәрьям.

— Мөмкинлекләр дә булыр. Дөнья үзгәреп тора. — Аннары ул, Мәрьямнең уен сизенгәндәй, сүзне Шәүкәткә күчерде. — Сезнең танышыгызны сәләтле художник диләр.

— Әйе, ул талантлы кеше.

— Кызык. Мин аның эшләрен карар идем.

— Ярый, мин әйтермен аңа.

Мәрьям урыныннан торып киндер янына килде. Аңа кара буяу белән ясалган, яңак сөякләре бераз калкып торган, чөелгән борынлы түгәрәк йөз, кыйгач каш астыннан озынча күзләр карады. Кара чәч дулкынланып күзгә төшкән. Портреттагы кыз дөньяга гаҗәпләнеп һәм шул ук вакытта могҗиза көтеп карый. Нәкъ менә шул күз карашы бу рәсем белән Мәрьям көзгедә күрергә гадәтләнгән йөз арасындагы охшашлыкны шактый кимәтә кебек иде.

— Мин мондый түгел ич.

— Ашыкмагыз. Бу схема гына әле. Аннары сез үзегезне белмисез ич. Мин сезнең үзегезгә таныш булмаган якларыгызны ачып салырга тиеш, шулай бит?

Бу Газизгә һәр нәрсә ачык, аңлаешлы, һәркемнең ни эшләргә тиешлеге мәгълүм. Аның янында син дә үзеңне көчле, акыллы итеп сизәсең — аның ышанычы кешеләргә дә күчә. Шулай да ниндидер корылык бар анда. Көчле хисләр, шикләнү, газаплanулар — берсе дә аңа таныш түгел микәнни соң?

Әйткән сүзен үтәмичә калмый икән тагын, очраган саен Шәүкәтнең картинасы турында сорый торды. Шәүкәтнең мастерскойда беренче күренүендә үк, Мәрьям ана Газизнең үтенечен әйтте. Моңарчы мөнәсәбәтләрен җайлый алмый аптырабрак йөргән ике яшь кешегә бу мәсьәлә сүз башлау өчен ярап куйды тагын. Дөрес, Шәүкәт чыраен сытып кына риза булды. Шулай да Мәрьям Газизгә шалтыратты, кичкырын эш беткәч, алар өчәүләп художество училищесына киттеләр.

Шәүкәт аларны зур, шыксыз бүлмәгә алып керде. Стенада берничә картина эленеп тора иде. Бүлмә караңгы иде инде: Шәүкәт ут кабызды. Мәрьям полотноларга күз йөртеп өлгермәде, Газиз уң як кырыйдагы картинага килеп тотынды:

— Шушымы? — Ул шунда картинаны карау өчен уңайлы нокта эзләнеп, уңга-сулга чайкалды.

Чыннан да, башка әсәрләр арасында бу полотно бик нык аерылып тора иде. Җәйге айлы төн. Әле генә яңгыр явып узган, ахры, һаваның чисталыгы, үтә күренмәле булуы сизелеп тора. Юеш тротуардагы зур күлләвектә саргылт кәрнизле таш йорт чагыла. Йорт почмагына бер кыз сөялгән: аның бөтен кыяфәтеннән инде бик озак көткәне сизелеп тора. Күрәсең, ул егетен көтәдер. Йортлар арасыннан күренгән күк йөзенең итәге инде аллана башлаган...

Бу күренеш күңелдә татлы әрнү, моңлы уйлар уята. Килерме ул бәхет, килмәсме? Рамда, этикеткада: «Җиде төн уртасында», дип язылган иде.

Мәрьям артына борылып карады. Газиз күзләрен картинадан алмый. Шәүкәт маңгаена төшкән кыска чәчләре астыннан астыртын гына аны күзәтә, юка иреннәре кысылган. Бары урындык артына ябышкан бармаклары гына аның дулкынланып Газиз хөкемен көткәнен сиздереп тора иде.

Ниһаять, Газиз борылып Шәүкәткә кулын сузды:

— Котлыйм. Бу синең беренче уңышың, билгеле. Сәләтең бар, хисләрең җитәрлек. Эшләсәң, тырышсаң, рәт чыгачак синнән.

Мәрьямгә бу мактау әз тоелды. «Сәләтле» генәме соң, талант иясе бит ул Шәүкәт! Беренче уңышы, имеш. Искиткеч әсәр бит бу! Урамга чыгып, Газиз белән хушлашкач, Шәүкәтнең дә шулай уйлаганлыгы мәгълүм булды.

— Бичара дилетант! Белеп торам: көнләшүеннән шартлар дәрәҗәгә җитте инде ул хәзер. Ул үзе сәнгатькә очраклы рәвештә килгән кеше бит. Әзме-күпме сәләте булган кеше баш художник кебек административ эшкә урнашмый да инде. Иҗат итәргә көче җитмәгәч, ичмасам, начальник булып тәм таба торгандыр.

Аяк астында март аеның төнге салкыннан бозланып каткан кары шыгырдый иде. Мәрьям дәшмәде. Газизне шул рәвешле юкка чыгарып ташлагач, Шәүкәт «пластинканы әйләндерде».

— Ә ул кыз — син ул, — диде тавышын әкренәйтеп, эчке дулкынлану белән. — Мин сиңа охшатып, синең өчен яздым аны. Әгәр мин ялгышсам, адашсам, кильми калсам — көт мине! Күпме көтәргә туры килсә дә — көт, яме!

Мәрьям туктап аның йөзенә карады. Ул Шәүкәт әйтми калганнарны ишетергә теләгәндәй сагайды, чөнки сөйгәненең әйткәннәре аны ни өчендер ышандырмый, бу сүзләрдә үзенчә кылану сизелә иде.

— Әгәр инде килмәсеңне белсәм дә көтимме?

— Мин киләчәкмен. Кайчан да булса киләчәкмен.

— Дөньяда төрле хәлләр булуы мөмкин, Шәүкәт. Үзеңне гомерлеккә бурычлы итеп куйма. Минем янга килә алмаслык хәлдә булсаң, нишләрмен мин?

— Мин үзем сиңа: «Көтмә мине, мин килмәячәкмен», дип әйтермен. Юк, мин сиңа алай дип әйтмәм. Көт, яме?

Күңелләрне җилкетеп, йөрәкләрне ярсытып яз килгән чак иде. Мәрьям күңелендәге шомны куарга, Шәүкәт сөйләгәннәргә үзен-үзе ышандырырга тырышты,

## Бәхетлеләр арасында

Мәрьям Шәүкәтнең диплом яклаган чагына бармады, чөнки ул үзе бик катгый итеп:

— Син килеп йөрмә, кирәкми, — дигән иде. Шулай да Мәрьямнең йөрәге түзмәде, аудиториягә кермәсә дә, училище янына бармый кала алмады ул. Базарларда гладиолуслар, роза чәчәкләре, канәферләр сата башлаганнар иде инде. Мәрьям бөтен базарны айкап, берәмтекләп сайлап, зур чәчәк бәйләме алды. Шул чәчәкләрне күтәреп училище бинасыннан төшкән куләгәдә бик озак торды ул. Аяклары талып бетте. Шатлыктан авызлары ерылган, дулкынланудан битләре алланган дипломчылар да чыга башлады. Аларның һәрберсе Мәрьямгә игътибар белән карый, чаярак егетләр:

— Чибәр кыз, бу букет миңа түгелме? Миңа булса, бирегез тизрәк, мин аларны алырга лаеклы! — дип шаярткалыйлар да. Шайтан алгыры, алар бүген — җиңүчеләр, алар — тантана итүчеләр, таныш булмаган чибәрләр чәчкә китереп бирсә дә, бер дә гаҗәп түгел! Шуңа күрә кем дә булса аларны тыйнаксыз яки әдәпсез санар дип уйлау аларның башына да килми. Аларның дулкынлануы, ташып торган шатлыгы Мәрьямгә дә йога.

— Юк шул, сезгә түгел бу чәчәкләр! — ди ул, гафу үтенгәндәй елмаеп.

Менә ишектә Шәүкәт күренде. Аның сөмсере коелган, гадәттә киеренке иңнәре дә салынып төшкән кебек. Ул хәтта Мәрьям ягына күз дә салмады.

— Шәүкәт! — диде Мәрьям борчылып. — Әллә син һаман яклама-дың әле?

— Ә-ә, синмени бу? Әйдә, — ул Мәрьямне култыклап алды. — Эш бетте монда.

— Якладыңмыни? Алайса, котлыйм! — Ул кыюсыз гына чәчәкләрне аңа сузды.

— Ташла... Котларлык берни дә юк. — Ул чәчәкләрне кулы белән этте. — Дүртле куйдылар. — Аннары ярсып: — Син үзең күрдең бит, үзең күрдең, анда, стенада, минекенә әз генә булса да якын килгән бер әсәр дә юк иде. Шулай бит! — Мәрьям шулай дигәнен белгертеп башын иде. — Ә ул пешеп җитмәгәннәрнең күбесе «отлично» алды.

— Синең эшеңнең кай җире ошамады соң аларга?

— Рәсем ясау техникам начар, имеш. Укыганда да тырышлык җитмәде, дип, укытучысы сайрап тора. Әлбәттә, мин аның кураена биемәгәнгә үч ала. Ә үзенең өйрәтер бер нәрсәсе дә юк иде. Сәнгатькә кадалган бер сөлек кенә ул! Кагыйдәләр ятлаган да шуны тәкърарлап йөри. Үзенең ике тиенлек тә әсәр язганы юк! Шул да сәнгать әсәрләре турында фикер йөрткән була бит. Ничего, күрсәтермен әле мин аларга кем икәнемне!

Шәүкәтнең кимсенүе аңлашыла. Әмма ни өчен шул чаклы үзенне-үзең ашарга? Дүртле дә начар билге түгел бит? Мәрьям егетне тынычландырырга тырышкан саен, Шәүкәт кыза гына барды. Ике-өч көн үткәч кенә башка нәрсәләр турында сөйләшер хәлгә килде ул.

## Зәһәр Камәрия

Морат Мәрьямгә проект заданиесе бирде.

— Менә, төп магистраль урамга чыга торган өч йортка проект төзеп кара әле, — диде ул. — Алар өчесе рәттән торалар. Тышкы оформлениесен уйларга кирәк... Бу йортларга проектны Гаделшина эшләгән иде инде, безгә ул ошап җитмәде. Менә син эшләп кара, әгәр синең вариант яхшырак булса, кабул итәрләр, бәлки.

Мәрьям җилнең каян искәнен шунда ук аңлап алды: аңа задание бирүне Газиз үтенгән иде бит. Морат исә Мәрьямгә әллә ни өмет багламаса да, өстеннән бурычны төшерә, соңыннан, «Менә бит, булдыра алмады, төзү институтыннан нинди архитектор чыксын», — дип акланырга җай эзли.

Үзәк урамнардагы йортларга сметада каралганнан артыграк расход тотарга рөхсәт ителә. Бинаның тышкы күренешенә үзгәрешләр кертергә ярый, әмма эчке планировкасына кул тидерергә рөхсәт ителми иде.

Мәрьямгә нәкъ менә шушындый өч йорт эләкте дә инде. Иң элек ул йортлар салыначак урынны карап кайтты. Урамы бик киң, трамвай,

троллейбус, автобуслар йөри, җәяүлеләр дә, машиналар да агылып тора. Йортларга каршы якта бакча булачак икән.

Мәрьям ашыкмады. Әйе, гадәти биш катлы, дүрт подъездлы, 64 әр квартирлы йортлар булачак алар. Беренче катларында ресторан, китапханә һәм кием-салым кибете булачак. Өч йорт та тышкы яктан юка таш плитәләр белән тышланачак. Өченче каттан башлап һәр квартирда — балкон. Анын ниен үзгәртәсең?

Хәер, балконнарны парлап-парлап берләштерергә дә була бит. Ул чакта бер озын балкон ике гаиләгә була дигән сүз. Аны плитә белән урталай бүлеп куярга мөмкин. Балкон араларын ике рәт төсле плитәләр белән тоташтырсаң? Ни төсле булырга тиеш ул киң тасмалар? Куе кызыл төстә, билгеле.

Өч йортны бергә тоташтырып салырга була. Алар бер-берсенә икенче каттан алып тоташалар, беренче кат урыны йөрер өчен буш кала. Һәр йортка алты бүлмә, алты лоджия арта дигән сүз бит бу. Димәк, икешәр бүлмәле урынына өчәр бүлмәле булачак ул квартирлар...

Мәрьям ашыкмады. Ул озак уйланып, төрле яктан үлчәп һәм бик дәртләнеп төзеде бу проектын.

Морат, проектны күрү белән, урыныннан сикереп торды да директорга йөгерде. Дөнья аны сак булырга, үз фикерен кычкырганчы, олыраклар сүзен тыңлап карарга өйрәткән иде.

— Молодец, булдыргансың, безгә ошады бу эшең, — диде ул директордан чыккач. — Бу йортлар синен проект буенча салыныр, дип өмет итик.

Морат бу сүзләрен обстановканы исәпкә алып бетермичәрәк әйтеп ташлады: Камәрия төшке аш ашарга дип урыныннан кузгалган иде. Моратның сүзләрен ишетеп алды да: «Кая, нинди проект ул?» дип килеп тә җитте. Сүзнең әлеге шул 183—187 нче йортлар турында икәнен белгәч, чәчрәп тә чыкты:

— Бәлеш, мин бу йортларга проектны төзеп, документациясен тапшырып бетердем бит инде? Ул нинди кешене мыскыл итү ул? Каян килгән ди ул бер кеше эшен икенчесеннән төзәттереп утыру? Мин үземне мыскыл иттерергә ирек бирмәм, сигез ел инженер булып эшләгән кеше мин! — дип, аңына килә алмый торган Морат кулыннан эскизны тартып алды да, тимерле үкчәләре белән яман шыкылдап, мастерскойдан чыгып та китте.

Директор, тукта, булыр-булмас эшкә гауга куптарып йөрмә әле, бу мәсьәлә хәл ителмәде бит, дигәндер инде. Шул көннән Камәрия Мәрьямне кан дошманы итеп күрә башлады, җае туры килсә-килмәсә дә төрттерә, кимсетергә тырыша торган булды.

Атна-ун көннән Мәрьямнең проектын кабул иттеләр. Бу хәбәрне Газиз алып килде. Ул Мәрьямне коридорда очратты да, котлыйм дип, тәмам югалып калган кызның маңгаеннан йомшак иреннәре белән үбеп тә алды. Анын үбүендә туганнарча якын, үз итүдән башка берни дә юк иде.

Ул да кереп китте — коридор борылышыннан Мәрьямгә каршы Шәфикъ абзый килеп чыкты.

Ул чакта коридорда Камәрия күренмәгән иде бугай. Әллә соң бу вакыйганы Шәфикъ абзыйдан ишетте микән?

Мәрьямнең проект эшләп азапланууна да, аны кабул итүләренә дә исе китмәде Шәукәтнең. Типовой проектта кызыл тасмалар сызу һәм газоннарны ничә метр киңлектә утыртырга кирәклеген исәпләп утыру — иҗади эш түгел, хәтта кызыклы шөгыль дә түгел иде, аныңча. Мәрьям эченнән генә рәнҗеп тә куйды: бар икән, Шәукәтнең үз эше генә эш! Икенче яктан караганда, дөрес тә инде: «Джоконда» биеклегенә омтылган талант иясе янында пүчтәк эшең белән мактанып буламыни?

Мәрьямгә яңа задание бирергә ашыкмыйлар иде әле. Ә аның тагын эшлисе, эзләнәсе, табып сөенәсе килде. Шул ук җәйне Казанда революция өчен көрәштә һәлак булган геройларга һәйкәл куярга карар чыкты. Һәйкәл проектына ябык конкурс игълан иттеләр. Конкурсның ябык булуы Мәрьямне дә кулына каләм алырга дәртләндерде. Ачыктан-ачык, менә бу минем эш, дип кешегә күрсәтергә кыенсыныр да иде, ә болай аның Мәрьям эше икәнен кем белә?

Авылга кайткач та Мәрьям тик тормады: һаман уйланды, һаман эзләнде. Ялдан килгәндә ул инде нишләячәген яхшы белә һәм бу турыда Шәүкәт белән бик тә киңәшәсе килә иде. Ләкин Шәүкәт белән киңәшү дә, рәхәтләнеп сөйләшү дә насыйп булмады.

## Күпердә

Уф, нишләп бу чаклы эссе соң әле өйдә? Әллә җылыткыч батареялар артык нык кызганмы? Мәрьям, урыныннан торып, ялан аяк тәрәзә янына килде. Әйе, батареялар ут кебек, кул тидерерлек түгел.

Мәрьям тәрәзә чаршауларын ачты. Урамда шыксыз, күңелсез. Бераз җилли дә, ахры, иртәгә, мөгаен, көн суыныр. Тәрәзәгә каршы салынган ике катлы балалар бакчасының бер бүлмәсендә генә ут яна. Күрше йортларда бер генә якты тәрәзә дә юк, бар кеше йоклый, күрәсең, вакыт бик соң инде. Багана башында электр лампочкасы чайкала. Әнә урамнан егет белән кыз узып бара. Әллә соң ир белән хатын микән? Култыклашмаганнар да, бер-берсенә сыенмаганнар да, ашыгып атлыйлар...

...Көзге караңгы кичләрнең берсендә Мәрьям белән Шәүкәт урамнардан янәшә үткәннәр иде. Ләкин үзләре янәшә атласалар да, алар арасында кичә алмаслык упкыннар хасил булган иде инде.

Шәүкәт авылыннан бик нык үзгәреп килде. Хәер, читтән караган кеше моны сизмәс тә иде әллә. Әмма Мәрьям Шәүкәтнең күңелен аңларга өйрәнгән иде инде. Мәхәббәте аны Шәүкәтнең кәефендә булган бик кечкенә үзгәрешләргә дә сизгер итте. Дөрес, егет шәһәргә килеп төшү белән Мәрьям янына, проект институтына йөгереп килде. Алар кольцодагы ашханәгә кереп, ашап чыктылар. Тик Мәрьямнең тамагыннан ризык үтмәде, Шәүкәтнең дә тәлинкәләре бушамады. Аннары Болак буена чыгып, күпер рәшәткәсенә таяндылар да, яшел мүк белән капланган хәрәкәтсез суга карап тордылар. Көн җылы, һава тузанлы, урамнар шау-шулы иде. Мәрьям бер сәбәпсез көлде дә көлде. Шәүкәтнең исә йөзе җитди, күз карашы сынаулы, кашлары җыерылган иде.

— Ул кадәр кычкырып көлмә, — диде Шәүкәт ахырда түземе бетеп. — Хәерлегә түгел синең бу көлүең.

Бәхетсезлек килгәнен Мәрьям үзе дә йөрәге белән сизенде, тик акылы моны сыйдыра алмады.

Алар кич очрашырга сүз куешып аерылыштылар. Әмма эш бетүгә Шәүкәт килмәде. Мәрьям аны баскыч төбендә дә, урамда да шактый озак көтте. Ахырда, эңгер-меңгер төшә башлагач, аның янына үзе барырга булды. Без күптәнге якын дуслар лабаса, дип үзен-үзе акларга тырышты ул. Бәлки, бик ашыгыч, бик әһәмиятле эше килеп чыккандыр, бәлки, ташлап чыгып китә алмаслык кеше килгәндер. Әзме сәбәп булырга мөмкин! Будильник куеп йокларга яткан булса — ул бит юлдан килгән, арган кеше, — будильник шалтыраганын ишетмәве мөмкин. Ниһаять, будильникның бозык булып, кирәк вакытта шалтырамавы да бик мөмкин бит!

Иң яхшысы — болай газапланып йөргәнче, барып сәбәбен белү. Ичмасам, Шәүкәтне күреп, сөйләшеп тә кайтыр, бик-бик сагынды бит ул аны, көннәрен түгел, сәгатьләрен санап көтте.

Шулай да бер сылтаусыз егет ишеген барып кагарга батырчылык итмәде ул. Юл буе сылтау эзләп барса да, чуалган зиһене берни дә уйлап чыгара алмады. Акылы белән үзен ничек кенә юатмасын, күңеле тынгысыз иде аның.

Урам чатында чәчкә сатучы очрады. Мәрьям аннан зур йөнтәс, куе кызыл георгин сатып алды. Чәчкә, моңлы уйга чумгандай, авыр башын юан сабагына кыңгыр салган иде.

Мамадыш тракты дип аталган таш юллы киң урамның ике ягында да, бакчаларга күмелеп, агач йортлар утыра. Урамга алма исе аңкыган. Караңгы төшкән, ләкин баганалардагы лампочкаларны кабызмаганнар әле. Сирәк-мирәк үткән машиналар, урам өстеннән тәбәнәк кенә очкан самолетлар чамадан артык улый кебек. Биек коймалар артында чылбырга бәйләнгән тук этләр өрә. Куркыта, күңелне шомландыра иде бу урам.

Мәрьям таныш урыс капканы йодрыгы белән дөбердәтте. Ишек алдында шашынып овчарка өрергә тотынды. Шау-шуга Шәүкәтнең фатирдаш иптәше чыкты.

— Исәнмесез! Шәүкәт өйдәме?

— Өйдә, — диде егет. — Әйдәгез, керегез!

— Рәхмәт. Кереп тормыйм инде. Үзе генә чыкмас микән?

Егет кереп киткәч, Мәрьям кинәт куркуга төште. Я алла, төн җиткәч егет артыннан килү оят бит инде. Шәүкәт, бәйләнчек булды бу, дип уйламасмы? Дөрес, элегрәк булса, аның башына бер дә начар уй килмәс иде, ул Мәрьямне күргәч, чын күңеленнән сөенер генә иде дә бит... Ә хәзер Шәүкәтнең ни уйлаганын һич белеп булмый. «Китәргә кирәк,— диде Мәрьям үз-үзенә. — Күзенә күренгәч, ни әйтермен». Ләкин бераз киткәч, тагын борылып килде. Хәзер соң инде, барыбер ул килгәнне Шәүкәт белде бит.

Менә капканың авыр келәләре шалтырады, усал эт яман чыелдап куйды һәм капкадан Шәүкәт килеп чыкты:

— Нишләп бередә торасың? Әйдә керик. Закир сине чакырмадымы әллә?

Мәрьям, дулкынлануын сиздермәскә тырышудан, артык кычкырып һәм ашыгып сөйләргә тотынды:

— Юк, ул чакырган иде дә, мин кермәдем. Ашыгам, соңга калам. Безнең Дуся түтәй мин кайтканны көтми, ята да йоклый... Вакытсыз килгән булсам, ачуланма инде.

— Вакытсыз түгел... Әле ашарга гына утырган идек. Әйдә, чын, керәбез, бәрәңге ашап чыгарсың...

— Нинди бәрәңге, тәмлеме?

— Әрчеп пешергән... — Шәүкәт бераз уйланып торды. — Юк, гафу ит. Чикмәнле бәрәңге. — Аннары моңсу гына елмайды. — Ярый әле, чикмәнле иде, югыйсә тоз урынына шикәр комы салганмын...

Ул арада Мәрьям үзен кулга алырга һәм килүенә сылтау табарга өлгергән иде инде.

— Мин сездә җәй көне үк зонтигымны калдырган идем. Шуны гына алып чыгып бирсәнче. Күз бит, яңгырлар башланыр.

Шәүкәт озак көттермичә генә зонтикны алып чыкты. Караңгыда аның йөзен ачык күрә алмады Мәрьям, шулай да егет аңа кашларын җыерган кебек тоелды.

Инде китәргә дә кирәк иде кебек. Шул чак Мәрьямнең исенә келт итеп сумкасындагы күчтәнәч килеп төште.

— Бәй, онытып язганмын. Мин сиңа авылдан карлыган алып килгән идем бит. Свежий көе алып килмәкче идем, бозылыр дип курыктым. Шикәр комы белән бутарга туры килде. Мә, шикәрле бәрәңге ашагач, моны кабып чәй эчәрсең.

Шәүкәт кулларын артка яшерде:

— Юкка мәшәкатьләнгәнсең. Мин баллы әйбер яратмыйм шул.

Шәүкәт моны шундый итеп әйтте, Мәрьям кыстап торуның мәгънәсез икәнен шунда ук аңлады. Бу — егетнең аны читкә этәрүе иде. Мәрьям карлыганын кире салгач, сумкасы чамасыз авыраеп киткәндәй булды.

— Сау бул. Мин китәм, — диде Мәрьям бераз сүзсез торгач, ләкин тиз генә урыныннан кузгала алмады. Шәүкәт аның ни көткәнен аңлады.

— Бирелә бер үзең йөрергә ярамас. Әйдә, озатып куям.

Алар урам уртасыннан янәшә киттеләр. Мәрьям аны сынар өчен юри читкәрәк тайпылды, Шәүкәт исә аңа якынлашмады. Баш очыннан әледән-әле яман улап самолетлар уза, аэродром якын гына биредә. Самолет канатларында яшелле-кызыллы утлар җемелди: «Бәреләкүрмә, сак бул», — ди ул утлар.

Алар сөйләшмиләр. Мәрьямнең бер кулында сумка, икенчесендә йөнтәс чәчкә. Караңгыда ул кап-кара булып күренә. Күңелендә мең төрле уй булса да, Мәрьям сүз башларга җай тапмый, чөнки ул «яңа» Шәүкәт белән ничек сөйләшергә кирәген белми, аның өчен сүз таба алмый.

Университетның биш катлы тулай торагы каршында тирән чокыр бар. Аның төбеннән тимер юл үтә. Тулай торактан килгән сукмак белән барсаң, шул чокыр аркылы салынган тар гына такта күпергә килеп керәсең.

Күпер уртасына җиткәч, Мәрьям туктады, култыксага таянып, аска, тоныкына ялтыраган рельсларга карады. Аннары күтәрелеп Шәүкәткә борылды:

— Ни булды сиңа, Шәүкәт?

— Ни булсын, берни булмады...

Мәрьям сораштырырга кирәк түгелен дә бик яхшы белә. Ул ни генә әйтсә дә, Шәүкәтнең күңеленә хуш килмәсен дә сизә, тик тыела алмый, тагын сорый:

— Юк, нидер булган сиңа. Син бик нык үзгәргәнсең, шулай бит?

Шәүкәт бөтен гәүдәсе белән тураеп нидер әйтә башлаган иде, баш очыннан утларын җемелдәтеп самолет узып китте, мотор гүләве Шәүкәтнең тавышын күмде.

— Үзгәрү гаҗәпмени? — диде ул самолет ерагайгач. — Дөньяда мәңгелек берни дә юк. Әгәр синең миңа мөнәсәбәтең үзгәрә икән, бу бер дә гаҗәп булмаячак.

Мәрьям, аның сүзләреннән йөзен капларга теләгәндәй, кулын күтәрде. Кулында чәчкә икән. Ул шул чәчкәсе белән Шәүкәтнең яңагына сукты. Берне... икене... Егет читкә тайпылмады, хәтта йөзен дә бормады. Мәрьям аның саен үчләнеп, кинәрәк селтәнеп, яңаклавын дәвам итте. Уңлап-суллап... Авыр чәчкә шап-шоп килде... Ниһаять, чәчәк өзелеп чокырга чәчрәде, Мәрьям кулында сабагы гына калды.

Шәүкәт шәрә сабакны сак кына алды да гаҗәпләнеп карады, тик ләм-мим сүз дәшмәде. Әгәр чыннан да күңеле сүрелгән булса, ул гаепле кешедәй түзеп тормас иде... Мәрьям күкрәге белән күпер култыксасына ятты, шушы култыкса аша сикереп, аска, чокырга ташланасы, ялтырап яткан рельсларга башын бәрәсе килде аның. Ул сумкасыннан банканы алып, төшереп җибәрде, пыяла ватылган тавыш тоныкына ишетелде.

Шәүкәт гадәттәгедән басынкырак тавыш белән әкрен генә сөйли башлады:

— Еллар үткәч, син минем хаклы булганымны аңларсың әле...

— Ник еллар үткәч? Ник хәзер түгел? Ник син минем белән ачыктан-ачык сөйләшмисең?

— Хәзер син мине аңламаячаксың... Аннары сөйләшеп торуда ни мәгънә?

— Димәк... барысы да бетте?

Шәүкәт дәшмәде. Дәшмәү ризалык билгесе иде...

Мәрьям, култыксадан аерылып, беренче адымын атлады. Ул үз-үзен кулга алырга өлгергән иде инде. Алар күпердән икесе ике якка чыктылар. Бераз киткәч, Мәрьям, үксегәнен ишеттермәс өчен, йодрыгын тешләде. Бетте...

Бу хәлгә акыл күзе белән караганда, Мәрьямнең ул чактагы кичерешләренә әллә ни сәбәп тә юк иде кебек. Шәүкәт белән аларның мөнәсәбәтләре артык тирәнгә кермәгән иде. Кешеләр яшь чакта сөешәләр дә аерылышалар, үпкән-кочкан җилгә очкан...

Юк, алай түгел икән шул. Мәрьям Шәүкәтне чын күңелдән яраткан, аңа ышанган, аның булачагына тәмам инанган иде инде. Соңгы ел эчендә ул тормышын аңа гына багышлады, барлык дус-ишләреннән, якыннарыннан читләште. Яшәвенең мәгънәсен Шәүкәт белән бергә булуда, аның мәхәббәтендә генә күрә иде ул.

Хәзер Шәүкәт аның белән араны шул чаклы кинәт һәм аяусыз өзгәч, Мәрьямнең киләчәген яктырткан утлар сүнеп киткәндәй булды. Киләчәк караңгы, тирә-юньдә бушлык. Ни өчен җирдә яши ул, беркемгә дә кирәк булмагач?

Табигать хатын-кызга көч-куәтне, күңел ныклыгын ирләргә караганда ким биргән, чөнки ул аларга башка бурычлар йөкләгән. Хатыннарны балалар белән беррәттән җил-давыллардан, авырлыклардан ирләр сакларга тиеш, күрәсең.

Ир куләгәсенә ышыкланырга, кемгәдер кирәк булырга омтылмаган, кеше өчен яшәргә теләмәгән хатын-кыз — хатын-кыз түгел. Киресенчә, сөйгәне өчен, кеше өчен олы җаваплылыкны үз җилкәсенә алмаган, хатын-кызны җил-давылдан сакламаган ир-егет — ир түгел.

Егетләре ташлаган кызлар, ирләре ташлаган хатыннар үзләрен кимсеткән өчен гарьләнеп яки балаларын ялгыз тәрбияләүдән куркып еламайлар. Юк, эш бөтенләй анда түгел. Аларга үзләрен яклый, саклый, көч бирә торган кеше кирәк. Аларга тормышларын, бөтен барлыкларын багышларга кеше кирәк.

...Шәүкәт белән күпердә саубуллашмыйча да аерылгач, кайтып җиткәнче Мәрьямнең күзенә ак-кара күренмәде.

Дуся түтәй аңа ишек ачты да, үз алдына нидер сөйли-сөйли, текә, тар агач баскычтан икенче катка менеп китте. Аның бизәкле ситсыдан тегелгән итәгенә борыны белән тия язып, арттан Мәрьям иярде.

Сиксәннән узган Дуся түтәй бик таза әле, суын да үзе ташый, кибетенә дә йөгерә. Үз гомерендә ике ир җирләгән, биш бала табып берсен дә исән үстерә алмаган, картайган көнендә олы йортта ялгыз калган.

Дуся түтәй гомерен Тимоша исемле ата мәчене тәрбияләп үткәрә. Аны иркәли, пенсия акчасына аның өчен ит-сөт сатып ала, кичләрен аның көндез нишләгәнен сөйләп утыра.

Бүген Тимоша өйгә кайтмаган икән, Дуся түтәйнең шуңа кәефе юк.

Ул Мәрьям бүлмәсенең ишегенә аркылы басты да, борынын мышкылдатып (әллә елаган да инде), шул турыда сөйләргә тотынды:

— Бөтен урамны әйләнеп чыктым инде, кайларда гына йөри икән бичаракаем. Бигрәк матур, бигрәк сөйкемле иде шул, мөгаен, урамнан берәрсе тотып алып киткәндер. Ерак алып китсәләр, нихәл итәрмен! Юлны таба алмавы да бар бит әле аның!

Мәрьям мәче дигән ялагай һәм астыртын хайваннарны яратмый. Ә игә менеп кунакларга гына торган бәйләнчек, симез һәм иркә Тимошаны бөтенләй җене сөйми иде аның. Дөньяда мәче өчен яшәгән карчыкның язмышы аңа коточкыч булып күренде.

Ул бүлмәсенә керде, Дуся түтәй кермәсен дип ишек келәсен элде дә, пальтосын да салмыйча караватына ауды...

## Шәфикъ абый Бохарасы

Төннәреңне йокысыз үткәргәндәниләр генә уйлап бетермисең? Үткәннәрне искә төшерү кешегә сөйләү белән бер түгел. Сөйләгәндә кайсынберсен яшерәсең, кайсын-берсен үзгәртәсең. Ә менә намусыңнан бер нәрсә дә яшереп булмый, намусың барсына да шаһит, барын да белә.

Мәрьям дөньяда тәрәген югалтты. Ул үзен бер мәгънәсезгә, бер кирәксезгә яши дип исәпли иде. Аның эше — катлаулы түгел, гадәтләнгән эшне куллар үзләре башкара, ә уйлар һаман бер тирәдә әйләнә.

Эчтән кара көек булып янып бетсә дә, Мәрьям дигән кеше дөньяда яши иде әле. Ул элеккечә эшли, ашый, йоклый алмаса да, кичләрен урынына ята, таныш-белешләре белән сөйләшә иде. Ул хәтта үзен-үзе иҗат эше белән шөгыльләнергә дә мәҗбүр итеп карады.

Әлеге ябык конкурста катнашырга дигән нияте, инде әзер эскизлары бар иде аның. Дуся түтәйнең: «Бар икән, хатын-кыз түгелдерсең син, юбка кигән малайдыр, бөтен дөньяны чүплисең!» — дип мыгырдавына колак та салмыйча, төннәр буе катыргы, фанер, пенопласт турап, һәйкәлнең макетын ясады.

Кабер өстендә Ана тора. Ул хәсрәтле күзләрен югары күтәргән, үткән гомерендәге зур югалтуларны, авыр фаҗигаләрне, җиңү тантанасын — барысын берьюлы исенә төшергән... Әллә Мәрьямнең кайгы кичергән чагы булганга, образда трагик мотивлар өстенлек алган иде. Мәрьям үзенең проектын беркемгә дә күрсәтеп тормады, Саҗидә апага гына серен ачып, аннан макетны комиссиягә тапшыруын үтенде.

Конкурста Мәрьям проекты дүртенче урынга чыкты. Анда башка шәһәрләрдә эшләүче күп кенә художникларның һәм архитекторларның проектлары булуны исәплəгәндә, бу Мәрьям өчен зур куаныч иде, билгеле. Жюри членнары заманча итеп эшләнгән обелискларны яхшы дип таптылар. Беренче премияне архитектор Морат Шәехзадин һәм художник Газиз Фатхуллинга бирделәр.

Конкурста җиңеп чыгучыларның исемнәре ачылгач, кинәт барысы да Мәрьямне сәләтле, тырыш, архитектор булырга әллә кайчаннан лаек кеше, дип таптылар.

Нәкъ шул айны, институт бетереп Казанга килгәненә ел ярым үзгач, яшь архитектор Сухоруков квартиры юклыгын, юньле задание бирмәүләрен сәбәп итеп, Алма-Атага китәргә йөри иде. Мондый хәлләр елга берничә тапкыр кабатланып торганга, берәүнең дә исе китмәде. Морат кына үз постыннан качкан «дезертир»ны күрми дә башлады: «Әйдә, ычкын, Алма-Атада сиңа пешерелгән бишбармак суына күрмәсен!»

Сухоруковның китүе Шәфикъ абый өчен генә бик зур вакыйга булды: ул тагын Бохараны исенә төшерде. Шәфикъ абый пенсия яшенә житеп килә инде, шуңа күрә, аның эшкә омтылышы да юклыгын исәпкә алып, заданиеләрне анда-санда гына бирәләр иде аңа. Һәм ул үзе дә моны шулай булырга тиеш дип исәпли: кешене эштә яндырып үтерергә димәгән, бераз пенсиягә чыгып яшәрлеген дә калдырырга кирәк ләбаса.

Соңгы ике атнасын бернинди эшсез үткәргән Сухоруковка Бохарада салынган биналарны бәйнә-бәйнә тасвирлап бетерде ул. Аннары чаяннарның явызлыгына, арык суларының болганчыклыгына, тут җимешенең тәменә — гомумән, экзотикага күчте.

Ул бик кызып китсә, кычкырып сөйләшә башласа, Морат башын күтәреп, аңа таба күзлеген генә елтырата, Шәфикъ абый янә пышылдауга күчә иде.

Ниһаять, Сухоруков китте, Шәфикъ абыйның күзләре кызарып, пеләше күгәреп калды. Ул берничә көн аптырап, үзенә шөгыль таба алмый йөрде.

Бушаган урынга Мәрьямне архитектор итеп күтәрделәр. Бу турыдагы приказга Мәрьямнең исе китмәде, ул аның үз тормышында нинди зур үзгәрешләр китереп чыгарасын белми иде әле. Ләкин Мәрьямнең үсүен ике кеше зур вакыйга кебек кабул итте.

— Котлыйм, Мәрьям, — диде Сажидә апа, чын күнелдән сөенеп. — Яшь чакта эшләп кал. Син әллә нинди зур эшләр башкарырсың әле, күренеп тора.

Ирина Сергеевна хөрмәт йөзеннән Мәрьям янына үзе үк йөгереп керде. Ул шатлыгыннан бер урында басып тора алмый иде:

— Ну, Мәрьям, молодец! Син беренче хатын-кыз архитектор бездә. Хәзер синең эшең искиткеч булырга тиеш. Үзебезнең нәрсәгә сәләтле икәнебезне ирләргә күрсәтик әле. Әгәр юл бирми башласалар, миңа гына әйт, минутында урыннарына утыртырбыз аларны...

Мәрьямне бу чаклы күтәрүгә эчтән кайнап утырган Камәрия Ирина Сергеевнаның сүзен иң кызган жирендә бүлде:

— Бәй, моңарчы да әллә кая китә алмадылар әле ирләр. Берсенең дә миннән артык эшләре юк.

— Әйе, әйе, — диде Ирина Сергеевна, Мәрьямгә күз кысып. Ул Камәрияне надан, сәләтсез кешегә исәпли һәм хатын-кызларның дәрәҗәсен үстерүдә аңа бернинди дә өмет багламый иде. Шулай да Камәриягә дөресен әйтү хәтәр икәнен истә тотып, дипломатик ход ясады: — Менә иптәш Гаделшина үрнәгендә эшләрсең. Хатын-кызларны архитектура өлкәсендә дә тиешле югарылыкка күтәрү сезнең кулда хәзер. Бу изге эштә мин сезнең ярдәмчегез, хезмәтчегез! — диде.

## Җил уңаена

Кыш килде. Күксел болытлары, ачы җилләре, озын төннәре белән кыш килде. Мәрьямнең тәне генә түгел, күңеле дә туңа иде кебек.

Ләкин ул суыклык астында кечкенә генә өмет чаткысы яши иде әле: Шәүкәт «көт!» дигәч, ул үзе «көтмә» дигәнче Мәрьям аны көтәргә вәгъдә биргән иде бит. Әлегә кадәр Шәүкәтнең актык өметне өзәрлек ул сүзне әйткәне юк. Хәер, оныткандыр инде ул бу турыда, яисә җай тапмыйдыр, чөнки проект институтына бер генә дә кергәне юк бит. Я булмаса, мәсьәләне тәмам хәл ителгән, аралар өзелгән дип исәпли торгандыр.

Шулай да Шәүкәтне көтә иде Мәрьям. Чөнки аяусыз хакыйкатьне берьюлы аңлап кабул итә алмады ул, аның күңелендә һаман да өмет чаткысы яна иде әле: дөнья үзгәреп тора, бәлки алар арасындагы киртәләр юкка чыгар һәм барысы да рәтләнер. Бу бигрәк тә кызның, Шәүкәт аны ярата дип, күптәннән ышанып йөргәнлегеннән килә иде.

Газиз кергән иде. Художникларның «Олы Идел» күргәзмәсе ачылуын сөйләде. Аитов та үзенең «Жиде төн уртасында» дигән полотносын тәкъдим иткән булган. Юк, теге диплом яклаганын түгел, яңа вариантын. Бусы тагын да яхшырак, ди. Тик кабул итмәгәннәр, идея эчтәлеге сай, дигәннәр. Аитов шул комиссиягә ачу итеп картинасын пәке белән кискәләгән...

Шушы яңалыкларны бөтенесе алдында сөйләгәч, Газиз Мәрьямне коридорга чакырып чыгарды.

— Шәүкәтнең кәефе бик начар, — диде ул. — Аңа бик зур таяныч терәк кирәк хәзер. Аңа кая да булса китеп, дөнья күреп кайту файдалы булыр иде. Бәлки сез отпускны хәзер алырсыз?

— Бәй, Шәүкәт ялга барсын дип, мин нишләп отпускы алыйм? Анда ни катнашым бар минем?

— Соң... — Газиз бераз югалып калды. — Мин сезне өйләнештеләр дип ишеткән идем...

— Безнеме? Безнең инде күрешмәгәнгә дә ярты ел.

— Менә сиңа мә! — дип аптырады Газиз. — Миңа кемдер Аитовның туенда булдым, дип сөйләгән кебек иде. Башка Аитов булды микәнни? Да-а, хәзерге вакытта синең ярдәмең бик кирәк иде аңа. Ул юкка чыгарга мөмкин. Дуслык менә шундый чакларда сынала да инде.

Ул Мәрьямнең ни әйтерен көтте, ләкин бертөрле дә җавап ишетмәде, саубуллашып китеп барды.

Мәрьям, озак уйланулардан соң, бөтен горурлыгын артка ташлап, Шәүкәтнең хәлен читләтеп булса да белешергә дә уйлаган иде инде...

Шәфикъ абый Мәрьямне янына чакырып алды да аның инженер булып эшләгән чагындагы сызымына юан бармагы белән төртеп күрсәтте:

— Кара әле, кызкай, синең мондагы тәрәзә урыннарына рамнарың сыймый бит. Ике сантиметрын кисеп ташларга кирәк була.

Мәрьям калька өстенә иелде:

— Кая әле, кая?

Һәм көтмәгәндә колак төбендә зәһәр пышылдау ишетте:

— Аитов өйләнгән бит...

Мәрьям бөтен тәне кызышканны сизде, әмма сер бирмәскә тырышты.

— Шәфикъ абый, бу информациянең проектка ни катнашы бар?

— Мин сине бу мәсьәлә кызыксындыра торгандыр дип уйлаган идем.

— Бераз гына, — диде Мәрьям, елмаерга тырышып. Шәфикъ агай аның газаплануыннан рәхәт, тәм табып утыра иде.

Берничә көннән Шәүкәт ниндидер йомыш белән Морат янына кергән иде. Шәфикъ ага аны Мәрьям алдында башлы-күзле булуы белән котлады. Шәүкәт котлауларны рәхмәт әйтеп кабул итте. Димәк, өйләнүе хак икән.

Мәрьям иртәсен дә, кичен дә, шушы минутларда Шәүкәтнең башка берәү белән елмаеп сөйләшүен, урамнарда бергә йөрүен, башка берәүне назлап-иркәләвен уйлап, ут эчендә яна башлады. Көнчелек газапларын язмыш дошманыңа да күрсәтмәсен икән!

Ничек ул хисләр тиз туа да тиз үлә икән? Ничек инде күптән түгел яратып, ансыз яши алмастай булып йөргән кешегә бүген бөтенләй битараф буласың, ник ул егылып үлми шунда, аның язмышы сине кызыксындырмый? Икенче берәүне кочканда, үпкәндә, ул мәхәббәтең искә төшеп, ничек үзгең өзелми икән? Мәрьям моны аңлый алмады.

Соңыннан озын колаклар Шәүкәтнең өйләнү тарихын Мәрьямгә ирештерделәр. Егет авылга каникулга кайткач, бер кыз белән танышкан да, торган да, имеш. Соңыннан теге кыз бик елагач, кызганып, аңа өйләнгән, имеш.

Бервакыт алар көтмәгәндә троллейбуста очраштылар. Шәүкәт ялгызы гына иде. Мәрьям шырык-шырык көлгән, шаярган булды. Сүз иярә сүз чыкты. Шәүкәт: «Мин синең алдыңда бурычлы түгел идем, башка кеше алдында бурычлы идем», — диде. «Бәхетеңне тапкан өчен миңа рәхмәт әйт алайса», — диде Мәрьям, үчекләп.

Димәк, авылдан килгән кичне Шәүкәт Мәрьям белән юри ызгышырга теләгән икән. Ул Мәрьямнең аңа үпкәләп китүен теләгән, аерылышуда аны гаеплисе килгән, яңа танышыннан Мәрьямнең начаррак икәненә үзен-үзе ышандырырга тырышкан икән.

# Шугалак

Кич уңаенда гына Мәрьям «Чишмә» ашханәсенә барып керде. Токмачлы аш ашыйсы килгән иде аның. Ашханәдә җылы, рәхәт. Кеше дә әз иде. Чаршау артындагы патефон Зифа Басыйрова тавышы белән «Җырламыйм мин җырларымны» дип җырлый. Кискән чәчләренә чигүле калфак кадаган официанткалар сабыр һәм нәзакәтле сөйләшәләр.

Мәрьям буш өстәл янына утырды. Ашны тиз китерделәр. Ул кулына кашык алгач кына күрше өстәлдә ялгыз утыручы чибәр егетнең шоколад төсле күзләре белән очрашты. Һе-е... Кайчан керде соң әле бу егет? Мәрьям кергәндә юк иде түгелме?

Ашагач, Мәрьям тиз генә киенә алмады — гардеробтагы апа каядыр чыгып киткән икән. Менә Мәрьям янына әлеге чибәр егет тә килеп басты. Гардеробчы юан хатын алпан-тилпән килеп җитте дә Мәрьямнең пальтосын егет кулына тоттырды:

— Егеткәй, туташка киенергә ярдәм итегез!

Янәсе, ул яшь кешене культурага өйрәтә.

— Юк, юк, рәхмәт, мин үзем дә киенә алам!

Егет эре ак тешләрен күрсәтеп елмайды, аның гарәпләргә охшаган кара-кучкыл озынча йөзе бердәм яктырып, мөлаемланып китте.

— Рөхсәт итегез!

Бу игътибардан баш тарту үзе бер тәрбиясезлек булыр иде, шуңа күрә Мәрьям аның кулыннан пальтосын тартып алырга җөрьәт итмәде. Егет Мәрьямгә ишекне ачты, алар, бер-берсенә сүз дәшмичә, икесе дә кольцога таба борылдылар.

— Сез дә бу яккамыни? — дип сорады Мәрьям, бераз шикләнеп.

— Әйе, мин троллейбус тукталышына барам. Сез дә троллейбускамы әллә?

— Юк. Трамвайга.

Бераз дәшми бардылар. Янәшәндәге кеше белән сөйләшмәү уңайсыз иде, Мәрьям сүз югыннан сүз булсын дип кенә:

— Әллә сез Ленин районында торасызмы? — дип сорады.

— Әйе...

Егет Мәрьямнең ул тирәләрдә сирәк булганын белеп, аптырады. Әгәр теләсә анда төзелгән яңа кварталларга аны йөртергә, гид булырга әзер икәнлеген әйтте. Анда парк бик яхшы, менә дигән шугалак бар. Әгәр Мәрьям ачуланмаса, егет аны катокка чакырыр иде. Мәсәлән, иртәгә сәгать алтыда алар бирεдә, троллейбус тукталышында очраша алалар. Аның тавышында көлемсерәү, үртәү ишетелде. Килмәсеңне бик беләм, юри генә чакырам дигән сыман иде. Шуңа Мәрьям, юри: «Бәлки, килермен дә әле», — дип ташлады. Алар хушлашканда бер-берсен үртәгәндәй көлемсерәп баш иделәр.

Башта таныш түгел кеше белән беркая барырга теләмәсә дә, «болай җебеп өйдә яту оят, бу нинди көчсезлек, ичмасам, бер һава алыштырып кайтырга кирәк», — дип үзен-үзе ачуланып, мәҗбүр итеп, билгеләнгән сәгатькә кольцога китте Мәрьям. Урам буйлап чалбар киеп йөрергә уңайсызланды, куртка белән чалбарын кәгазьгә төреп, сеткага салды да кулына тотты.

Киче дә бик матур, әз генә вак кар сибәли, җылы, рәхәт, һава чиста.

Егет Мәрьямгә дусларча елмайды, әмма аның кыз килгән сөенечтән түбәсе күккә тигән, дип әйтү дөрес булмас иде. Алар таныштылар: егетнең исеме Вилдан икән.

Мәрьям тимераякта начар шуа. Шулай да Вилдан аны җитәкләп йөрмәде. Мәрьям ике атлады да егылды, өч атлады да утырды. Бүген генә сатып алынган яңа коңгырт чалбары белән шугалакның яртысын себереп чыккандыр, мөгаен. Ул егылуга, Вилдан әллә каян җил кебек

килеп житә, тимераяклары астыннан боз кыйпылчыклары чәчрәтеп, кырт борыла, Мәрьямнең култык асларыннан күтәреп аягына бастыра да тагын юкка чыга. Аның үзен шулай иркәле тотуы ошамады Мәрьямгә: димәк, Мәрьям ана һич тә комачауламый, димәк, ул Вилдан каршында бурычлы да түгел.

Хәрәкәттә бәрәкәт, дигәндәй, егылсаң да, тезләр күгәрсә дә, саф һавада, актыда, кеше арасында уралып йөрү күнелен күтәрде кызның. Аның күзе ачылгандай булды. Вакыт та тиз үтә икән монда.

Әнә Вилдан тимераягын салган, биек көрткә баскан да аңа кулын болгый. Мәрьям, ул төшкә барып житкәнче тагын бер-ике тапкыр утырып алды. Ә Вилдан рәхәтләнеп көлә:

— Их син, аю баласы!

Алар киенү бүлмәсендә өсләрен алыштырдылар, тимераякларын тапшырдылар.

Вилдан Мәрьямне озатып тормады, троллейбуска утыртты да жибәрде.

Шугалакта берничә тапкыр булдылар алар. Ә берсендә, шимбә көнне, шактый салкын иде, Вилдан Мәрьямне чәй эчеп, жылынып чыгарга чакырды. Мәрьям аның тыйнак бер егет булуына тәмам ышанган иде инде: баш тартып аны кимсетергә теләмәде. Вилдан яна йортларның берсендә, дүртенче каттагы бер бүлмәле квартирда тора икән.

Шулай итеп, Мәрьям беренче тапкыр киләчәктә үзе хужа булачак квартирның бусагасын атлап керде.

Гөлт итеп ут кабынуга, Мәрьям үзен ожмахка кергәндәй хис итте. Өй жылы, чиста иде. Яшькелт стеналарда эре-эре көзге яфраклар сурәте. Тәрәзәдә яшелгә ак-кара сызыклар белән каеннар төшерелгән чаршау. Бер як стенада идәннән түшәмгә чаклы китап шкафлары. Икенче якта секретер, янәшәсендә диван-карават. Уртада ялтырап торган өстәл, диванга каршы якта радиола һәм телевизор. Гомумән, бу йортта белемле, культуралы, зәвыклы, яшәүнең тәмен белгән кеше торганы әллә каян сизелә иде.

Дуся түтәйнең Мәрьям торган кысан, салкын, караңгы, шыксыз бүлмәсе бу квартир белән чагыштырганда эт оясы кебек иде. Вилдан Мәрьямнең өстен салдырып, диванга утырырга тәкъдим итте, иннәренә жылы джемперын салды, каршысына өстәлгә рефлектор китереп куйды.

Йомшак диванда, йөзеңне жылы нурларга куеп утыру искиткеч рәхәт иде.

— Әз генә сабыр ит, хәзер чәй пешерәм, — диде Вилдан.

— Озак буламы соң ул?

— Унбиш минут. Ә син, теләсәң, китап карый тор.

Вилданның китаплары бихисап икән. Кызыксыну Мәрьямне урыныннан кузгатты. Китапларның күбесе букинистлар кулыннан да узган булырга кирәк, нык таушалган, күп укылган. Калын-калын томнар. Кызык... Конан Дойль. — «Шерлок Холмс мажаралары», Ефремов. — «Андромеда томанлыгы», Лев Шейнин, — «Тикшерүче язмалары». Мәрьям киштәдән киштәгә үрелде, ләкин бөтен шкафны санаклы кешеләр, Марстан килгән коточкыч хәшәрәтләр, мәкерле һәм хәйләкәр жинаятьчеләр, аларны аулаучы шулай ук хәйләкәр һәм акыллы милиционерлар һәм полицейскийлар тутырган иде. Кешене мавыктыра һәм күңелгә шом сала торган хыялый дөнья... Аек килеш төш күрсәтә торган әфиун, татлы агу, укучының гомерен кыскарта торган агу. Мәрьям житди әсәрләр, һич булмаса квартир хужасының эшенә бәйле справочниклар табарга өметләнеп, өске киштәләргә үрелер өчен, йомшак креслога менеп басты һәм шул ук минутта Вилданның тавышын ишетте:

— Шәпме минем китапханә? Күргән кешенең исе китә. Китап сорап жаныма тияләр... Ә бирсәң, кайтарып алуны өмет тә итмә... Шулай да

мин синең хакка кешегә китап бирмәм дигән антыма хыянәт итәргә риза... Теләгәненне сайлап ал, рәхим ит.

Мәрьям креслодан төште.

— Сайламадым әле. Ә бусы ни тагын? — Ул Вилдан кулындагы сәер тартмага төртеп күрсәтте. Ул тартма китапханәләрдә каталог салып куя торган шкафка охшаган иде.

Вилдан шкафчыкны өстәлгә куеп, тартмачыкларны берәм-берәм ачып күрсәтергә тотынды.

— Яле, иснәп кара әле!

— Чәй.

— Ә бусы?

— Бусы да чәй ич, — диде Мәрьям, гаҗәпләнеп.

— Ә сорты нинди?

— Чәй булгач, барыбер түгелмени?

Мәрьям исә чәй сортларын исе белән дә, төсе белән дә аермый иде.

— Һи-и, чәй эчүнең ләззәтен белмисең икән син! Я, кайсын пешерим сиңа?

Кыз тәвәккәлләп бер тартмачыкка бармагы белән төртте:

— Менә бусын!

— Һи-и, чәйнең дә иң тәмсезе ич бу, Краснодар чәе! Юк, бу мәсьәләдә минем зәвыкка ышанырга туры килә инде сиңа болай булгач, — диде Вилдан горурланып һәм тартмасын күтәреп, ялтырап торган очлы башлы ботинкалары белән кәс-кәс басып, кире кухняга кереп китте. Бу ботинкалар аның куе зәңгәр йоннан бәйләнгән спорт костюмына шул кадәр ятышсыз иде ки, Мәрьям ирексездән көлеп җибәрде. Чын балачага икән бу Вилдан! Киеме дә, кыланышы да, укыган китаплары да яшүсмер малайларныкы кебек! Мәрьямгә күңелле булып китте. Ул Вилдан әзерләгән чәйне дә: «Ай-һай тәмле, мондый чәй эчкәнем юк иде әле», — дигән булып эчте. Вилдан аның сүзенә чын күңелдән ышанып: «Мин бит берничә сортны бергә кушып пешердем, шуңа тәмле ул», — дип мактанып утырды.

Чәйдән соң Вилдан пластинкалар уйнатты. Ул чәй белән генә мавыкмый, анда бер тумбочка эстрада пластинкалары да бар икән. Бу музыка да кешене уйлардан арынып, мәлҗеп утырырга, я булмаса тып-тын басып биергә өнди иде.

Мәрьям урыныннан кузгалгач, егет аны тагын утырырга кыстамады, шулай да кызның кәефе кырылмады, ул күтәренке күңел белән кайтып китте.

## Туйлар

Ниһаять, 187 нче йорт салынып бетте. Эштән соң Мәрьям ул йортны тагын бер карап кайтырга булды. Кешеләр күчеп килгәч, әчендә җан кергәч, ничек күренә икән...

Караңгы төшкән иде инде. Яңа тапшырылган йортның тәрәзәләре якты. Абажурлар, люстралар әләргә өлгермәгәннәр әле, лампочкалар күзне камаштыра. Тәрәзә пәрдәләре дә юк — кешеләрнең әрле-бирле йөргәне, өстәл янында көлешеп утырганнары аермачык күренеп тора.

Ирексездән шушы ыгы-зыгыга катнашасы, шул бәхетлеләр арасында буласы килә.

Мәрьям якындагы гастрономга йөгерде. Кесәсендәге бар акчасын кырып-себереп, бер тартма торт, бер шешә шампанский алды. Бу аның да олы бәйрәме, аның тормышка ашкан беренче проекты, беренче җиңүе ләбаса!

Ул кире килде, бераз уйланып торды да 55 нче квартирга керергә булды — Вилдан да 55 нче квартирда тора бит.

Эчтә бер дә тавыш-тын ишетелмәде. Шакыгач, озак көттермәделәр тагын, кемнеңдер каты-каты басып килгәне ишетелде. Ишекне таза гәүдәле, киң җилкәле, ак чырайлы, егерме биш тирәләрендәге кеше ачты.

— Рәхим итегез! — диде ул, ачык елмаеп.

Күрәсең, бүген аларга квартирны, газны, суны, электрны тикшерергә дә бик күп комиссияләр кергәндер. Шуңа күрә бу таза егет ят хатын-кызны күргәч бер дә гаҗәпләнмәде.

— Сезне яңа йорт белән котлыйм! — диде Мәрьям, күчтәнәчләрен сузып. Егет бу юлы аптырабрак калды. Нишләргә белми бераз уйланып торгач, төргәкне кулына алды да тавышын күтәребрәк:

— Зөлфия! Кунак килде! — диде.

Кухня ишеге ачылып, аннан кара кашлы, сипкелле йөз күренде. Ул, кунакны танымагач, аптырап егеткә карады.

Квартир нәкъ Вилданныкы шикелле, бер бүлмәле, озынча, кухня ишеге бүлмәгә чыга. Бүлмә буп-буш, бары бер почмакта матрац, юрган һәм ак тышлы мендәр ята. Алай да кухняда өстәл бар икән, аның янына ике чемоданны бастырып куйганнар.

— Гафу итегез, борчыдым, — диде Мәрьям. — Мин бу йортның проектын төзегән идем... Мин — архитектор.

Хуҗалар бердәм елмаештылар:

— Менә күрдеңме, Зөлфия, шулай була ул, — диде егет. Аннары Мәрьямгә борылды: — Ул әйтә, әйдә, бүген күчкәнне берәүгә дә әйтмик, кызык итик әле, ди. Кеше килсә, тегесе-монысы кирәк, әзерлисе-җыясы була... Өй туен бәби туе белән бергә үткәрербез дигән идек.

Түм-түгәрәк гәүдәсен мамык шәлгә ураган Зөлфия оялып башын иде, «ни сөйлисең инде» дигәндәй, куе керфек астыннан гына иренә үпкәле караш ташлады.

— Әйдә, утырыгыз, — диде ир кеше бер чемоданга ымлап. — Мине Рифкать диярсез. Сездән мондый зур күчтәнәчләр алу яхшы түгел түгелен. Ну, раз алып килгәнсез икән... Кире күтәртеп җибәреп тә булмый. Әле үзебез дә нидер җитмәгәндәй аптырашып утыра идек. Шулай бит, Зөлфия? Мин тагын, аңа ярамый дип, аны-моны алмадым. Ымсынып куяр да, мин әйтәм, зарары тияр. Нечкә нәрсә бит ул хатын-кыз.

Рифкать бик җор, телгә оста һәм кыю гына егет икән. Ә тыйнак Зөлфия исә ире сөйләгәннәрдән читенсенгәндәй башын иеп утыра. Аның бәхетле, тыныч икәне күренеп тора иде.

Ярый әле, Зөлфия чәйнек һәм ике стакан тыгып килгән икән.

Рифкать шампанский шешәсен шарт иттереп ачты да, шәрабның беразын юри стенага сиптергәч, стаканнарга салды.

— Башта сез котлагыз өйне, аннары мин җитешермен. Син, Зөлфия, стаканы белән каплый күрмә тагын, миңа да калдыр.

— Күбек кенә ич ул!

— Ничу, ничу! Киләсе ел шушы вакытта шешәсе белән каплап куйсаң да сүзем булмас.

Зөлфиянең бите алланды, ул кыюланып, ачылып китте. Бераз карлыкканрак тавыш белән шатлыгын сөйләргә кереште:

— Һаман ышанып бетмим әле. Торып-торып, төш түгел микән бу, уянмасам ярар иде, дип куям. Бала белән кеше өстендә торырга туры килсә нишләрбез, дип курыккан идек. Бүген Рифкать ачкыч алып кайткач та, ышанмыйм, дим, хак булса әйдә тизрәк кереп утырыйк, дим. Такси белән килдек. Әйберләрне иртәгә алып килсәк тә ярар. Искиткеч бит бу! Ваннасы, кухнясы, кайнар суына чаклы торба белән киләчәк.

— Планировкасы бик үк уңайлы түгел инде, — диде Мәрьям гафу үтенгәндәй. — Безгә әчке планировканы үзгәртергә ярамый шул.

— Что сез, что сез! — Зөлфия кулы белән нәфис хәрәкәт ясады. — Бу төшкә чаршау элсәк, монда Рифкать үзе идәннән түшәмгәчә шкаф ясап куяр, бик оста ул андый эшкә...

— Мебелегез бармы соң?

— Юк әле. Хозяйка караватында йоклый идек...

— Хәзергә идәндә йоклап торсак та ярый, — дип сүзгә кушылды Рифкать. — Егылып төшмәскә ару була ул. Бигрәк тә мондый чакта...

Тагын чемоданнарына утырдылар. Электр плитәсендәге чәйнек кайнап чыккан икән. Стаканнардан пешә-пешә баллы су эчтеләр — яшьләр шикәр алып килгәннәр, тик чәйне оныткан нар икән.

— Безнең йорт башкаларга охшамаган, — диде Зөлфия. — Балконнары иркен, матур... Сезнең профессиягез бик яхшы. Эшегез күңелле, мавыктыргыч, иҗади эш. — Аннары беркатлы итеп өстәп куйды: — Сез би-ик, би-ик бәхетледер?

— Әлбәттә! — диде Мәрьям, елмаеп.

Шактый вакыттан урамга чыкканда да елмая иде әле ул. Ә тышта кыш шәһәр урамнарын бизәп куйган. Мәрьям бу хозурлыкны ничек моңарчы күрмәгән соң әле? Аяк астындагы кар асылташлар сибелгән ак келәмгә охшаган. Кешеләр һәммәсе, әкияттәге патша балаларыдай, күзләрне камаштырып ялтыраган келәмгә басып узалар. Урамдагы яшь агачлар кардан ясалган кебек, ап-аклар, ә күктән ут яктысында җемелдәп, бәс коела. Башны күтәреп күккә карасаң, сирәк йолдызларны күрәсең, җиргә бәс түгел, йолдыз кыйпылчыклары коела кебек.

Урамның ике ягында да рәткә тезелгән саргылт фонарьлар яна. Йортларның эченә җан кергән — барлык тәрәзәләрдә ут балкый.

Кайчак кешеләр дә шулай була бит: карап торуга әллә ние дә юк кебек, берчак йөзе балкып, күзләре нурланып китә, аның тирән хисле, нечкә күңелле, сизгер акыллы кеше икәнен аңлыйсың һәм борыны почык, авызы зур булуына игътибар да итмисең.

Кичке шәһәр дә шулай. Аның житешсез якларын төн пәрдәсе каплый. Ә утлар яктысында тынгысыз тормыш, якты өметләр, уйланулар, сөенечләр күзгә ташлана.

Мондый кичләрдә күңелне гаҗәп бер талпыну биләп ала, үзеңдә таулар кичәрдәй көч сизәсең, зур, изге максатка омтыласың килә.

Мәрьям янында якын кешесе булуын теләде, дөньяның хозурлыгына аның белән бергә сокланасы, серләрен сөйлисе, хыялларын уртаклашасы килде. Әмма андый кешесе юк иде шул аның. Ул тормышында зур үзгәрешләр кичергән, ләкин ире — таянычы янында булганлыктан, шул үзгәрешләрне тыныч каршы алган Зөлфияне исенә төшерде, аны үзе белән чагыштырып карады. Һәм үзен ялгыз, ятим хис итте...

Җитмәсә, соңгы көннәрне Вилдан да күзгә күренми башлады. Үзара мөнәсәбәтләр гади, дустанә генә булса да, соңгы ике-өч ай эчендә ул инде аңа шактый күнеккән иде. Дөрес, аларның танышлыгы шул шугалакка, кино, театрга бергә йөрүдән узмады. Үзара мөнәсәбәтләр турында авыз ачып бер сүз сөйләшкәннәре юк. Язмышымны шушы аз сүзле, тыйнак һәм сабыр егет белән бәйләрмен, дип Мәрьямнең башына да килгәне юк иде. Була бит шундый кешеләр, ул янында чакта син ялгыз түгел кебек, янында булмаса, аны һич юксынмыйсың. Бары тик үзен япа-ялгыз дип хис иткәнгә генә, Мәрьям аның инде ике атналап күзгә күренмәгәнен исенә төшерде. Кайчандыр Вилдан аңа эш урынындагы телефонын язып биргән иде: шалтырат әле миңа, янәсе, мин... бәлки... киногa билет алып куярмын. Бүген шуны хәтерләп, Мәрьям таушалып беткән кәгазь кисәген сумкасы төбеннән табып алды.

Иртәгесен Мәрьям Вилданның эш урынына — бер заводның конструкторлар бюросына шалтыратты һәм «инженер Закиров бюллетеньдә» дигән җавап алды.

Шул ук кичне Мәрьям Вилданның хәлен белергә китте. Ул егетне урын өстендә ярдәмсез ята торгандыр дип күз алдына китергән һәм ялгызы бит, чәй кайнатып эчерүчесе дә юктыр дип кызганган иде. Бераз гына арттырып җибәргән икән. Муенына эре шакмаклы җылы шарфын ураган Вилдан бер дә алай хәлсез кешегә охшамаган иде. Ул Мәрьямне күргәч сөенде, бераз гына карлыкса да, матур, калын тавышы белән аңа рәхмәт әйтте.

Бу юлы Мәрьям: «Юк, утырып кына тор, син авыру бит, үзем барын да табам», — дип өстәлне үзе хәстәрләде. Буйдак хуҗалыгында күп нәрсәләр җитми икән. Гомумән, кухняда тәртипсезлек хөкем сөрә иде: чынаяклар чәйдән саргайган, мельхиор калаклар күгәргән, тәрәзә төбендә каткан ипи сыныклары ята. Ярый әле, Мәрьям күчтәнәчкә дип конфет алып килгән иде, югыйсә чәй эчәргә шикәре дә юк икән егетнең.

Чәй эчәргә җае булмаса да, мәе табылды тагын. Егет, мин чирле кеше бит, даруланырга туры килә, син дә грипп йоктырма, чарасын күреп, алдан дезинфекция ясыйк, дигән булып, өстәлгә моңарчы Мәрьям күрмәгән шешә китереп куйды: «Салхино». Мәскәүдән бик якын танышы алып кайткан икән.

— Синең исәнлеккә, — диде Вилдан, чынаягын күтәреп (рюмка дигән нәрсә аңарда, билгеле, юк икән).

Шәраб тәмле булып, җиңел эчелсә дә, буыннарга нык суга торган булып чыкты... Чәйдән соң диванга янәшә утырып, Вилданның фоторәсемнәрен карадылар. Ул аларны альбомга тезмәгән, пакетларда гына тота икән. Вилдан үзенең төрле шәһәрләрдә командировкага йөргәннәре турында бик кызык итеп сөйләде.

— Беләсеңме кыслаларны ничек тоталар диңгездә?

— Ничек?

— Менә шушындый, — ярты метрлап ара күрсәтте, — бау кисәге аласың да яр буена утырасың. Су астында, ярдагы тишекләрдә менә мондый-мондый кыслалар оя коралар. — Вилдан йодрыгын күрсәтте. — Әлеге бауны шундый оя турына төшерәсең. Кысланың ачуы килә бу селкенеп торган баута. Кыскычлары белән — цап! Нәкъ шул минутта бауны җәһәт кенә тартып аласың — кысла ярга килеп төшә.

— Бәй, ник соң ул кысла бауны ычкындырмый? — диде Мәрьям, гаҗәпләнеп.

— Өлгерә алмый, күрәсең!

Вилдан андый кызыкларны бик күп белә икән. «Күбесен мажара китапларыннан укып беләдер инде», — дип уйлады Мәрьям. Алар янында яшел абажурлы торшер гына яна. Бүлмә почмаклары серле күләгәләргә яшеренгән. Җылы, рәхәт. Мәрьям үз иңбашына Вилдан иңбашының тиеп-тиеп киткәнен тоя.

Вакытның соң икәнен белсә дә, Мәрьям Вилданның сүзен бүләргә җай тапмый утырды. Бу рәхәттән салкын урамга чыгарга кирәген уйлау белән бөтен тәне чымырдап китә иде аның. Чыгуга аның битенә усал җил бәрер. Хәзер троллейбуслар да сирәк йөри торгандыр. Мәрьям тукталышта ялгызы көтә-көтә туңып бетәр (авыру Вилданнан үзен озатырга рөхсәт итә алмый ич инде ул!). Троллейбуста кеше берәү-икәү генә булыр. Башына иске шәл ураган кондуктор, аягын электр миченә куеп, бөрешеп утырыр һәм йокымсырап түнеп-түнеп китәр. Андый чакта троллейбус бик әкрен баргандай тоела. Ниһаять, кольцога җиткәч, Мәрьям троллейбустан төшәр дә, үз күләгәсен үзе куып, үргә каршы йөгерер. Дуся түтәй аңа ишекне ачкач, «Әле генә, яна гына ятып, җылынып йокыга гына киткән идем», — дип сукраныр. Шулай итеп Мәрьям чолан кебек шыксыз бүлмәсенә кайтып керер...

Менә, биш минуттан чыгам, тагын ун минут кына утырыйм, ди торгач, сәгать бер җитте. Сиңа кирәкмәгән чакта сәгать телләре бик җәһәт йөгерәләр шул алар!

Мәрьям, ниһаять, урыныннан кузгалды.
— Миңа китәргә вакыт. Болай да соңга калып беттем.
Вилдан матур күзләре белән Мәрьямгә тутырып карады. Аның ялгыз каласы килмәгәне күренеп тора иде.
Мәрьям кечкенә, кысан коридорга чыгып, чөйгә үрелгән иде, Вилдан аның пальтосын үзе алды, әмма кидермәде, кире элеп куйды да Мәрьямнең иңнәреннән кочты. Мәрьямнең йөрәге шашып типте, ул карышмады. Вилдан кыенсынып, кызарынып кызның күзләренә карады һәм әкрен генә:
— Бәлки... калырсың? — диде. — Бу салкында кая барасың. Троллейбуслар да сирәк йөри хәзер. Аннары... кем көтә анда сине? Хозяйкаң ачуланыр да әле. Чирле кешене ялгызын ташлап китү дә яхшы түгел...
Мәрьям «юк-юк» дияргә авызын ачкан иде, Вилдан аңа каршы әйтергә ирек бирмәде, коры, эссе иреннәре белән аның иреннәренә орынды. Кыз аны этмәде, читкә тайпылмады, әйтәсе сүзен дә әйтә алмады.
«Барыбер түгелмени? Кем өчен сакларга тиеш соң мин үземне? Кемгә кирәгем бар минем?»
Һәрхәлдә, ул Вилданга кирәк иде — һәм ул калды.
...Ул кыска гына вакытка әллә йоклаган, әллә онытылган иде, кинәт сискәнеп айнып китте дә, күңеле нилектән шомланганны аңларга тырышып, күзләрен зур ачкан хәлдә шактый вакыт хәрәкәтсез ятты. Аның янында гына, ак тышлы юрганы астыннан борынын гына чыгарып, Вилдан изрәп йоклый. Мәрьям үзенең хәзерге хәле турында уйларга курыкты, ул нинди булса тавыш ишетергә теләп, сагайды, ләкин колаклары чыңлаудан башка бернинди аваз да ишетмәде.
Көн яктырып кына килә иде, күрәсең, тәрәзә пәрдәләре аша саран яктылык саркый. Бүлмә күңелсез һәм моңсу төсле тоела иде. Ләкин иң гаҗәбе һичнинди тавыш ишетелмәү иде; әйтерсең, бөтен нәрсә хәрәкәттән туктаган, хәтта вакыт бер мизгелдә тукталып калган.
Мәрьям Вилданны уятмаска тырышып, сак кына урыныннан кузгалды һәм пәрдәләрне ачып тышка карады. Соры, күңелсез иртә икән, урамнан бер ир кеше ашыгып узганы күренде, ул мамыкка баскандай шыпырт атлый иде.
Мәрьям тәрәзә пыялаларына күз төшерде һәм... өч кат рам күрде. Әйе, әйе, биредә тәрәзәләр гадәттәгечә ике генә катлы түгел, өч катлы иде...
Диван пружиналары шыгырдап куйды. Вилданның бераз карлыккан, ләкин ягымлы тавышы:
— Нишлисең син анда? — дип сорады. — Тәрәзә янында торма, салкын тидерерсең.
— Тидерер инде, өч кат рам белән... Бу йортның бар тәрәзәләрендә дә шулаймы ул?
— Булыр инде. Үзем куйдырдым мин аны. Югыйсә бик әшәке тавыш бит. ТЭЦ бер уфылдап куйса, котыңны алыр. Ә болай ныгыткач, тыныч... Я, торма анда, кил бире, нәрсәгә сиңа дөнья шау-шуы?
Берничә көннән алар язылыштылар. Институттагылар бу вакыйгага хәйран калды — алар Мәрьямнең Шәүкәттән соң кем белән булса да дуслашканын белми дә калганнар иде. Шулай да туйны шау-шулы, күңелле итеп үткәрергә тырыштылар. Сәҗидә апа әллә нинди хикмәтле торт пешереп китерде. Ирина Сергеевна местком исеменнән хрусталь графин белән рюмкалар бүләк итте. Калган кунаклар биш будильник алып килделәр. Март башы гына булуга карамастан, озын аяклы Морат каяндыр сирень чәчәкләре эзләп тапты. Целлофанга төрелгән күгелҗем тәлгәшләр бик зәгыйфь булып, алардан сизелер-сизелмәс кенә җир исе аңкый иде.

Мәрьямнең бит алмалары уттай янды, үзе шырык-шырык көлде. Нindидер көлү бизгәге тотты аны. Нәкъ шундый чакта Шәүкәт ака:

— Хәерлегә түгел синең бу көлүең, — дигән иде.

Бу юлы кунаклар аны сөенечтән көлә дип уйладылар, күрәсең. Чама белән генә дулкынланган, тыныч Вилдан аны-моны сизмәде.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

# Апрель

Ә аннары, аннары ниләр булды соң әле? Үзенең хаклыгына шикләнерлек, хатасын искә төшереп йөзе кызарырлык нәрсә эшләде Мәрьям?

Хәзер менә төн караңгылыгына күзне төбәп, үзенә-үзең генә сөйләгәндә, аннары узган биш ел эчендә андый вакыйгалар булмаганын күрәсең. Әйе, булмаган, чөнки ул бер дә искитәрлек эш кырмаган. Кызганычка каршы, күп очракларда гаиләдә тыныч тормыш — кызыксыз тормыш була шул.

Хәер, ул елларны әллә ни эш кырмавына Мәрьямнең акланырлык сәбәбе дә бар: ул әни булды, аякка бастырганчы, Фәйрүзәсен үстерде. Эшен дә ташламады, тик эше һаман бертөрле, кызыксыз иде: типовой проектларга нигез проекты ясау. Тыныч, гаугасыз, жинел эш.

Әйе, биш ел яшәлгән, юньләп искә алырлык берникди вакыйга булмаган. Әллә ялгыш санымы ул, әллә яшәлмәгәнме ул көннәр? Биш ел гомер кесәдән төшеп калган акча кебек юкка чыккан. Алар истәлеге булып тик дүрт яшьлек Фәйрүзә генә калган.

Искә алырлык, онытылмаслык вакыйгалар яз башында, апрель аенда булды...

«Чулпан» кинотеатрына Мәрьям проекты буенча реконструкция ясала иде. Ул реконструкциянең проект буенча эшләнәме икәнен карар өчен кинотеатрга керергә күптән җыенып йөри дә, һич вакыт табылмый: иртән эшкә ашыгыла, «Чулпан» троллейбус тукталышыннан ерак, төшеп йөрисе килми, кичен Фәйрүзә янына дип омтыласың. Ә эш сине көтми, төзүчеләрнең проектлар белән бик исәпләшми торган гадәтләре бар. Кереп карамый һич ярамый иде.

Мәрьям, эштән бераз иртәрәк китеп, «Чулпан»га кереп чыгарга булды.

Көн болытлы, күңелсез иде. Өстән, янгыр дисәң яңгыр түгел, кар дисәң кар түгел, салкын дым ява. Мәрьямнең өстендәге юка күксел пальтосы каралып киткәндәй булды, әллә ни салкын булмаса да, туңдырды.

Кинотеатрның вестибюленә барып кергәч, ул пальтосын каккалап караган иде дә, кулы гына чыланды. Вестибюльдә тәртипсезлек, стеналары сыланмаган, идәне җимерек хәлдә. Борынны ярып юеш акбур исе, буяу исе аңкый.

Эчтән, тамаша залыннан, команда биргәндәй кычкырган һәм шакылдаган тавышлар ишетелә. Мәрьям ярым караңгы фойе аша шунда узды.

Тамаша залы куе зәңгәр түшәмдәге сөт төсле плафоннарга тезелгән сирәк лампочкалар белән генә яктыртылган. Мәрьям килеп кергәндә, ике ир кеше стеналарга чаршаулар элеп маташалар иде. Берсе биек баскычка баскан да чаршауларны түшәм астына беркетә, икенчесе чүпрәкне астан тартып, рәтләштереп йөри. Чаршаулар ямьсез сары төстә, ә түшәмне куе зәңгәргә буяганнар. Моны күреп аптыраган Мәрьям, исәнмесез диясен дә онытып: «Нишлисез сез?» — дип кычкырды.

Аста торучы яна гына мыек чыга башлаган егет икән, бит урталарын чокырайтып елмаеп карады:

— Ничек, нишлибез? Күрмисезмени, ремонт ясыйбыз лабаса!

— Реконструкция проект буенча эшләнергә тиештер лә. Түшәмне күксел төскә, стеналарны алсуга буярга кирәк иде. Ә сез горчица төсле чүпрәк эләсез.

— Безгә соң, безгә проект ни дә, ни ни. Безнең эш нәчәлство кушканны эшләү. Әнә, директор белән сөйләшегез.

Моңарчы бу әңгәмәне баскычның югары аратасына утырып тыңлаган җирән чәчле егет, авызындагы кадакларын чыгарып, иптәшенә дәште:

— Ташла әле, Юра, шул телгә салынуыңны. Әйдә, эшне бетерик тә кайтып китик тизрәк.

— Юк, — диде кычкырып Мәрьям. — Хәзер үк төшегез аннан! Мин сезгә бу эшне дәвам итәргә рөхсәт бирмим!

— Сез каян килгән начальник соң әле? — диде җирән чәч, аның катгый тавышыннан шиккә төшеп.

— Архитектор мин.

Мәрьям, егет моны ишеткәч тә, эшен ташлап, аның янына йөгереп төшәр, дип уйлаган иде дә, егет авызын гына кыйшайтты:

— Подумаешь! Безнең андый начальнигыбыз да бар икән әле! Кара син аны, тагын бер команда бирүче килгән. Әнә, директор биредәдер, керегез дә аңа команда бирегез. Ә безне тоткарламагыз. Без сдельно эшлибез.

Ул чүкечен күтәреп, кадак кага башлауга, Мәрьям, йөгереп барып, чаршауның бер иңен шытырдатып тартты да төшерде. Җирән чәч әз генә егылмый калды. Шау-шуга залга тәбәнәк буйлы, юан гәүдәле, кара мыеклы хатын йөгереп килеп керде.

— Ни булды тагын?

Бу кинотеатрның директоры иде, күрәсең.

— Менә, теләсә кем керә дә эшне тоткарлый, — диде җирән чәч. — Ишекне бикләп куярга кирәк иде.

Директор Мәрьямгә борылды.

— Иптәш директор, — диде Мәрьям, тыныч булырга тырышып. — Проект буенча стеналар алсу плиткалардан торырга тиеш бит. Ә болар сары чүпрәк асалар.

— Аның ни аермасы бар? Без бу материалны әллә кайчан алган идек инде, аны хәзер чыгарып ташлап булмый лабаса.

— Соң бу зәвыксызлык ич! Ямьсез ич! Сез үзегез проектны яхшы дип кабул иттегез...

— Сеңелем, нишләп йөрисез әле сез монда, ә? Сезгә без заказ бирдек — сез ул заказны үтәдегез. Безнең контора сезнең конторага акчасын түләп, араны өзде. Минем эшем бик тыгыз чак. Зинһар, чыгып китегез, башымны катырмагыз.

— Юк, мин чыгып китмим. Сез барысын да проектта күрсәтелгәнчә эшләтергә тиешсез!

Директор Мәрьям белән сүз көрәштереп тормады, кулыннан тотты да ишектән чыгарып җибәрде. Мәрьямнең төрле оешмаларга баруы белән өркетергә маташуына:

— Әйдә, бар-бар, мин барып та тормам, синең хулиганлыгың турында ике сүз генә язып җибәрермен! — дип мыскыллап калды.

Менә тырыш, эшлә, җелегеңне суыр моннан соң, дип уйлады Мәрьям. Матурлыкның нәрсә икәнен белмәгән, интерьер дигән нәрсә турында хәбәре дә булмаган хатын, тота да, кинотеатр залын теләсә нинди чүпрәккә төреп куя! Ә анда — ул залда көннең көнендә меңнәрчә кеше була.

Мәрьям, гарьлегеннән, ачуыннан, бу гаделсезлектән кая барып сугылырга белмичә, урам уртасында туктап калды. Тизрәк Газизне табарга кирәк, аны алып килеп күрсәтергә кирәк. Ул чарасын күрсен, бу вәхшилекне туктатсын!

Әмма эш вакыты беткән инде, Газизнең өендә телефон юк та бугай әле. Ә болай эзләп барсаң да, мөгаен, кайтмагандыр әле өенә. Берәр яры йөри торгандыр.

Вакыты да юк бит әле аның, сәгать җиде тула икән инде. Ни дисәң дә бу эшне иртәгә калдырмый булмый, тизрәк өйгә кайтырга кирәк.

Ул биек үкчәле кызыл туфлиләре белән күлләвекләрнең нәкъ уртасына баса-баса троллейбус тукталышына йөгерде. Тукталышта кара болыт булып халык тора. Шыгрым тулы троллейбуслар, туктап-нитеп тормыйча, тәгәрмәч асларыннан пычрак су чәчрәтеп кенә узып китәләр. Яшьрәкләр, ул арырак тукталмасмы дип, ярты квартал аның артыннан чаба.

Шул инде ул: көн начарландымы, троллейбуска утыру кыенлаша. Бераздан юеш туфлиләр аякларны туңдыра башлады, дымланып авырайган пальто иңбашларны тарта иде. Мәрьям тәмам өметен өзеп, инде башка чара эзлим дип торганда, бер автобус туктады да алгы ишеген ачты. Бала-чагалы хатыннар, әбиләр кереп беткәч, Мәрьям дә ишек басмасына басты, шул ук минутта автобус ишеге ябылып, астагы тимере белән аның уң аягына яман авырттырып китереп орды. Мәрьям ирексездән күзләрен йомып ыңгырашып куйды. Автобус кузгалды, кемнеңдер көчле кулы Мәрьямнең беләгеннән тотып өскә менгерде.

— Ни булды, әллә ишеккә кысылдыңмы? — диде таныш тавыш.

Аның каршында Шәүкәт басып тора иде.

— Аягыма әллә нинди тимере бәрде шунда...

— Бик авырттырдымы? — Ул үз аягы авырткандай кашларын җыерды.

— Авырттырды шул, — диде Мәрьям, зарланган тавыш белән.Ниндидер усал карчык очлы терсәге белән Мәрьямнең аркасына китереп төртте:

— Киләсесендә чыгасызмы? Соң нишләп юл өстендә торасыз? Ну бу яшьләрне!

Автобусларда карчыклар нилектәндер аеруча явыз булалар.

— Бирерәк кил! — диде Шәүкәт, үз алдыннан, тимер касса янынннан урын биреп.

Аларны шунда ук төрле яктан этә-төртә башладылар һәм Мәрьямнең бераз читтәрәк торырга тырышуына карамастан, бер-берсенә китереп кыстылар. Мәрьям сумка тоткан уң кул аркасы белән Шәүкәтнең сул кулына орынып китте. Ул кулның кайнарлыгы аның бөтен тәнен көйдереп алгандай булды.

— Исәнме, хәлең ничек, с приездом, — диген миңа.

Шәүкәт шаярып сөйләсә дә, аның әкрен, басынкы тавышы калтырап куйгандай булды. Мәрьям керфекләрен күтәреп егетнең күзләренә карады һәм аның тонына керергә тырышып:

— С приездом! Кәефең ничек? Ни кырып йөрисең? — дип кабатлады.

Аларның күзләре бер генә секундка очрашты. Мәрьям оялчан гына елмаеп, Шәүкәт сагаеп карады. Алар бер буйда диярлек булганлыктан, күзләре бер-берсенә бик якын иде. Бу караш бер секунд кына дәвам итте, Мәрьям шунда ук башын читкә борды: ул үзе күргәнне аңлаудан, белүдән курка иде... Шәүкәтнең яшькелт күзләре үзгәрмәгән, алар аңа элеккечә үк якын итеп, сокланып карыйлар, аларда ялвару да бар иде. Мәрьям нәкъ бу ялварулы караш алдында, бу сихри елмаю алдында үзен яшь вакыттагыча көчсез итеп сизде. Аерым яшәгән еллар бик күп нәрсәләрне үзгәрткәннәр, әмма алар арасындагы якынлыкны жи-

мерә алмаганнар. Халык белән тееп тутырылган автобуста алар үзләрен икәүдән икәү генә итеп сизделәр. Мәрьям иңбашы белән Шәукәтнең күкрәгенә үк терәлгән, аларның сулышлары үк кушыла, Шәукәттән аңкыган кыйммәтле тәмәке исе башны әйләндерә иде.

Дөрес, болар бар да күңелдән генә кичерелде, алар гади таныш кешеләр кебек сүзләрнең дә иң гадиләрен генә сөйләштеләр. Күзләрдә чагылган хисләргә сүз белән дә, ым белән дә ишарә ясалмады, Мәрьям аның йөзенә яңадан күтәрелеп карарга кыймады, курыкты.

Шәукәт Художниклар союзына килгән икән. Урал тауларына иҗади командировкага барып кайтырга икән исәбе. Яза башлаган картинасын эшләп бетерер өчен яңа тәэсирләр кирәк. Ул бит хәзер Әлмәттә, художество мәктәбендә укыта. Майда укулар бетә, җәй айларында картинасын төгәлләп, Татарстан художниклары күргәзмәсенә куя алса, күз күне Мәскәүгә укырга китеп булмасмы.

Мәрьямнең проектлар өстендә эшләгәнен белгәч, Шәукәт артык зур өметсез нәрсә турында үтенгәндәй кыюсыз тавыш белән ул проектларны кәгазьдә генә булса да күрергә теләгәнен әйтте. Шул ук вакытта артык теләнергә дә курыкты. Әгәр Мәрьям яңа проектларын күрсәтергә риза икән, бу читләтеп кенә булса да, аның Шәукәткә ачу сакламавын, һәрхәлдә, аны начар кешегә санамавын күрсәтүче дәлил булачак. Ә Шәукәт өчен, аның үз-үзен ихтирам итүе өчен Мәрьямнең аңа мөнәсәбәте бик тә, бик тә әһәмиятле иде.

Мәрьямнең Шәукәткә элекке рәнҗүләре, үпкәләре онытылып бетмәгән булса да, кечерәйгән, кимегән иде. Ничек кенә булмасын, ул берниндй дошманлы хис тә сиздермәде. Һәм җиңел генә: «Безнең институтка керсәң, күреп чыгарсың шунда», — дип куйды. Бу әле аны үз янына чакыру да, гафу итү дә түгел иде, шулай да ул сүзләрдән соң Шәукәтнең йөзендәге киеренкелек, шик югалды, ул иркенәеп, рәхәтләнеп елмайды.

Мәрьямнең тукталышы алдарак иде. «Сау бул, Шәукәт, мин төшәм инде». Автобус кузгалып киткәндә, тәрәзәдә Шәукәтнең елмайган йөзе күренде. Ул уң кулын чигәсе турына күтәргән: «Сау бул!» Я алла, ул гел үзгәрмәгән, элек тә шулай ук елмаеп, кулын шулай күтәрә торган иде.

Ә автобус әллә нишләп алсу төскә буялган. Алсу автобус буламыни? Ни булган бу дөньяга? Биш катлы типовой йортлар алсу, урам асфальты алсу! Мәрьям гаҗәпләнеп як-ягына каранды. Ә-ә, көнбатышта соры болыт пәрдәсен кояш нурлары тишеп чыккан икән. Шул нурлар бөтен каланы алсуга манганнар.

Күп тә үтмәде, болыттагы тишек ямалды, дөнья яңа соры төскә керде. Шулай да Шәукәтнең елмаюы да, очлы нурларның төсе дә зур бер шатлык булып күңелгә кереп калды. Күңел тагын да зур сөенеч, олы могҗиза көткәндәй ашкына иде.

Ул өйгә дә елмаеп кайтып керде. Башка көннәрне кухня белән ванна бүлмәсе арасында килән сарып йөргәндә телевизор каршында, я приемник янында тик утырган Вилданның кыяфәте аның ачуын китерә, «ник мин генә болай бөтереләм әле, ник ул кыл да кыймылдатмый, мин дә эштән кайттым лабаса», — дигән гаделсезлек рәнҗетә иде. Бүген ул иренә борылып та карамады, Фәйрүзәсенә май ягып ипи сыныгы тоттырды да, бәрәңге пешкәнче, ялт итеп иdәннәрне юып чыгарды. Табын янында, авызына ни капканын да сизмичә, калын китапка кадалып утырган Вилданга бер сүз дә әйтмәде. Бичараның чираттагы мавыгуы, Сименонның яңа әсәрен каяндыр тапкан, укып бетермичә бүген йокларга да ятмас, ахры.

Менә Мәрьям Фәйрүзәне кәйләп кечкенә караватына яткырды. «Фәйрүзәкәйнең тәмле әйбер ашыйсы килгән. Шулай бит?». Кызчык шулай дип башын селки. «Ә татлыдан татлы, тәмледән тәмле нәрсә

ул?». Фәйрүзә әтисенекенә охшаган шоколад төсле күзләрен зур ачып, кашларын маңгаена күтәрә. «Ни ул?» «Йокы ул, бәбием. Менә йоклап кара әле, ай-яй татлы йокы».

Вилдан, салкын чәенә шикәр салырга да онытып, бер кабуда йотып җибәрде дә диван-карават янына килеп чишенергә тотынды. Ә күзе һаман китап битендә. Урын җәю өчен Мәрьям аны бераз читкәрәк этте.

Вилдан чалкан ятып китап укый. Бүлмә ярым караңгы, люстра сүндерелгән, түнге лампадан төшкән яктылык китап битләрен, Вилданның куе, кара чәчен ялтырата. Мәрьям диван кырыена утырган да карашын шул китап катыргысына терәп үз уйларына чумган.

Вилдан уң кулы белән китап битен ачарга әзерләнде, Мәрьямнең карашы ирексездән шул лампа яктысына кергән бармакларга төште. Озынча тырнаклы, буын араларына кара төк үскән, ак бармаклар китап битен җайсыз, йомшак тотканнар. Аларда көч тә, ихтыяр да юк, алар тынычлыкка, тик торырга күнеккәннәр. Бу кулда циркуль, линейка, очлы карандаш булуын һич күз алдына китереп булмый, аларга берни дә кирәкми кебек... Ирексездән Мәрьямнең хәтеренә икенче кул, көчле, нервлы, йодрыкланып чигә турысына күтәрелгән кул килде.

Вилдан күзен китап битеннән алып хатынына карады:

— Ни бар?

Аның әле генә капитан Мегрэ белән җинаятьчеләр аулап йөргән миендә борчылу туган иде.

— Ник болай карыйсың миңа?

— Болай гына, — диде Мәрьям, үзе сәбәпсез елмайды.

— Булыр инде. Син миннән гаеп эзләп утырасың.

Аннары нидер исенә төшкәндәй, китабыннан тәмам айнып, башын күтәрде. Үзе яктыда, хатыны караңгыда булганга, аңа Мәрьямнең йөзе начар күренә иде.

— Сиңа нидер булган бүген.

— Юк ла, берни булмады.

— Ну да, син ни булганын миңа әйтәсеңме соң... Эч серенне миңа сөйлисеңме соң...

Аның тавышында чын-чынлап борчылу яңгырады.

Мәрьям торып ванна бүлмәсенә кер юарга кереп китте, Вилдан тирән көрсенеп китабын алды. Биш минуттан ул бөтен барлыгы белән капитан Мегрэ янында иде инде.

*Ахыры бар.*

## Нури Арсланов

### Сагындым

Диңгез, диңгез!
Кояш нурларында
Миллион төсләр белән кабындың.
Син иректәй иркен,
Мин, шулай да,
Иделемне өзелеп сагындым.

Барган саен яңа җирләр, илләр...
Диңгез ача тылсым сандыгын:
Һәр шәһәре — әкият...
Мин, шулай да,
Казанымны өзелеп сагындым.

Аджарлар бар монда, абхазлар бар —
Хуҗалары диңгез ярының,
Матур, батыр халык,
Мин, шулай да,
Татарымны өзелеп сагындым.

Купшы магнолиясе, чинарлары,
Хөрмәләре таулар ягының.
Мәңгелек җәй монда,
Мин, шулай да,
Туган ягым, сине сагындым.

Дулкыннарга, офыкларга карап
Күз-керфегем күпме талдырдым;
Ялгызсынам икән сездән башка,
Бик сагындым, дуслар, сагындым...

Диңгезнең дә хәтта бар бер чиге,
Тик чиге юк хисләр агымының!
Туфракларың сөрмә, суың ширбәт,
Татарстан, сине сагындым.

*1967*

### Диңгездә

Кемдер юк, нәрсәдер җитми,
Җанымда борчу гына...
Ник елый икән акчарлак
Ялгызы, моңсу гына!

Еракта Кырым таулары,
Тауларда күксел томан.
Алар да моңсу,— кайгымны
Уртаклашалар сыман.

Дельфиннар уйный, бу мине
Юатып уйнавымы!
Алыгыз диңгез төбенә
Сагышлы уйларымны!

Тар кебек миңа киң диңгез,
Аз кебек миңа һава;
Кайда киң күңелгә сәйран,
Кайда хисләргә дәва!

Нигә соң әле бу миңа
Кинәт сарылды сагыш:
Кирәк җырла, кирәк ела,
Кирәк авыруга сабыш...

Әй диңгез, шаула, дулкынлан,
Талпынып уйначы бер,
Әйдә, синең дәһшәтеңнән
Рухланыйм туйганчы бер!

*1967*

## Көлеп бакса идә

Кара диңгездә ак кораб,
Ай арттан килә.
Тик яктырмый моңа карая
Өйләнә-тирә:

Кап-караңгы диңгез өсте,
Ай — маяк кына.
Җанымда шул маяк төсле
Өмет яктыра;

Яктыра кыюсыз гына,
Нәкъ айга охшаш,
Чыгар дип, таулар артыннан
Көлеп шат кояш.

Эх, бер көлеп бакса идә —
Җан кинәнәсе!..
Кояш төсле шат йөземдә
Ай күләгәсе...

*1967*

## Нигә?

Мин елмаеп килә́м ерактан ук —
Шәүләң генә синең күренсен...
Эчемдәге тышымда шул минем,
Син дә нигә шулай түгелсең!..

Сине күрсәм бетә борчуларым,
Син шул минем бердәнберемсең,
Син дип яшим, син дип өзелеп торам,
Син дә нигә шулай түгелсең!..

Әллә юри салкын кыланасың,
Теләгәндәй: «Күңеле сүрелсен».
Мин шәярмыйм алай хисләр белән,
Син дә нигә шулай түгелсең!..

Уйлыйсыңдыр: «Бу — кол инде миңа,
Түгелә икән яше, түгелсен».
Сөйгәнне кол иту, колны сөю —
Сөюмени! Хаклы түгелсең...

Теләгем бер: елмаюым аша
Бөтен җаным сиңа күренсен!
Мин бәхетле дәрвиш бәндә инде...
Ә син,
Син шул андый түгелсең.

*1967*

## Өмет

Ни әйтерсең әгәр бер көн үлем килсә:
— Вакыт җитте китәргә, әйдә, кем,— дисә!

Ярый ла әйтә алсаң: — Чү, орынма!—дип,—
Юлыңда бул, миңа таба борылма! — дип.

Әйт-әйтмә, тик үлемнең күңеле йомшармас,
Явыз булса да, ул тугры — ришвәт алмас:

— Күп интектең, — дияр, — ял ит, күзеңне йом...
Алып калмас хәтта врач кылган им-том.

Шулай да мин бер хәйләсен табармын шәт
Калыр өчен тагын гүзәл җирдә яшәп:

Калдырырмын, әйтсәм әйтим мин чынымны,
Мирас итеп һич югында бер җырымны.

Шул җыр белән минем исемем дә онытылмас,
Тәнгә булса булыр кабер, җанга булмас!

*1967*

## Айга карап

Бинокльдән карыйм Айга тәрәзәмнән —
Тамып төшәр төсле Ай бал кәрәзеннән.
Күк йөзендә булса да күп иптәшләре,
Зөһрә кызның һаман түгелә күз яшьләре...
Ай кызы ул, кызыкмый ул бер йолдызга,
Менә диген егет кирәк Зөһрә кызга!
Ашсаң иде шул Зөһрәнең янныарына,
Йөрсәң иде Айның алтын тауларында...
Һәйкәл булып заманнардан заманнарга,
Юллар ачып яңа дөнья һәм таңнарга,
Ташларына меңеп басса иде кеше!
Эх, күрәлсәм иде мин шул бөек эшне!

*1966*

## Уникe батыр турында баллада

*«Татарлар батырларча үлделәр, өлмәеп үлделәр...»*

*Ланфредини истәлегеннән.*

Таш утрау шикелле бу төрмә,
Таш коймa әйләнә-тирәсе.
Бөлдeләр бу ташлар мәйданга
Бүген дә корбаннар килесен...
Дәрләргә унике батырның
Ашуын бу ташлар күрделәр.
Таң калып тетрәде диварлар:
Батырлар өлмәеп үлделәр, —
Татарлар өлмәеп үлделәр.

Еракта, Идел-Йорт җирендә
Уникe батырның иле бар.
Кайтмаслар тик илгә егетләр:
Каршыда таш коймa, шомлы дәр.
Җәйге таң. Зәп-зәңгәр күк йөзе...
Яшәргә иде!.. ди күңелләр.
Тик шәфкать сорамый дошманнан
Батырлар өлмәеп үлделәр,—
Татарлар өлмәеп үлделәр.

Йодрыктай йөрәккә никадәр
Кайгылар, газаплар сыялар...
Сыймады батырлар йөрәге —
Чатнады таш-пулат коймалар.
Хисләре богаудан арынып,
Киң-иркен күкләргә менделәр.
Һәм үлмәс җыр булып калдылар! —
Мусалар өлмәеп үлделәр, —
Батырлар өлмәеп үлделәр.

*1968*

— — ◆ — —

**Айзек Азимов**

# ШӨКӘТСЕЗ МАЛАЙ

**ФАНТАСТИК ХИКӘЯ**



*Американың прогрессив язучысы һәм галиме Айзек Азимовның исеме бөтен дөньяга билгеле. Аның фантастик хикәяләре, романнары һәм фәнни-популяр хезмәтләре бик күп телләргә тәрҗемә ителгән. Ул егермеләп фантастик әсәр һәм берничә фәнни хезмәт язган. Шул исәптән аның «Мәңгелекнең юкка чыгуы» дигән атаклы романын, «Кеше биохимиясе» һәм «Интеллигент кешенең энциклопедиясе» дигән фәнни әсәрләрен күрсәтеп китәргә була.*

*Айзек Азимов 1920 елда Россиядә туган. 1923 елда аның ата-аналары Америкага күченеп киткәннәр. Айзек Азимов Америкада Гарвард университетының химия факультетын тәмамлаган. Профессор Азимов хәзерге вакытта фәнни эшләр белән генә шөгыльләнә.*

*«Казан утлары» өчен мин Айзек Азимовның «Шөкәтсез малай» дип аталган хикәясен тәрҗемә иттем һәм шул турыда әйтеп авторга хат яздым. Айзек Азимов, тәрҗемә өчен рәхмәтен белдереп, җавап хаты җибәрде. Хатта журнал укучыларына аталган шундый сүзләр дә бар:*

*«Моннан җиде гасыр элек татарлар сугышчан халык булганнар. Аларның армияләре меңәр миль җирләрне басып алганнар. Хәзер татарлар үзләренең күршеләре белән дус һәм тату яшиләр. Мин дөньядагы барлык халыкларның да, татарлар шикелле, сугыштан баш тартуларын, һәркемнең үз күршеләре белән дус һәм тату яшәвен теләр идем».*

*Америка язучысының татар тарихына карашын бик үк дөрес*

*дип әйтеп булмый, әлбәттә. Ләкин хикмәт анда түгел. А. Азимов сүзләренең мәгънәсе, үткән тарихтан бигрәк бүгенге көнгә һәм киләчәккә карый: җирдә сугыш булмаска тиеш, җирдә мәңге тынычлык һәм татулык урнашырга тиеш! Бу мәсьәләдә без — совет кешеләре — Айзек Азимовның фикеренә тулысынча кушылабыз һәм аңа үзебезнең теләктәшлегебезне белдерәбез.*

*Язучының «Шөкәтсез малай» хикәясе иң яхшы фантастик әсәрләрнең берсе булып исәпләнелә. Аның гуманизмы, олы җанлылыгы монда аеруча көчле чагыла. Хикәядә фән-техника бик нык алга киткән киләчәк заман тасвирлана. Ләкин авторның чынында хәзерге заманга, аерым алганда, бүгенге Америка тормышына ишарәләвен аңлавы читен түгел. Барлык кешеләр тарафыннан диярлек читкә кагылган, кыерсытылган Тимми Америка Кушма Штатларындагы хокуксыз негрларның бер гәүдәләнеше булып тора. Авторның симпатиясе тулысынча Тимми ягында.*

**НУРИХАН ФӘТТАХ.**



Нығытып ябылган ишекне ачар алдыннан Эдит Феллоуз, гадәтенчә, иң элек өстендәге халатын төзәткәләп алды һәм бары шуннан соң гына реаль дөнья белән реаль булмаган дөнья арасындагы күзгә күренмәс сызыкны үтеп чыкты. Кесәсендә аның куен дәфтәре белән авторучкасы бар иде. Хәер, шактый вакыттан бирле инде ул даими рәвештә язу белән шөгыльләнми иде һәм куен дәфтәре белән авторучкасын соңгы чиктә генә куллана иде.

Бу керүендә ул үзе белән чемодан алып керде. («Малайларга уенчыклар алып киләм», — дип елмаеп аңлатты ул сакчыга. Каравылчы күптән инде аңа берниндн сорау бирми башлаган иде, шуңа күрә ул аңа, керергә рөхсәт икәнлеген аңлатып, кул гына селтәде.)

Мисс Феллоузның бүлмәгә керүен шөкәтсез малай, һәрвакыттагыча, бик тиз сизеп алды һәм, жылый-жылый, аның каршысына йөгереп килде.

— Мисс Феллоуз, мисс Феллоуз, — дип мыгырданды малай. Сүзләрне ул ничектер үзенчә йомшак итеп, бераз аңлаешсызрак итеп әйтте.

— Нәрсә булды, Тимми? — диде мисс Феллоуз, малайның куе коңгырт чәчле ямьсез башыннан сыйпап.

— Жерри тагын килерме минем белән уйнарга? Миңа бик уңайсыз. Әллә ничек кенә булды шунда...

— Ул турыда уйлама. Шуның өчен жылыйсыңмыни әле син?

Малай мисс Феллоузга арты белән борылды.

— Бик үк аның өчен дә түгел, мисс Феллоуз,— диде ул.— Мин тагын төш күрдем.

— Тагын шундый ук төшме? — диде мисс Феллоуз, тешен кысып.

Әйе, Жерри белән булган хәлдән соң аның элекке төшләрен күрә башлавы һич тә гаҗәп түгел.

Малай елмаймакчы булып баш какты, һәм аның бүлтәеп торган жәенке иреннәре арасыннан чамадан тыш эре тешләре күренде.

— Кайчан соң мин моннан чыгарлык дәрәҗәдә зур булып үсәрмен икән, мисс Феллоуз? — диде ул.

— Тиздән, тиздән, — диде мисс Феллоуз, йомшак кына итеп, һәм шул чакны малайны кызганудан аның йөрәге кысылып куйды.

Ул Тиммигә үзен кулыннан житәкләргә ирек бирде. Малайның тупас, коры уч төбе жылысын тойгач, мисс Феллоузның күңеле күтәрелеп китте. Малай аны «Стасис»ның Беренче секциясе булып исәпләнгән һәм, һичшиксез, бик яхшы җиһазланган, тик шулай да үзе өчен, ягъни жиде яшьлек (ай-һай, жиде генә яшьлек микән?) гарип бала өчен, мәңгелек төрмә булган бүлмәләр аша житәкләп китте.

Ул аны бер тәрәзә янына алып килде. Тәрәзәдән вак куаклык белән капланган кырлар-басулар күренә иде.

Малай борыны белән тәрәзә пыяласына капланды.

— Син аннан да яхшырак, матуррак җирләр күрерсен, — диде күнелсез генә мисс Феллоуз, кечкенә тоткынның тәрәзә пыяласында чагылган мескен кыяфәтенә карап.

Гадәттән тыш ямьсез, шөкәтсез малай иде бу, әмма Эдит Феллоуз чын күнелдән ярата иде аны.

Мисс Феллоузның иреннәре калтыранып китте: хәзер ул үз-үзен тыймаска булды, чөнки анын йөзе балага күренми иде.

Юк, алар аны үтермәячәкләр. Аны үтертмәс өчен ул кулыннан килгәннең барын да эшләячәк. Барын да! Ул чемоданын ачты да аннан кием-салымнар ала башлады.

* * *

«Стасис Инкорпорейтэд» дип аталган акционерлар җәмгыятенең бусагасын Эдит Феллоуз беренче мәртәбә моннан өч ел элек атлап керде. Ул чагында мисс Феллоуз бу җәмгыятьнең ни белән шөгыльләнгәнен белми иде әле. Хәер, җәмгыятьнең үзендә эшләүчеләрдән башка ул турыда, гомумән, беркем дә берни белми иде. Һәм чыннан да, бөтен дөньяны шаккатырган хәбәр бары тик мисс Феллоуз «Стасис»ка эшкә кергәч икенче көнне генә таралды. Шуңа кадәр алар физиология өлкәсендә белеме, медицина химиясе өлкәсендә эш тәҗрибәсе булган, бала җанлы хатын-кызны эшкә чакырулары турында кыска-кыска белдерүләр генә биргәләделәр. Эдит Феллоуз балалар табу бүлегендә шәфкать туташы булып эшли иде. Шуңа күрә ул «Стасис Инкорпорейтэд»нын барлык таләпләренә җавап бирә алам дигән фикергә килде.

Физика фәннәре докторы Җеральд Хоскинс баш бармагы белән чигәсен ышкып алды да мисс Феллоузны игътибар белән караштыра башлады.

Мисс Феллоузның борыны бераз гына симметриясез, кашлары калын иде. Хоскинсның күз карашын тоеп ул үзеннән-үзе бөрешеп калды һәм шул чакны бите тартышып куйганлыгын тойды.

«Әллә ниткән чибәр дип белерсең! — дип уйлады ул доктор Хоскинс турында, үпкәләп. — Чәче коела, корсагы үсә башлаган. Иреннәре нык кысылган... караңгы чырайлы, йомыкый». Ләкин тәкъдим ителгән эш хакының алдан исәп тотканга караганда да күбрәк булачагы беленгәч, мисс Феллоуз нәтиҗә чыгарырга ашыкмаска кирәк дигән фикергә килде.

— Алайса, сез чыннан да балаларны яратасыз? — диде Хоскинс.

— Яратмаган булсам, яратам дип әйтмәгән булыр идем.

— Бәлки, сез матур балаларны гына яратасыздыр? Теге... ни... үзләренчә лыбыр-лыбыр килә торган, алсу битле, кечкенә борынлы гүзәл балаларны?..

— Нинди генә булмасын, бала бала инде ул, доктор Хоскинс, — диде мисс Феллоуз. — Нәкъ менә шундый ямьсез балалар башкаларга караганда да ярдәмгә күбрәк мохтаҗ булалар.

— Әйтик, без сезне алдык, ди...

— Мине эшкә алырга риза дип әйтмәкче буласызмы сез?

Доктор Хоскинсның киң йөзендә елмаю билгесе чагылып китте. Шул мизгелдә үк ул ничектер мисс Феллоузга ягымлы булып күренде.

— Карар кабул иткәндә мин озак сузарга яратмыйм, — диде Хоскинс. — Ләкин хәзергә мин сезгә бер нәрсә дә тәкъдим итмим әле, сезне буш кул белән борып та җибәрә алам. Сез сон үзегез минем тәкъдимгә риза булырга әзерме?

Мисс Феллоуз, куллары белән кечкенә сумкасын чытырдатып кыс-

кан килеш, яна эшнең файдалы яклары турында күнеленнән тиз генә исәпли башлады, ләкин кинәт уянган бер импульска буйсынып, ул уйларын шундук читкә куды.

— Әйе, әзер, — диде ул.

— Бик шәп. Бүген кич без «Стасис»ны эшләтә башларга җыенабыз, кичекмичә үз вазифаларыгызны үти башлау өчен, минемчә, сезгә шунда булырга туры килер. «Стасис»ны кичке сәгать сигездә җибәрәбез. Җидедә утыз минутта мин сезне шушы ук урында очратырмын дип ышанам.

— Тик...

— Ярар, ярар. Хәзергә шул җитеп торыр.

Сигнал бирелгәч тә, елмаеп алар янына секретарь кыз килеп керде һәм мисс Феллоузны кабинеттан озатып куйды.

Төп-төгәл сигезенче яртыда «Стасис»ка килгәч, мисс Феллоуз гаҗәпләнми булдыра алмады: үзе турында аңа беркемгә дә әйтергә кирәк булмады. Аның юлында очраган барлык кешеләр — ирләр, хатын-кызлар, әйтерсең, аның кем булуын гына түгел, бәлки аның кем булып эшләячәген дә алдан ук белеп торалар иде, һәм тиз арада аны бина эченә үткәреп тә җибәрделәр.

Ул балконда басып торды. Моннан аңа космик корабльнең идарә пульты белән электрон-исәпләү машинасының контроль панеле шикелле рәк нәрсәне хәтерләткән ниндидер приборлар тулы киң, зур шахта күренә иде.

Шахтаның икенче ягында түшәмсез квартира стеналары хезмәтен үтәгән коймалар калкып тора иде. Ул стеналар ниндидер искиткеч курчак өен хәтерләтә иде, һәм мисс Феллоуз басып торган җирдән шул курчак өенең эчендәге җиһазлары уч төбендәгедәй күренә иде.

Курчак өенең бер бүлмәсендә электрон плита белән суыткыч җайланма, икенче бүлмәсендә ванна бар иде. Ә өченче бүлмәдә күренгән нәрсә бары тик койка... кечкенә балалар койкасы булырга тиеш иде...

Хоскинс ниндидер бер ир кеше белән сөйләшеп тора иде. Мисс Феллоузны да исәпләгәндә, балконда алар нибарысы өч кеше иде. Хоскинс мисс Феллоузны ят кеше белән таныштырмады, һәм шуңа күрә туташка ят кешене читтән генә, яшертен генә караштырудан башка чара калмады.

— Мин һич тә сезнең алда боларның барысын да аңлаган кеше булып кыланырга тырышмыйм, доктор Хоскинс, — диде ят кеше. — Мин бары шуны гына әйтергә телим: белгеч булмаган интеллигент кеше ни дәрәҗәдә аңлый алса, кайбер нәрсәләрне мин дә шул дәрәҗәдә генә аңлыйм. Бу мәсьәләдә хәтта күпмедер белемем булса да, миңа әлеге проблеманың бер ягы бик үк аңлашылып җитми. Мин сайлап алу мәсьәләсен күз алдында тотам. Сез бик ерак чорларга кадәр үтеп керә аласыз. Әйтик, монысы аңлашыла да, ди. Еракрак үтеп кергән саен, объектлар томанлырак, аңлаешсызрак була бара. Бу хәл исә бик күп энергия сарыф итүне сорый. Ярар. Ләкин шул ук вакытта сез якынрак объектка да барып җитә алмыйсыз. Менә шул нәрсә минем өчен аңлашылмый да инде.

— Сез миңа, Девеней, чагыштыру ясарга рөхсәт итсәгез, бу проблеманы мин сезгә икенче яктанрак аңлатырга тырышып карармын. Ул чагында инде мәсьәлә сезгә алай ук катлаулы булып тоелмас.

Ят кешенең сүз арасында ишетелеп калган исеме мисс Феллоузга иркесездән тәэсир итте һәм шунда ул ят кешенең кем икәнлеген аңлап алды. Бу, күрәсең, телевизион яңалыклар өчен фәнни темаларга очерклар яза һәм гыйлем дөньясындагы барлык зур вакыйгаларны үз күзе белән күрергә ярата торган Кандин Девеней иде бугай.

— Әгәр сез алай аңлаешлырак булыр дип исәплисез икән, нигә чагыштыру кулланмаска? — диде Девеней.

— Ярар, алайса. Сез инде, әлбәттә, беләсез: әгәр гадәттәге шрифт белән басылган китап сездән алты фут ераклыкта торса, сез ул китапны укый алмаячаксыз. Ә инде сезнең күз белән китап арасын бер футка кадәр кыскартсак, сез аны укый алачаксыз. Үзегез дә күреп торасыз, монда: никадәр якынрак булса, шулкадәр яхшырак дигән кагыйдә өстенлек итә. Ләкин сез шул ук китапны күзегезгә бер дюймга тикле якынайтсагыз, сез янадан укый алмый башлаячаксыз. Менә шуннан инде аңлашыла булса кирәк: безнең алда артык якын ара дигән каршылык ята.

— Һм, — диде Девеней. — Бу чагыштыруны сез миңа үз хикәямдә файдаланырга рөхсәт итәрсез ич?

— Кирәк икән, файдаланыгыз. Мин бик шат булырмын. Бит миңа сезнең кебек кешене шактый озак көтәргә туры килде. Мин сезгә нинди мәгълүмат кирәк, барысын да бирермен. Ниһаять, без дөньяга үз җилкәбез аша үрелеп карарга рөхсәт итә алабыз, һәм дөнья халкы чыннан да кайбер нәрсәләр күрә алачак.

Мисс Феллоуз Хоскинсның үз-үзен тыныч һәм ышанычлы тотуына ирексездән сокланып куйды. Хоскинста бик нык ихтыяр көче барлыгы сизелә иде.

— Сезнең мөмкинлекләрнең чигениндирәк? — диде Девеней.

— Кырык мең ел.

Мисс Феллоузның кинәт тыны кысылды.

— Ел дисезме?!

Киеренкелектән, әйтерсең, бөтен тирә-як кинәт таштай катып калды. Идарә приборлары янындагы кешеләр бөтенләй диярлек кыймылдамыйлар иде. Кемдер микрофонга бер үк тонык тавыш белән ниндидер кыска-кыска сүзләр әйтә иде — мисс Феллоуз, никадәр тырышса да, берни аңлый алмады.

Девеней, балкон култыксасы аша иелеп, астагы кешеләрне, приборларны күзәтә иде.

— Без ни дә булса күрә алырбызмы, доктор Хоскинс? — диде ул.

— Нәрсә дисез? Юк, буласы нәрсә булмыйча торып, без бернәрсә дә күрә алмаячакбыз. Объектны без, радар аппаратындагы принцип шикеллерәк принцип буенча, читләтебрәк табабыз. Тик без монда электромагнит дулкыннары урынына мезоннардан файдалануны яхшырак күрәбез. Тиешле шартлар булганда, мезоннар кире кайта һәм аларның кайбер өлеше берәр объектка туры килеп чагыла ала. Безнең төп бурычыбыз — менә шул чагылышларны тикшерү.

— Бик авыр эштер бу, күрәсең.

Хоскинсның йөзендә елмаю билгесе чагылып үтте.

Сезнең алда — илле еллык эзләнүләр нәтиҗәсе. Мин үзем бу проблема белән моннан ун ел элек кызыксына башладым. Әйе, чынлап та моны бик үк җиңел эш дип булмый.

Микрофон янындагы кеше шул чакны кулын күтәрде.

— Менә берничә атна буена инде без вакыт ераклыгы белән исәпләнелә торган ераклыктагы билгеле бер моментны өйрәнәбез. Үзебезнең вакыт эчендә көченүләребезне алдан исәпләп, без тәҗрибәне әле туктатабыз, әле янадан башлап җибәрәбез. Һәм шуның белән без вакыт эчендә тиешенчә төгәл юнәлеш таба алуыбызны әледән-әле тикшереп торабыз. Хәзер инде безнең аппаратлар бернинди кимчелексез эшләргә тиеш.

Эдит Феллоуз, үзе дә сизмәстән, кинәт урыныннан торды, култыкса янына килеп басты. Ләкин аста әле карарлык берни юк иде.

— Хәзер була, — диде микрофон янындагы кеше тыныч кына.

Шул чакны беразга тынлык урнашты, һәм кинәт курчак өй ягыннан коты алынган ниндидер баланың чыркылдап кычкырган тавышы ишетелде.

Мисс Феллоуз, тетрәнеп, чәчләре үрә торып, тиз генә шул якка борылып карады.

Ә Хоскинс йодрыгы белән култыксага сугып алды да калтыранган бер тавыш белән, тантана итеп:

— Булды! — дип кычкырды.

Мисс Феллоуз шахтага төшә торган бормалы, кыска баскычка таба йөгерде. Арттан, ашыктырып, каты кулы белән аның аркасыннан эткәләп, Хоскинс килде һәм авыз ачып аңа бер генә сүз дә әйтмәде.

Моңарчы идарә приборлары янында торган кешеләр хәзер барысы да бер жиргә жыелганнар иде. Алар, елмаеп, тәмәке төтене пошкыртып, төп бинага килеп кергән кешеләргә карап торалар иде. Курчак өй ягыннан көчсез генә булып ниндидер жуылдаган тавыш ишетелә иде.

— «Стасис»ка керү бернинди куркыныч тудырмый, — диде Хоскинс Девенейга. — Мин үзем монда күп мәртәбәләр кереп чыктым. Бераз гына вакытка сәер бер тойгы барлыкка килә, ләкин аның сәламәтлеккә бернинди зыяны юк.

Сүзләренең дөрес икәнлеген күрсәтмәкче булган кебек, ул ачык ишектән кереп тә китте. Киеренке бер кыяфәттә елмаеп һәм ни өчендер тирән сулап, аның артыннан Девеней атлады.

— Монда килегез, мисс Феллоуз! — диде Хоскинс, түземсезлек белән кулын изәп.

Мисс Феллоуз ризалык белдереп баш какты һәм ничектер уңайсыз гына атлап бусагадан үтте. Аның бөтен тәнен ниндидер эчке бер калтыравык калтыратып жибәргәндәй булды, тик шулай да өй эченә кергәч бу тойгы юкка чыкты. Монда яңа киселгән агач һәм дымлы туфрак исе килә иде.

Хәзер инде монда тып-тын иде, һич югы, теге баланың тавышы ишетелми иде. Ләкин аның урынына кинәт кайдадыр аяк тавышлары һәм нидер шыштырдаган тавышлар ишетелеп китте, — әйтерсең, кемдер кулы белән агач йөзен сыйпый иде. Ул да булмады, ыңгырашкан авазлар ишетелә башлады.

— Кайда соң ул? — диде мисс Феллоуз, өзгәләнеп. «Андагы бала нишләсә дә барыбер микәнни соң бу ахмакларга?» дип уйлады ул.

Малай йокы бүлмәсендә яисә, дөресрәге, койкалы бүлмәдә иде.

Ул шәп-шәрә иде, һәм аның былчыракка буялып беткән күкрәге бер калка, бер төшә иде. Кара-кучкыл шәрә аяклары янында балчык катыш бер кочак каты үлән аунап ята иде. Аннан ниндидер сасы ис һәм туфрак исе аңкый иде.

Мисс Феллоузның балага төбәлгән күз карашында Хоскинс ачык-тан-ачык жирәнү һәм кот алыну билгеләре күрде һәм, үртәлеп:

— Малайны шулкадәр ерак гасырлар тирәнлегеннән чип-чиста көе тартып алырга безнең бернинди мөмкинлегебез булмады, мисс Феллоуз, — диде. — Соңыннан ул-бу була күрмәсен өчен без аны чолгап алган кайбер нәрсәләрне дә чыгарырга мәжбүр булдык. Югыйсә, ул монда аягынмы, баш сөягенеңме берәр өлешенме югалтып чыккан булыр иде.

— Үтенәм сездән — берни әйтмәгез! — диде мисс Феллоуз, нишләргә белмичә, мондый сөйләшүне тизрәк туктатасы килеп. — Нигә карап каттык соң әле без? Бичара бала шундый курыккан, шундый пычрак...

Ул хаклы иде. Малайның тәне каткан балчык һәм ниндидер май таплары белән капланган иде, ә ботында ниндидер тырналган, шешкән урыны күренә иде. Карап торуга аңа нибарысы өч кенә яшь бирерлек иде.

Хоскинс үзенә таба якынлашкач, ул башын иде дә тиз генә артка тайпылды. Өске ирене аның турсаеп калды һәм шул чакта аның авызыннан мыгырдануга да, песи мырлавына да охшаш бер өн чыкты.



Хоскинс җәһәт кенә аның кулыннан эләктереп алып, югары күтәрде. Бала исә дөнья бетереп кычкыра, боргалана башлады.

— Алай түгел, менә болай тотыгыз, — диде мисс Феллоуз.— Иң элек аны җылы ваннада нытып юарга кирәк. Сезнең монда кирәкле нәрсәләр бармы? Булса, кием-салымнарын китерергә кушыгыз әле. Аннары, аны юындырырга булышыгыз... бераз гына булса да... Тагын шул: алла хакы өчен мондагы бу пычракны, чүп-чарны җыештырырга кушыгыз.

Боерыклар бирергә хәзер инде аның чираты җитте, һәм үзенең яңа ролендә ул үзен бик яхшы хис итте: нишләргә белмичә, читтән генә күзәтеп торган хатын-кызны тәҗрибәле шәфкать туташы алыштырды. Хәзер ул балага бөтенләй икенче күз белән, белгеч күзе белән карады, — һәм күпмедер вакытка шактый аптырашта калды. Баланың тәненә сылашкан балчык, аның кычкырып җылавы, бер дә юкка карышып, үрлекырлы килүе — барысы да каядыр артка чигенде. Хәзер ул баланы караштыра иде.

Үз гомерендә күргән барлык балалар арасында бу иң ямьсез, иң шөкәтсез бер бала иде. Кеше башына бик үк охшамаган башыннан алып камыт аякларына тикле аның барлык әгъзалары адәм әйтеп адәм ышанмаслык дәрәҗәдә килешсез, килбәтсез иде.

Өч ир кеше ярдәмендә ул аны шулай да юындыра алды. Алар бала белән булашкан арада бүтәннәр өй эчен җыештырдылар. Баланың бертуктаусыз кычкыруына, тибенүенә һәм күлмәге сабын суына чыланганга үртәлеп, хәтере калган бер горур кыяфәттә мисс Феллоуз тавышсыз гына эшләде.

Малайның тәне, ниһаять, алсу төскә кергәч һәм тәмле сабын исләре аңкыта башлагач, мисс Феллоуз, әлерәк кенә кичергән кире тойгыларына да карамастан, үзен яхшырак хис итә башлады. Малай инде кычкыра алмый иде: ул бары

хәлсез тавыш белән шыңшып-шыңшып кына куя һәм шул ук вакытта аның куркынган, сак күз карашы әле бер кешегә, әле икенче кешегә юнәлә һәм бүлмәдәге бер генә кешене дә читтә калдырмый иде. Юынгач, чистаргач, аның шәрә тәненең ябыклыгы тагын да ныграк күзгә ташланып тора иде. Салкыннан дер-дер калтырана иде үзе.

— Бирәсезме инде сез анда балага бирәр җылы күлмәк! — диде мисс Феллоуз кискен генә.

Шундук каяндыр әчке күлмәк килеп төште. Әйтерсең, боларның барысы да алдан әзерләнеп куелган иде. Тик шулай да, мисс Феллоузга боерык бирергә мөмкинлек калдырып, аны юри сынарга теләгән сыман, ул таләп иткәнче беркем дә урыныннан кузгалмады.

— Мин аны тотып торырмын, мисс, — диде Девеней, шәфкать туташы янына килеп. — Үзегез генә кидерә алмассыз.

— Рәхмәт сезгә.

Балага күлмәк кидергәнче, иң элек аның белән чын-чынлап сугышырга туры килде. Кидереп бетергәч исә бала күлмәген ертырга азаплана башлады. Мисс Феллоуз нык кына итеп аның кулына сугып алды.

Бала кызарынып китте, шулай да җыламады. Күзләрен зур ачып мисс Феллоузны күзәтте; үзенә билгеле булмаган әйберне тикшергән сыман, ипсез бармаклары белән күлмәген капшаштырып карады.

«Хәзер нишләргә инде?» дип уйлады мисс Феллоуз, аптырап.

Бүлмәдәге кешеләрнең барысы да, хәтта шөкәтсез малай да, бу тагын нишләр икән инде дигәндәй, тып-тын калдылар.

— Сезнең балага ашатырдай бирәр нәрсәгез бармы... сөтегез? — диде мисс Феллоуз нык кына итеп.

Алар баланы ашату-эчерту турында да алдан кайгыртып куйганнар иде. Шул чакны бүлмәгә суыту бүлеменнән һәм җылыту җайланмасыннан торган махсус күчмә агрегат кертteләр.

Мисс Феллоуз иң элек сөтне генә алды. Электрон җайланма күп булса ун-унбер секунд эчендә сөтне тиешле температурага кадәр җылытты да автоматик рәвештә туктап калды. Мисс Феллоуз тәлинкәгә бераз сөт агызды. Баланың аң үсеше бик түбән икәнлеген һәм аның тәлинкәдән ашый алмаячагын ул әз генә дә исеннән чыгармады.

Ул малайга баш какты да:

— Эч әле, эч, — диде. Ничек итеп тәлинкәне авызга китерергә кирәклеген күрсәтте. Бала аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торды, тик шулай да урыныннан кузгалмады.



Шул чакны мисс Феллоуз кискен бер карарга килде. Бер кулы белән малайның беләгеннән тотып, икенче кулын сөткә тыгып алды да сөтле бармакларын баланың иренәнә тидерде. Малайның битеннән, иякләреннән сөт тамчылары акты.

Малай кычкырып җылап җибәрде, ләкин шундук туктады да юеш иреннәрен ялмарга кереште. Мисс Феллоуз артка чигенде.

Менә малай тәлинкәгә якынрак килде, иелде, тирә-якта яшеренеп яткан дошманнарын күзәткән шикелле, тиз генә як-ягына каранып алды һәм комсызланып сөтне песи кебек эчә башлады.

Мисс Феллоуз баланың бу кыланышыннан җирәнгәнлеген яшерә дә алмады. Җирәнүе, күрәсең, йөзенә дә чыкты, чөнки Девеней аңа карап алды да:

— Доктор Хоскинс, туташ беләме соң мондагы нәрсәләрне? — диде.

— Нәрсәне? — диде мисс Феллоуз, кызыксынып.

Девеней икеләнгәндәй итте. Бала белән мәш килү дә, мисс Феллоузның күп нәрсәне әле белмәве дә Хоскинс өчен бары кызык кына иде, ахрысы. Моның шулай икәнлеген докторның кыяфәтенә карап та белергә була иде.

— Телисез икән, әйтегез, — диде ул Девенейга.

— Очраклы язмыш аркасында сез үзегезнең неандерталь чоры баласын караучы беренче мәдәни хатын-кыз булуыгызны — бөтен тарихта беренче хатын-кыз булуыгызны белмисез дә бугай әле, — диде Девеней, мисс Феллоузга мөрәҗәгать итеп.

Мисс Феллоузның йөрәген кинәт ярсу биләп алды. Шулай да ул тыелып калды һәм Хоскинска таба борылып:

— Ул турыда сез миңа алданрак әйтә алган булыр идегез, доктор, — диде.

— Ник? Сезнең өчен барыбер түгелмени?

— Без бала карау турында сөйләштек.

— Бу да бала түгелмени? Кайчан да булса сезнең эт баласымы, песи баласымы караганыгыз булмадымыни, мисс Феллоуз? Эт баласы яисә песи баласы бу неандерталь балага караганда да кешегә охшаганрак идеме әллә? Әгәр бу шимпанзе баласы булып чыккан булса, сез аннан җирәнгән булыр идегезмени? Сез медик, сез шәфкать туташы, мисс Феллоуз. Сезнең документларга караганда, бала тудыру бүлегендә сез өч ел эшләгәнсез. Бала тудыру бүлегендә сезнең гарип баланы караудан баш тарткан чагыгыз булдымы?

Мисс Феллоуз үзенең бирешә башлаганлыгын аңлады.

— Шулай да сез миңа алдан әйтеп куя алган булыр идегез, — диде ул, йомшара төшеп.

— Сез шундук эштән баш тарта алсын өченме? Бәлки, сез хәзер баш тартмакчы буласыздыр?

Хоскинс аңа салкын күз карашы ташлап алды. Икенче яктан, бүлмәнең аргы башыннан аны Девеней күзәтеп тора иде; сөтне эчеп бетергән, тәлинкәне чип-чиста итеп ялап куйган неандерталь малае исә, ялварып нидер сораган кыяфәт белән, зур ачылган күзләрен тутырып, сөткә чыланган битен күпертеп, шулай ук аңа таба карап тора иде.

Малай сөткә ымлап күрсәтте, һәм шул чакны анын авызыннан өзек-өзек булып гырылдавык авазлар чыкты. Шул ук вакытта ул оста гына итеп телен дә шартлатып алды.

— Карагыз әле, сөйләшә белә! — диде мисс Феллоуз, исе китеп.

— Әлбәттә, — диде Хоскинс. — Homo neanderthalensis ул чынында аерым төр түгел, бары тик Homo sapiensның бер төре генә. Шулай булгач, нишләп әле ул сөйләшә белмәскә тиеш? Ихтимал, ул тагын сөт сорый торгандыр әле.

Мисс Феллоуз, аны-моны уйламыйча, тиз генә сөт шешәсенә үрелде, ләкин Хоскинс шундук аның кулыннан тотып алды.

— Ә хәзер, мисс Феллоуз, ни дә булса эшләгәнче сез миңа әйтергә тиешсез: каласызмы монда, юкмы?

Мисс Феллоуз, үртәлеп, кулын Хоскинс кулыннан ычкындырды.

— Әгәр мин китсәм, әллә сез аны ашатмаска уйлыйсызмы? Мин... бераз аның янында торып торырмын.

Ул балага тагын сөт салып бирде.

— Без сезне монда шушы бала белән бергә калдырмакчы булабыз, мисс Феллоуз, — диде Хоскинс. «Стасис»ның Беренче секциясенә керә торган бердәнбер ишек монда. Ишек тыштан ныгытып бикләнә, шунда ук сак тора. Мин сезнең ишек йозагын яхшылап өйрәнүегезне теләр идем. Ул йозак сезнең дә, минем дә бармак эзләренә ярашлы рәвештә көйләнгән. Түбә өстендәге бушлыкны да ныгытып саклыйлар, — диде ул, курчак өйнең түшәме булырга тиешле якка күтәрелеп карап. — Көтелмәгән берәр нәрсә була-нитсә калса, безгә шундук хәбәр итәчәкләр.

Мисс Феллоуз гаҗәпләнеп курчак өйгә күз йөртеп чыкты.

— Нигә шулкадәр саклар куелган, доктор Хоскинс? Бу бала сезгә берәр төрле куркыныч тудыра аламы әллә?

— Беләсезме, мисс Феллоуз, бөтен хикмәт энергиягә бәйләнгән. Бала беркайчан да бу йорттан чыкмаска тиеш. Беркайчан да. Бер генә секундка да. Бернинди очракта да. Хәтта аңа үлем куркынычы килгәндә дә. Хәтта **сезне** үлемнән коткарырга кирәк булса да, мисс Феллоуз. Сез мине аңладыгызмы?

Мисс Феллоуз горур гына башын югары күтәрде.

— Боерыкның нәрсә икәнлеген мин яхшы беләм, доктор Хоскинс.

— Бик яхшы. Берәр нәрсә кирәк булса калса, сез һәрвакыт безгә сигнал бирә аласыз.

Ике ир кеше «Стасис»тан чыгып китте.

Артына әйләнеп караса, мисс Феллоуз малайның сагаеп әүвәлгечә үзенә таба карап торуын күреп алды. Малайның куркынган күз карашы бер генә секундка да аннан читкә юнәлмәде, ул мисс Феллоузның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торды. Мисс Феллоуз кинәт үзенең ничек тә баланы тынычландырырга тырышканлыгын шәйләп алды. Иплән кенә аның башына таба кулын якынайтты. Кулын малайның күз алдында тотарга тырышты. Шуның белән ул балага: мин сиңа бернинди начарлык эшләргә теләмим дигәнне аңлатырга тырышты.

Шулай итеп ул аның башыннан сыйпый алды.

Малай тагын телен шартлатып куйды.

— Кулга алырга буламы сине? — диде мисс Феллоуз.

Ул, ике кулын да сузып, тынып калды. Баланың кулы әкрен генә аның кулына таба якынлашты.

— Дөрес, — диде мисс Феллоуз, баш кагып.

Сузылган кулы мисс Феллоузның кулына бер дюйм чамасы гына калгач, баланың кыюлыгы кинәт юкка чыкты, һәм ул тиз генә кулын кире тартып алды.

— Ярар, соңыннан без тагын шулай итеп карарбыз әле, — диде мисс Феллоуз тыныч кына. — Ятасың килмиме? — Ул караватка кулы белән шапылдатып алды. Малай келде дә күз ачып йомганчы караватастына кереп тә китте.

Мисс Феллоуз келеп карават астына карады. Карангыда ул уттай янган күзләр күрде, һәм шул чакны тагын тел шартлаткан тавыш ишетелде.

— Анда үзеңне тынычрак сизәсең икән, әйдә, йокла шунда карават астында, — диде мисс Феллоуз.

Ул йокы бүлмәсенең ишеген ябып куйды да өч бүлмәнең иң зурысына китеп барды. Аның өчен анда койка куелган иде; түбә өстенә, аның таләбен үтәү йөзеннән, вакытлыча чатыр корылган иде.

* * *

Күрше бүлмәдән ишетелергә мөмкин булган бер генә тавышны да ишетми калмыйм тагын дигән кебек, ул, теләсә дә, теләмәсә дә, үзен гел киеренке тоеп ятты һәм һич кенә дә йоклап китә алмады. Үз-үзен ул, бала өйдән чыгып китә алмаячак, дип ышандырырга тырышты, ләкин, шуңа да карамастан, аның күңелен шикләнү корты кимерде.

Чыннан да малай куркыныч булса? Чын мәгънәсендә куркыныч булса? Юк, мөмкин түгел. Әгәр ул шундый куркыныч бала булса, Хоскинс аңа әйтми булдыра алмас иде, аның бер үзен генә калдырмас иде бала белән...

Үзенең куркуыннан көлеп, ул үз-үзен тынычландырырга тырышты. Нибарысы өч-дүрт яшьлек бала гына бит әле бу малай. Шулай да әгәр, йокыга киткәч, кинәт ул аңа һөҗүм итсә, тешләре, тырнаклары белән тешләргә, тырнарга тотынса?..

Мисс Феллоуз еш-еш сулу ала башлады. Барлык игътибарын туплап тыңларга тотынды һәм шул вакыт аңа ниндидер тавыш ишетелеп киткәндәй булды.

Теге бүлмәдә малай жылый иде.

Куркудан яисә ачудан кычкырмый, чыелдамый, бәлки, кайгыдан нишләргә белмәгән бәхетсез, ялгыз бала ничек жыласа, ул да шулай әкрен генә үксеп жылый иде.

«Бичара», — дип уйлады мисс Феллоуз һәм бала белән очрашуыннан соң беренче мәртәбә аның күңелен ихлас бер кызгану тойгысы өтеп алды.

Бала бит ул, шулай булгач, аның башы нинди формада булса да барыбер түгелмени? Һәм ул теләсә нинди бала гына да түгел, ул ятим бала, һәм кешелек тарихында бер генә бала да аның кебек ятим булмаган. Моннан берничә мең ел элек аның атасы-анасы гына үлеп калмаган, бәлки кайчандыр аны чолгап алган барлык нәрсәләр дә мәңгегә юкка чыккан. Бик күптән узып киткән бер чор эченнән шундый тупас рәвештә тартып алынган ул бала — үзе кебек балалар арасында бөтен дөньяда бердәнбер жан иясе. Соңгысы һәм бердәнбере.

Мисс Феллоузның күңелен торган саен кызгану һәм үзенең каты бәгырьлелеге өчен уңайсызлану хисе били барды. Ул яткан урыныннан торды да күрше бүлмәгә юнәлде.

— Малай, малай, кил әле! — диде ул, пышылдап.

Ул инде карават астына кулын да сузмакчы булган иде, ләкин шундук аның күңеленә: әгәр тешләсә? дигән уй килде һәм ул баштагы уеннан кире кайтты. Ул сүрән генә яна торган утны кабызды һәм караватны читкәрәк этәрде.

Бичара бала, куркулы, күз яшь тулы күзләре белән мисс Феллоузга текәлгән килеш, тезләрен кочаклап, почмакта бөрешеп утыра иде.

Ярым караңгыда аның кыяфәте мисс Феллоузга алай ук куркыныч булып күренмәде.

— Мескенкәем, бичаракаем, — диде ул, сак кына аның башыннан сыйпап. Аның кулы кагылу белән, баланың бөтен тәне тартылып куйды, аннары әкрен генә йомшый башлады. — Бичара балакай. Берaз гына синең янда торырга буламы?

Туташ бала янына утырды да аның чәчләрен, чигәсен, кулларын сыйпады һәм шул ук вакытта авыз эченнән әкрен генә ниндидер ягымлы бер жыр көйләргә тотынды.

Аның жырлавын ишетеп бала башын калкытты һәм, үзе өчен бөтенләй ят булган авазлар белән кызыксынгандай, тоныкут яктысында шәфкать туташы иреннәренең кыймылдавын күрергә тырышты.

Малайның шулай карап торуыннан файдаланып, мисс Феллоуз аны үзенә таба якынрак китерде һәм йомшак, иплe бер хәрәкәт белән,

экренләп-экренләп аның башын үзенең иңбашына якынайтты. Куллярын аның аяклары астына тыкты, ашыкмыйча гына, салмак кына баланы үзенең тезләре өстенә куйды. Шул ук җыр сүзләрен кабатлый-кабатлый, баланы кулыннан ычкындырмыйча, утырган җирендә тирбәлә башлады. Малай экренләп тынычлана барды, һәм озакламый аның тигез генә тын алуын ишетеп, мисс Феллоуз аның йокыга киткәнлеген аңлап алды.

Бик саклык белән, әз генә дә тавышланмаска тырышып, ул баланы урынга салды. Өстенә япты да игътибар белән аның йөзенә карап тора башлады. Йоклаганда баланың йөзе шундый тыныч иде, шундый сабыйларча иде,— коточкыч ямьсезлеге дә аның ничектер күзгә үк ташланмый шикелле иде.

Мисс Феллоуз җиңеләеп бер көрсенде дә иплэп кенә бала янына йокларга ятты.

Йокы аралаш аңа кинәт кемдер үзен этеп җибәргәндәй кебек тоелды. Ул уянып китте һәм коты алынудан чак-чак кына кычкырып җибәрмәде. Күзләрен зур ачкан килеш, малай аңа төбәп карап ята иде. Ничек итеп үзенең бу бала янына караватка килеп ятуын хәтерләү өчен мисс Феллоузга шактый вакыт кирәк булды. Малайдан күзен алмыйча, ул башта бер аягы, аннары икенче аягы белән әкрен генә идәнгә басты.

Өстән ябылмаган түшәм ягына тиз генә бер куркулы күз карашы ташлап алды да, караваттан бөтенләй торып китү өчен, барлык көчен җыеп, соңгы омтылыш ясамакчы булды.

Ләкин шул чакны малай кулын сузды, каты бармаклары белән аның иреннәренә кагылды һәм үзенчә ниндидер сүзләр әйтте.

Баланың кагылуын тоеп ул сискәнеп китте. Көн яктысында бала тел белән әйтеп булмас дәрәҗәдә ямьсез иде.

Ул тагын нидер әйтте дә зур итеп авызын ачты һәм, кулы белән ымлап, үзенең авызыннан нидер акканын аңлата торган хәрәкәт ясады.

Мондый ымның мәгънәсен аңларга тырышып, мисс Феллоуз уйга калды. Аннары кинәт кычкырып җибәрде:

— Син минем җырлавымны телисеңме? — диде.

Малай, берни эндәшмичә, аның авызына карап торуында булды. Дулкынланудан бераз гына ялгыштырып мисс Феллоуз теге кичә төнлә җырлаган җырны көйли башлады. Шөкәтсез малай елмаеп җибәрде, музыка көенә килешсез генә селкенеп-селкенеп алды һәм шул ук вакытта көлүгә охшашлы ниндидер авазлар чыгарды.

— Бераз гына сабыр ит әле,— диде мисс Феллоуз.— Тәзәтенеп алыйм әле. Хәзер, тиз генә... Аннары сиңа ашарга әзерләрмен.

Берничә секунд эчендә ул солы боткасы пешереп алды, ботканы өстәлгә китереп куйды да, кул изәп, баланы үзе янына чакырды.

Әллә малай аны аңлады, әллә аңа ботка исе тәэсир итте,— шундук ул караваттан төште.

Мисс Феллоуз аны кашык белән ашарга өйрәтмәкче булып карады, ләкин бала куркып кинәт читкә тайпылды. «Хәзергә ярап торыр, алда әле безнең вакыт күп», дип уйлады мисс Феллоуз. Тик шулай да ул малайның боткалы тәлинкәне авызына күтәреп ашавын таләп итте. Малай буйсынырга мәҗбүр булды. Ботканың күп өлеше авызына эләксә дә, ул аны түгеп, пычранып бетте.

Мисс Феллоузның гаҗәпләнүенә каршы, бала туалетны бик җиңел үзләштерде. Ул аның нәрсә кушканын бик тиз аңлап алды. Мисс Феллоуз җиңел сулап куйды.

— Менә бу әйбәт малай, менә бу акыллы малай! — дип сөйләнде ул, баланың башыннан сыйпап.

һәм бала аңа елмаеп җибәрде. Туташның искәрмәстән күңеле күтәрелеп китте.

Шул ук көнне төштән соң матбугат вәкилләре килде. Алар ачык ишеккә аппаратларын җайлап куйган арада, мисс Феллоуз баланы кулына алды. Малай яратып аның күкрәгенә елышты. Тирә-яктагы ыгы-зыгыга ул куркып, шикләнеп карады һәм кинәт кычкырып җибәрде, ләкин, шуңа да карамастан, туташка аны бары тик бер ун минуттан соң гына күрше бүлмәгә алып чыгарга рөхсәт иттеләр.

Мисс Феллоуз ачудан кызарынып тиз арада кире әйләнеп килде һәм монда уздырган унсигез сәгать вакыт эчендә беренче мәртәбә курчак өйдән тышка чыкты.

— Минемчә, бүгенгә җитеп торыр. Баланы инде тиз генә тынычландырып булмаячак. Барыгыз, китегез моннан, — диде ул.

— Ярар, ярар, — диде «Таймс һеральд»тан килгән джентельмен. — Ул соң чыннан да неандерталь баласымы, әллә бу берәр төрле хәйлә генәме?

— Монда бернинди алдау юк, — дип кычкырды Хоскинс каяндыр арттан. — Бу бала чыннан да Homo neanderthalensis.

— Кызмы, малаймы ул?

— Ул — маймыл-малай, — диде «Ньюс»тан килгән джентельмен, сүзгә катышып. — Әле генә безгә маймыл баласы күрсәттеләр. Үз-үзен ничек тота ул, туташ?

— Дөньядагы барлык кечкенә малайлар үзләрен ничек тотсалар, ул да шулай тота, — диде мисс Феллоуз, үртәлеп. Бу джентельмен алдында ул баланы якларга кирәк тапты. — Аннары, ул маймыл баласы түгел. Аның исеме бар. Ул... Тимоти, Тимми. Ни генә эшләмәсен, аның барлык эше, кыланышы тулысынча нормаль.

Тимоти дигән исемне ул аңа бөтенләй уйламаганда тапты.

— Тимми — маймыл-малай, — диде «Ньюс»тан килгән джентельмен һәм, соңыннан билгеле булганча, бөтен дөньяга ул нәкъ шул исем белән танылды.

— Әйтегезче, доктор, киләчәктә нишләргә уйлыйсыз бу маймыл белән? — диде «Глоб»тан килгән джентельмен, Хоскинска мөрәҗәгать итеп.

Хоскинс иңбашларын җыерып куйды.

— Минем иң беренче бурычым аны безнең чорга күчерергә мөмкин икәнлеген исбат итү иде. Ләкин, минемчә, аның белән антропологлар да, физиологлар да кызыксыначак. Безнең күз алдындагы бу бала — үсеше буенча хайван белән кеше арасындарак торган җан иясе. Бу бала буенча без әле үзебез турында, борынгы ата-бабаларыбыз турында бик күп нәрсәләр белә алырбыз дип ышанырга кирәк.

— Сез аны монда озак тотарга уйлыйсызмы инде?

— Аны өйрәнү өчен күпме вакыт кирәк булса, шулкадәр тотачакбыз. Шуның өстенә, тәҗрибәләр тәмамлангач та әле аны күпмедер вакытка монда калдырырга туры киләчәк. Тәҗрибә өчен, ихтимал, шактый вакыт кирәк булыр.

— Сез аны бу өйдән алып чыга алмыйсызмы? Өйдән алып чыгып булса, ул чагында без телевизион аппаратураны җайлап куяр идек тә менә дигән тамаша әзерләр идек.

— Кызганычка каршы, бу бала «Стасис»тан чыга алмый.

— Нәрсә ул «Стасис»?

— Аны аңлатып тору бик күп вакытны алыр дип куркам, джентельменнар, — диде Хоскинс, елмаеп. — Кыскача гына әйткәндә, мәсьәлә шуңа кайтып кала: «Стасис»та без аңлый торган вакыт юк. Бу бүлмәләр гүя күренми торган тышча белән капланган һәм аларның безнең тормышка, чынбарлыкка бернинди катнашы юк. Менә шуңа күрә дә әлеге баланы вакыт эченнән тартып алырга мөмкин булды да.

— Туктагыз әле, — диде «Ньюс»тан килгән джентельмен, Хоскинсның сүзен бүлеп. Докторның аңлатмалары аны ничектер канәгатьләндереп житкерми иде бугай. — Туктагыз әле, нәрсә булмаганны сөйлисез сез? Бит туташ жиңел генә өйгә кереп-чыгып йөри.

— Туташ кына түгел, сезнең теләсә кайсыгыз өйгә кереп чыга ала, — диде Хоскинс илтифатсыз гына. — Сез вакыт көче сызыкларына янәшә хәрәкәтләнәчәксез һәм моңа карап кына энергия сизелерлек дәрәжәдә кимемәячәк тә, артмаячак та. Бала исә монда бик ерак чордан китерелгән. Аның хәрәкәт итү юлы көч сызыкларына аркылы туры килде, шуңа күрә дә ул вакыт потенциалы алды. Аны бүгенге чынбарлыкка, бүгенге вакытка күчерү өчен безнең барлык энергияне һәм шулай ук, ихтимал, Вашингтон шәһәре энергиясе запасларын тулысынча сарыф итәргә туры килер иде. Без малай белән китерелгән барлык чүп-чарны да сакларга мәжбүр булдык һәм без ул чүп-чарны моннан әкренләп-әкренләп кенә юкка чыгара барачакбыз.

— Бүген кичен сез интервью бирә аласызмы? — диде «Таймс һеральд» вәкиле. — Сезнең интервьюны без барлык каналлар буенча тапшырачакбыз.

— Булыр дип уйлыйм, — диде Хоскинс, ашыгып.

Икенче көнне иртән Хоскинсның йөзе шатлыктан кояштай балкый иде.

— Интервью уңышлы чыктымы соң? — диде мисс Феллоуз.

— Искиткеч шәп булды. Теге... ни... Тимминең хәле ничек?

Аның малайны исеме белән атавын ишетеп, мисс Феллоуз гажәпләнеп китте.

— Хәле бик әйбәт. Тимми, кил әле монда. Бу әйбәт абый, ул сиңа тими.

Ләкин Тимминең күрше бүлмәдән чыгасы килмәде. Ишек артыннан аның бөдрә чәчләре генә күренә һәм әледән-әле куркынган карашлы сыңар күзе генә елтырап-елтырап китә иде.

— Мондагы шартларга малай искиткеч тиз күнегә. Беләсезме, ул чынлап та бик башлы күренә.

— Сезнең шуңа исегез китәме?

— Әйе. Баштарак мин аны маймыл баласы диебрәк уйлаган идем, — диде мисс Феллоуз, беравык икеләнеп торганнан соң.

— Кем генә булмасын, хәзергә ул безнең өчен бик күп файдалы эшләр эшләде. «Стасис Инкорпорейтэд»ның данын күтәреп жибәрде бит ул. Хәзер инде без телгә кердек, мисс Феллоуз, телгә кердек!

Күрәсең, доктор Хоскинсның күңелендә ташыган шатлык хисен кем белән булса да, хәтта мисс Феллоуз белән булса да уртаклашасы килә иде.

— Ничек итеп ул безгә дан китерә алды соң? — дип сорады мисс Феллоуз.

Хоскинс, кулларын кесәсенә тыгып, сөйләвен дәвам итте:

— Ун ел буена эшләү дәверендә безнең кесә шактый такырайган иде. Безгә акчаны каян туры килсә, шуннан алырга, чын-чынлап тиенләп жыярга туры килә иде. Бу тәжрибәне тормышка ашыру өчен без башка максатларга билгеләнгән акчаларны тоттык. Без аны бернинди рөхсәтсез файдаландык. Әгәр тәжрибә барып чыкмаган булса, мин инде күптән бөлгән булыр идем.

— Шуңа күрә дә өйнең түшәме юкмыни? — диде мисс Феллоуз, аны сүзеннән бүлдереп.

— Нәрсә дисез?

— Өйнең түшәмен ябарга акчагыз житмәдеме димен!

— Ә! Беләсезме, аның сәбәбе акча житмәү генә түгел. Дөресен әйткәндә, без неандерталь кешенең яшен төгәл генә билгели алмадык. Бездән бик ерак вакыт белән аерылган объектларның үзенчәлекләрен

төгәл билгеләүдә безнең мөмкинлекләр әлегә бик чикле һәм ул кешенең бик зур гәүдәле, кыргый холыклы булуы ихтимал иде. Ул чагында инде безгә аның белән читлеккә ябылган хайваннар белән эш иткән кебек эш итәргә туры килер иде.

— Шикләнер урын калмагач, хәзер инде түшәмне яптырып алырсыз дип уйларга кирәк.

— Хәзер була. Хәзер безнең акча күп. Безгә мөмкин булган һәртөрле чыганактан акча вәгъдә итәләр. Бик шәп нәрсә бу, мисс Феллоуз. — Доктор Хоскинсның киң йөзеннән бер генә секундка да елмаю билгесе югалып тормады.

* * *

Шул көннән бирле мисс Феллоуз үзен «Стасис Инкорпорейтэд» акционерлар җәмгыятенең аерылмас бер кисәге итеп тоя башлады. Аңа кечерәк бер кабинет бирделәр, кабинет ишегенә аның исеме язылган кечкенә такта беркеттеләр. Кабинет «Стасис»ның мисс Феллоуз «курчак өй» дип йөрткән камерасына якын гына иде. Хәзер инде аңа беренче көннәрдәгегә караганда күбрәк түли башладылар, курчак өйнең, ниһаять, түшәмен яптылар, әчке җиһазларын яхшырттылар.

Мисс Феллоуз Тиммигә шулкадәр ияләшеп китте, — инде ул аның ямьсезлеген бик үк күрми дә башлады.

Тик бер генә нәрсәгә күнегә алмады. Ул да булса — фәнни тәҗрибәләргә катнашу иде. Ул никадәр читтә калырга тырышса да, торган саен үзен бу тәҗрибәләргә шәхси җаваплы итеп тоя башлады һәм еш кына аңа физиологлар белән ачыктан-ачык ызгышырга туры килде.

Бер көнне алар янына Хоскинс килеп керде. Бу вакытта мисс Феллоуз шундый ярсыган иде, — үзен-үзе белештермичә, дошманнарын үтереп ташлый алыр шикелле иде. Аларның бернинди хаклары юк бит! Аларның хакы юк! Ул бала хәтта неандерталь чоры баласы булса да, барыбер хайван түгел, ул — кеше!

Ул, Тимминең үксүен ишеткән хәлдә, ярсуыннан шартлар дәрәҗәгә җитеп, ачык ишектән физиологларның нишләүләрен күзәтеп тора иде. Кинәт үзе янында басып торган Хоскинсны күреп алды, Хоскинс монда күптән инде басып тора иде, ахрысы.

— Керергә буламы? — диде Хоскинс.

Сүзсез генә ым кагып, мисс Феллоуз тизрәк Тимми янына ашыкты. Бала шундук аның күкрәгенә елышты һәм кечкенә ябык куллары белән аны кочаклап алды.

— Мин сезгә катгый рәвештә әйтәм, доктор Хоскинс: Тимми белән шулай кыланырга аларның бернинди хаклары юк. Кайчандыр сез миңа әйткән идегез: Тимминең табылуы «Стасис»ка җан кертеп җибәрде дигән идегез. Әгәр сезнең күңелегездә балага карата тамчы кадәр генә рәхмәт тойгысы булса да, ул бичараны алардан коткарырга тиешсез... Һич югы ул үсеп, үзе аңлар дәрәҗәгә җиткәнче булса да... Аларның кыланышларыннан соң ул тынычлап йоклый алмый, төне буе саташып, ыңгырашып чыга. Мин сезне алдан ук кисәтеп куям: моннан соң мин аларны монда кертмәячәкмен! (Мисс Феллоуз үзенең кычкыра башлаганлыгын аңлап алды, әмма ул үз-үзен тыеп тотар дәрәҗәдә түгел иде инде.)

— Аның неандерталь баласы булуын мин бик яхшы аңлыйм, — диде ул бераздан тынычрак тавыш белән, — ләкин күп кенә нәрсәдә без аларга бәя биреп җиткермибез. Неандерталь чоры кешеләренең үз культуралары булган, алар яшәгән чорда кешенең кайбер бөек ачышлары ясалган. Мәсәлән, алар кыргый хайваннарны кулга ияләштергәннәр, тәгәрмәчне, тегермән ташларының берничә төрен уйлап тапканнар. Аларның, һичшиксез, рухи таләпләре дә булган. Мәетне күмгәндә алар

үлгән кешенең әйберләрен кабердә күмеп калдырганнар, димәк, алар теге дөньяда да тереклек бар дип белгәннәр. Шуңа нигезләнеп, аларның ниндидер дине булган дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Менә шуларның барысы да Тиммигә карата кешечә мөнәсәбәт булырга тиешлеге турында сөйләмимени?

Мисс Феллоуз яратып Тиммине аркасыннан чәбәкләп алды да аны бүлмәгә уйнарга кертеп җибәрде. Ишек ачылгач, Хоскинс, бүлмәдәге бик күп уенчыкларны күреп, шактый гаҗәпкә калды. Ул елмаеп куйды.

— Бичара бала ул уенчыкларга тулысынча лаек, — диде мисс Феллоуз, үз-үзен акларга җыенган сыман. — Аның бар нәрсәсе шул уенчыклар. Ул аларны монда кичергән һәртөрле газаплары белән эшләп ала.

— Юк, юк, мин аның курчакларына һич тә каршы түгел, — диде Хоскинс. — Мин бары бер нәрсә турында гына уйлап куйдым: теге вакытта мин сезгә неандерталь баласын көчләп диярлек таккан чакта сез шундый ризасыз идегез. Шуннан бирле никадәр үзгәреш!

— Минемчә, мин ул кадәр үк ризасыз түгел идем, — диде мисс Феллоуз әкрен генә.

— Сезнеңчә, ничә яшь булыр аңа, мисс Феллоуз? — диде Хоскинс, сүзне икенчегә борып.

— Төгәл генә сезгә берни әйтә алмыйм, чөнки без неандерталь кешеләрнең үсешен күз алдына китерә алмыйбыз, — диде мисс Феллоуз. — Буена карап фикер йөртсәк, аңа өч яшьтән артык биреп булмый. Хәзерге вакытта физиологлар ясый торган төрле «тәҗрибә»ләрне исәпкә алсак, ул инде күптән үсүдән туктаган булырга мөмкин. Әгәр дә инде аның инглиз телен ничек өйрәнүенә карап фикер йөртсәк, аңа дүрт яшьтән артыграк биреп була.

— Шулаймыни? Нишләптер мин сезнең язмаларда аның сөйләргә өйрәнүе турында бер сүз дә очратмадым.

— Миннән башка ул беркем белән дә сөйләшмәячәк... һич югы хәзерге вакытта. Ул һәркемнән курка, һәм монда гаҗәпләнер урын да юк. Мәсәлән, ул берәр төрле ашамлык сорый ала. Үзенең теләсә нинди теләген белдерә һәм мин әйткән барлык нәрсәне диярлек төшенә ала. Хәер, аның аң үсеше тукталып калырга да мөмкин. (Соңгы сүзләрне әйткәндә мисс Феллоуз, әчке бер киеренкелек белән, Хоскинсның йөзендәге үзгәрешкә карап, бу мәсьәләне үзенең тиешле вакытында кузгатканмы-юкмы икәнлеген белергә тырышты.)

— Ник? — диде Хоскинс.

— Һәрбер балага билгеле бер стимуляция кирәк, ә Тимми монда ябылудагы кебек яши. Аның өчен мин көчемнән килгәннең барын да эшлим, ләкин мин бит һәрвакыт аның янында була алмыйм, аннары, мин аңа кирәк булганның барын да бирә алмыйм. Мин сезгә шуны әйтергә телим, доктор Хоскинс: ул икенче бер бала белән уйнарга тиеш.

Хоскинс әкрен генә башын кыйшайтты.

— Кызганычка каршы, бездә андый бала бер генә. Бичара бала.

Аның авызыннан мондый сүз ишетеп мисс Феллоуз шундук йомшап калды.

— Сез бит Тиммине яратасыз, әйеме? — диде ул. Тагын икенче бер кешенең бу баланы яратуын күрү аның өчен бер шатлык иде.

— Әлбәттә, — диде Хоскинс, бераз гына үз-үзен онытып, һәм шул чакны мисс Феллоуз аның күз карашында арыганлык билгесе күреп калды.

Мисс Феллоуз үзенең планын азагына кадәр житкерү турында уеннан шундук баш тартырга мәҗбүр булды.

— Сез бик арыган кебек күренәсез, доктор Хоскинс, — диде ул ихлас бер теләктәшлек белән.

— Шулаймы? Шат күңелле булып күренү өчен миңа шактый көч куярга туры киләчәк.

— Минемчә, «Стасис Инкорпорейтэд»ның күп эше сезгә бер генә минутка да тынгылык бирми.

— Сез хаклы. Анда тагын хайваннар, үсемлекләр, минераллар бар... Карагыз әле, мисс Феллоуз безнең экспонатларны күргәнегез дә юктыр әле сезнең?

— Дөресен әйткәндә, юк. Кызыксынмаган өчен түгел. Соңгы вакытта минем эшләрем күп булды.

— Хәзер инде сезнең вакытыгыз бар, — диде Хоскинс, кинәт кенә кабул ителгән әчке бер карарга буйсынып, күрәсең. — Иртәгә иртән сәгать унберләрдә мин сезнең янга керермен, барысын да үзем күрсәтермен. Ризамы?

— Бик риза, доктор Хоскинс, — диде мисс Феллоуз, елмаеп.

Икенче көнне Хоскинс ачык йөз белән нәкъ әйтелгән вакытка килеп житте. Мисс Феллоуз Тиммигә иртәнге ашның кайдалыгын аңлатты һәм аның кайдан нәрсә алып ашарга кирәклеген белүенә тагын бер кат ышангач, мин тиздән кайтырмын дип, ашыгып саубуллаша башлады.

Хоскинс туташны бинаның яңа бер өлешенә алып китте. Мисс Феллоузның әле беркайчан да анда булганы юк иде.

— Хайваннар, үсемлекләр, минераллар... — дип сөйләнде Хоскинс кичәге кебек. — Хайваннар менә монда — алар безнең иң кызыклы экспонатлар.

Бинаның эчке өлеше бөтенләе белән бүлмәләргә бүленеп беткән иде, һәм ул бүлмәләрнең һәркайсы «Стасис» камерасы булып исәпләнә иде. Мисс Феллоузны Хоскинс шул бүлмәләрнең берсенә, пыяла тәрәзә янына алып килде. Мисс Феллоуз эчкә күз ташлады. Беренче булып аның күзенә күренгән җан иясе баштарак аңа өсте тәңкә белән капланган койрыклы тавык сыман бер нәрсә булып тоелды. Ул тавык сыман нәрсә, матур башын житез генә як-якка боргалап, ике арык аягында селкенгәләп, камера буенча йөреп тора иде. Аның башында әтәч кикриген хәтерләткән сөяк оры тырпаеп тора иде. Кыска алгы аякларының бармак сыман үсентеләре бер өзлексез бер кысыла, бер язылаиде.



— Бу безнең динозавр, — диде Хоскинс. — Ул инде монда берничә ай яши. Аның белән кайчан аерылышырга туры килер — һич әйтә алмыйм,

— Динозавр?
— Ә сез ниндидер коточкыч зур нәрсә күрмәкче булган идегезме?
Мисс Феллоузның бит очларында чокырлар барлыкка килде.
— Минемчә, кайберәүләр аларны нәкъ шундый коточкыч зур нәрсә итеп күз алдына китерәләр. Мин, мәсәлән, кайчандыр, кечерәк гәүдәле динозаврларның да яшәгәнлеген беләм.
— Без менә шушындый кечкенә гәүдәле динозаврны табарга тырыштык та. Кагыйдә буларак, аны һәрвакыт тикшереп торалар, ләкин хәзер күрәсең, аңа бераз ял биргәннәр. Аның ярдәмендә шактый кызыклы ачышлар ясалды. Мәсәлән, аны бөтенләй үк салкын канлы хайван дип әйтеп булмый. Ул үзенең тән температурасын тирә-як температурасыннан югарырак тота ала. Дөрес, аның бу сәләте бик үк камил түгел. Кызганычка каршы, бу ата динозавр. Аны монда тартып чыгарганнан бирле без бертуктаусыз икенче бер динозаврны — моңысында инде ана хайванны эзлибез. Ләкин әлегә тикле уңышка ирешә алганыбыз юк.
— Нигә кирәк ул сезгә ана динозавр?
Хоскинсның күз карашында ачыктан-ачык мыскыл чагылып китте.
— Ана динозавр булса, ул чагында без аталандырылган күкәй ала алган булыр идек. Аннары инде динозавр балаларын да күрергә насыйп булыр иде.
— Әйе шул.
Мисс Феллоузны Хоскинс трилобитлар бүлегенә алып килде.
— Әнә ул кеше — Вашингтон университеты профессоры Дуэйн, — диде Хоскинс. — Ул атом-төш химиясе белгече. Хәтерем ялгышмаса, ул су кислородындагы изотопларның нидән гыйбарәт булын тикшерә.
— Нинди максат белән?
— Ул тикшерә торган су — җир йөзендә кеше барлыкка килгән чордагы су. Ни генә бумасын, ул суның яше кимендә ярты миллиард ел исәпләнелә. Әгәр без ул суның изотопларындагы матдәләрне белә алсак, шул ерак чордагы океаннарның да температурасын белә алачакбыз. Дуэйн үзе трилобитлар белән кызыксынмый, аларны бүтән галимнәр тикшерәләр. Ул галимнәрнең эше рәхәт, аларга бары скальпельләр белән микроскоплар гына кирәк. Дуэйнга исә һәрбер тәҗрибә өчен катлаулы масспектограф җайлап куярга туры килә.
— Ник? Башкача булдыра алмыймыни?
— Юк, булдыра алмый. Аңа бу бинадан бер әйбер дә алып чыгарга ярамый.
Монда шулай ук дөньядагы иң беренче үсемлекләрнең үрнәкләре дә, кыя китекләре дә җыйналган иде. Болар теге Хоскинс әйткән үсемлекләр һәм минераллар иде. Һәрбер экспонат янында тикшеренүче галимнәр кайнаша иде. Боларның барысы да актив фәнни эш үзәгенә әйләнгән, кинәт җанланып киткән ниндидер музейны хәтерләтә иде.
— Боларга турыдан-туры сез җитәкчелек итәсезме, доктор Хоскинс?
— Юк, мисс Феллоуз, аллага шөкер, минем карамакта хезмәткәрләр җитәрлек. Минем мәсьәләнең бары теоретик ягы гына: вакытның эчтәлеге, вакыт ераклыгында яткан объектларны мезон ярдәмендә таба белү һәм шуның өше нәрсәләр генә кызыксындыра. Шуларның барысын да мин үз миң елдан да якынрак вакыт эчендә яткан объектларны таба алу методына бик теләп алыштырган булыр идем. Әгәр дә без җир йөзендә кеше барлыкка килгән чорга үтеп керә алсак...
Шул чакны ерактагы бер камерадан килгән ниндидер шау-шуны ишетеп, ул сүзеннән туктап калды. Анда кемдер нечкә тавыш белән нидер кычкыра иде. Хоскинсның чырае бозылып китте һәм ул бер-ике сүз белән генә гафу үтенде дә ашыгып әлеге тавыш килгән якка китеп барды.
Мисс Феллоуз йөгереп диярлек аның артыннан иярде.

— Миңа тәҗрибәмнең иң әһәмиятле өлешен тәмамларга кирәк икәнлеген аңламыйсызмыни сез? — дип кычкыра иде кызыл битен сирәк сакал-мыек әйләндереп алган олы яшьләрдәге бер кеше. Эш халатына «С. И.» («Стасис Инкорпорейтэд») дигән хәрефләр чигелгән, баштанаяк формалы кием кигән хезмәткәр, Хоскинска мөрәҗәгать итеп:

— Профессор Адемевскийга башта ук: бу экспонат монда бары ике генә атна торачак дип әйтелгән иде, — диде.

— Тәҗрибәм күпме вакытка сузыласын мин ул чакта белмәдем, мин әүлия түгел! — дип кычкырды Адемевский, ярсып.

— Сез бит беләсез инде, профессор, безнең бинаның мәйданы бик чикләнгән, — диде Хоскинс. — Шуңа күрә без үзебездәге үрнәкләрне әледән-әле алыштырып торырга мәҗбүрбез. Бу халькопирит кисәге каян китерелгән булса, шунда кире илтеп куелырга тиеш. Галимнәр яңа экспонатлар көтәләр.

— Нишләп мин аны үз карамагыма ала алмыйм? Миңа аны моннан алып китәргә рөхсәт итегез!

— Мөмкин түгел икәнлеген сез инде беләсездер дип уйлыйм.

— Сез шушы халькопирит кисәген, биш килолы шушы минерал кисәген кызганасызмы? Ник?

— Сез аны моннан алып китсәгез, бик күп энергия юкка чыгачак. Ул безгә бик кыйбатка төшәчәк! Бу турыда сез бик яхшы беләсез, — диде Хоскинс, үртәлеп.

— Беләсезме, доктор Хоскинс, — диде хезмәткәр, аларның сүзен бүлдереп, — билгеле кагыйдәләр булуына да карамастан, профессор минералны үзе белән алып китәргә маташты. Мин, профессорның камера эчендә икәнлеген белмичә, чак-чак кына «Стасис»ны өзми калдым.

Беразга барысы да тынып калды. Хоскинс галимгә таба борылды да салкын гына:

— Дөресме, профессор? — диде.

Адемевский уңайсызланып йөткеренеп куйды.

— Ни... мин аны берәр төрле зыян ясар дип уйламадым...

Хоскинс кулын күтәрде дә камераның тышкы стенасында асылынып торган шнурны тартып җибәрде.

Шушы вакытта әлеге шау-шуны тудырган, ләкин берние белән дә аерылып тормаган ташны кызыксынып караучы мисс Феллоузның кинәт тыны кысылып куйды: таш аның күз алдында юкка чыкты. Камера бушап калды.

— Кызганычка каршы, профессор, сезгә «Стасис»тагы төрле объектларны тикшерү өчен бирелгән рөхсәт кәгазе моннан соң бөтенләйгә юкка чыгарыла, — диде Хоскинс һәм каршы сөйләп маташкан профессорга арты белән борылды да, ярсудан әле булса агарынып мисс Феллоузга:

— Сез минем белән ашарга барудан баш тартмассызмы? — диде.

* * *

Мисс Феллоузны Хоскинс кафетерийның администрация әгъзалары өчен билгеләнгән бүлегенә алып керде.

— Доктор Хоскинс, мондый күңелсез хәлләр монда еш буламы? — диде мисс Феллоуз, кулына чәнечке алып.

— Юк, — диде Хоскинс көчәнеп кенә, — мондый хәл әле беренче мәртәбә булды.

— Бер вакытны сез миңа әйткән идегез бугай: камерадан әйбер алып чыгу бик күп энергияне юкка чыгара дигән идегез.

— Бик дөрес. Ярты секунд чамасы вакыт эчендә без бер еллык энергиядән колак каккан булыр идек. Шулкадәр энергияне югалту безне узган вакыт тирәнлегенә үтеп керү планнарын тормышка ашырудан берничә елга баш тартып торырга мәҗбүр итәр иде. Профессор

мәсьәләсенә килгәндә, таш кисәге белән бергә ул үзе дә туп-туры плиоценга олаккан булыр иде һәм без ташны кайсы чордан алган булсак, нәкъ шул чорга барып төшкән булыр иде.

— Кит аннан!

— Ләкин профессорның язмышы мине әз генә дә борчымый: шундый нәрсә эшләр дәрәҗәдә ахмак булган икән, китә бирсен! Моннан соң яхшы сабак булыр иде. Ләкин күз алдына китерә аласызмы — аның юкка чыгуы бөтен дөньяга билгеле булса, беләсезме, кешеләргә ничек тәэсир итәр иде ул! Безнең тәҗрибәләрнең шундый куркыныч хәлләргә китерүен белсәләр, безгә акча бирүне шундук туктаткан булырлар иде.

Хоскинс мәгънәле генә итеп бармакларын шартлатып куйды һәм караңгы чырай белән алдындагы ашамлыкка сузылды.

— Сез аны кире кайтара алмас идегезме? — диде мисс Феллоуз. — Башта теге ташны ничек табып алган булсагыз, шул ук ысул белән кайтарып булмас идеме?

Юк, чөнки кире озатылган әйбер икенче мәртәбә табылмый... әгәр алдан ук аның белән киләчәктә элемтә тоту күздә тотылмаган булса... Бу очракта исә андый элемтә күздә тотылган дип әйтергә безнең бернинди нигезебез юк.

— Әйберләрне шулай узган чордан хәзерге чорга, хәзерге чордан узган чорга күчерү тарих агышын үзгәртмиме? — диде мисс Феллоуз.

Хоскинс инбашларын җыерып куйды.

— Мәсьәләгә теория ноктасыннан якын килсәң, сезнең сорауга уңай җавап бирергә туры килер иде, ләкин чынында, кайбер гадәттән тыш хәлләрне исәпкә алмаганда, тарих үсеше өчен моның бернинди әһәмияте юк. «Стасис»тан без һәрвакыт ни дә булса алып ташлый барабыз. Әйтик, һава молекулалары, бактерияләр, тузаннар. Без файдалана торган энергиянең ун процент чамасы менә шундый югалтуларны каплауга китә. Ләкин чагыштырмача зуррак әйберләрне бер чордан икенче чорга күчерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр дә тиз арада бетә бара.

— Табигатькә китергән зыянны табигать үзе бетерә бара димәкче буласызмы?

— Билгеле бер дәрәҗәдә шулай. Ләкин әйберләрне узган чордан бүгенге көнгә яисә бүгенге көннән узган чорга күчерсәк, ул чагында сизелерлек дәрәҗәдә зыян киләчәк. Әгәр дә без берәр гади кешене күчерсәк, яра әле үзеннән-үзе төзәлергә дә мөмкин. Көн саен без Авраам Линкольнны, яисә Мөхәммәтне, яки Цезарьны бүгенге көнгә күчерүне сорап язган бик күп хатлар алабыз. Без, әлбәттә, аларның сүзен тыңлый алмыйбыз. Хәтта аларны эзләп тапсак та, кешелек тарихының үсешендә шундый зур урын тоткан кешеләрне бер чордан икенче чорга күчерү чынбарлыкка коточкыч зур зыян китергән булыр иде. Һәм ул кадәр зыянны берни белән дә бетереп булмас иде. Без теге-бу объектны бер чордан икенче чорга күчерүнең тарих үсешенә ни дәрәҗәдә тәэсир иткәнлеген билгеләү өчен тиешле математик исәпләүләр ясыйбыз һәм моның аерым методлары бар. Без соңгы чиккә якынлашмас өчен барлык көчебезне куеп тырышабыз.

— Димәк, Тимми... — диде мисс Феллоуз, сүзгә башлап.

— Бу мәсьәләдә аның эшләре әйбәт. Чынбарлыкка бернинди куркыныч юк. Шулай да... — доктор Хоскинс мисс Феллоузга тиз генә сынаулы бер күз карашы ташлап алды. — Юк, берни юк. Кичәгенәк сез Тиммигә балалар белән аралашырга кирәк дигән идегез бугай.

— Әйе, — диде мисс Феллоуз, куанычлы елмаеп. — Мин сезне һич тә минем үтенечемә игътибар иткәнсездер дип уйламаган идем.

— Ник? Мин күңелемдә балага карата иң җылы хисләр саклыйм һәм сезнең аңа булган мөнәсәбәтегезне чын күңелдән хуплыйм. Ләкин,

никадәр генә изге теләктә булсак та, Тиммигә без беркаян да аның яшьтәшен таба алмыйбыз.

— Таба алмыйбыз? — диде мисс Феллоуз, каушап.

— Мин бит сезгә әле генә аңлаттым. Аның яшендәге икенче неандерталь баласын табарга безнең өметебез юк. Андый гадәттән тыш уңышка ирешүне без башыбызга да китерә алмыйбыз.

— Ләкин сез мине дөрес аңламагансыз, доктор Хоскинс, — диде мисс Феллоуз, кашыгын бер читкә куеп, кискен генә. — Мин һич тә сезнең тагын бер неандерталь баласын безнең чорга күчерүегезне теләмим. Моның мөмкин түгеллеген мин бик яхшы аңлыйм. Ләкин Тимми белән уйнарга «Стасис»ка икенче бер баланы алып килергә була бит.

— Кеше баласынмы? — диде Хоскинс, шаккатып,

— Башка баланы, — диде мисс Феллоуз һәм шул чакны ул Хоскинска карата булган ялкынлы тойгысының дошманлык тойгысы белән алышынганлыгын сизде. — Тимми — кеше бит!

— Бу турыда минем уйлап та караганым булмады.

— Ник? Ник сез нәкъ шул турыда уйламадыгыз? Моның нинди начарлыгы бар? Сез баланы аның чорыннан тартып алдыгыз, аны мәңге ябылуда яшәүгә дучар иттегез, шулай булгач, нишләп әле сез үз генә булса да аның алдында үзегезне бурычлы санамыйсыз? Доктор Хоскинс, әгәр дә бу дөньяда биологик сыйфатлардан башка барлык күрсәткечләр буенча кем дә булса аның атасы булып исәпләнә алса, ул кеше — сез. Шулай булгач, ник сез аның өчен шундый кечкенә яхшылыкны да эшләргә теләмисез?

— Мин аның... атасы? — диде Хоскинс, өстәл янынна ничектер уңайсыз гына кузгалып. — Әгәр сез каршы килмәсәгез, мин сезне кире «Стасис»ка озатып куярмын, мисс Феллоуз.

Алар кире курчак өйгә кайттылар. Берсе дә бер сүз эндәшмәде.

* * *

Очраклы гына бер-берсенә күз төшереп алуларны исәпләмәгәндә, мисс Феллоуз шактый вакыт Хоскинс белән очрашмады. Менә бер вакыт кәтмәгәндә курчак өй янында докторның тавышы ишетелеп китте — ул туташны үзе янына чакыра иде.

Формалы халат якаларын, итәкләрен төзәткәләп, ашыгып, мисс Феллоуз өйдән чыкты һәм каршысында урта буйлы зифа бер хатынкызны күреп, уңайсызланып, кинәт туктап калды. Аксыл чәчле, ак чырайлы булганга, бу хатын ничектер хәлсез шикелләрәк күренә иде. Хатынның күлмәк итәгенә ныгытып тотынган көе, түгәрәк битле, зур күзле өч-дүрт яшь чамасындагы бер бала басып тора иде.

— Кадерлем, менә бу мисс Феллоуз, малайны караучы шәфкать туташы, — диде Хоскинс. — Мисс Феллоуз, минем хатын белән таныш булыгыз.

Мисс Феллоуз, үз-үзен мәҗбүр итеп, хатын белән тыныч кына, иркен генә исәнләште.

— Хәерле көн, мисис Хоскинс. Бу сезнең... малаймы?

— Әйе, бу минем улым Җерри, — диде Хоскинс. — Җерри, исәнләш мисс Феллоуз белән.

(«Бу» сүзенә җиңелчә генә басым ясап әйтте түгелме соң ул? Шуның белән ул аңа: бу — неандерталь баласы түгел, **минем** улым дигәнне сиздерергә теләмәде микән?)

Җерри, әнисенең итәгеннән ычкынырга теләмичә, бераз гына алга атлады да, авыз эченнән мыгырданып исәнләшү сүзләре әйтте. Мисис Хоскинс, үзен бик нык кызыксындыра торган берәр нәрсәне күрмәкче булган сыман, үрелеп, мисс Феллоузның җилкәсе аша ничек тә бүлмә эчен күрергә тырышты.

— Әйдәгез, алайса, «Стасис»ка керик, — диде Хоскинс. — Әйдә, кер, кадерлем. Анда кергәндә сиңа бераз гына күңелсез тойгы кичерергә туры килер, ләкин шулай да курыкма — тиз бетәр.

— Сез Җеррины да алып кермәкче буласызмы? — диде мисс Феллоуз.

— Әлбәттә. Ул Тимми белән уйнаячак. Сез бит әйткән идегез Тиммигә уйнарга иптәш кирәк дип. Бәлки, сез инде ул турыда оныткансыздыр да?

— Ләкин... — диде мисс Феллоуз һәм аның Хоскинска юнәлгән күз карашында тирән бер гаҗәпләнү билгесе чагылды. — Бу сезнең малаймы соң?

— Кемнеке булсын тагын? — диде Хоскинс, үртәлеп. — Сез үзегез шуны теләдегез түгелме соң? Әйдә, акыллым. Әйдә кер.

Мисис Хоскинс, үз-үзен мәҗбүр итеп, Җеррины кулына күтәрде һәм бусага аша атлады. Җерри шыңшый башлады: «Стасис»ка кергәндә һәркем кичерә торган күңелсез тойгы аңа, күрәсең, бик үк ошамады.

— Кая соң теге җан иясе? — диде мисис Хоскинс нечкә генә тавыш белән. — Мин аны күрмим.

— Тимми, кил монда! — диде мисс Феллоуз, баланы чакырып.

Тимми ишек артыннан башын күрсәтте дә үзенә кунакка килгән малайга күзләрен зур ачып карап тора башлады. Мисис Хоскинсның куллары сизелерлек дәрәҗәдә киеренкеләнеп калды.

Ул үзенең иренә таба борылып:

— Син аның куркыныч түгеллегенә ышанасыңмы, Җеральд? — диде.

— Әгәр сез Тимми турында әйтсәгез, аның бернинди куркынычы юк, — диде мисс Феллоуз, шундук сүзгә катышып. — Ул бик тыныч, сүз тыңлаучан малай.

— Ләкин ул бит кы... кыргый.

(Менә ничек икән! Газеталарда маймыл-малай турында язган нәрсәләрнең нәтиҗәсе инде бу.)

— Ул һич тә кыргый түгел, — диде мисс Феллоуз, һәр сүзенә басым ясап. — Биш яшьлек бала ни дәрәҗәдә тыныч, акыллы булса, ул да шулай ук тыныч, акыллы. Киң күңеллелек күрсәтеп, малаегызга Тимми белән уйнарга рөхсәт итүегез бик яхшы, мисис Хоскинс. Мин чын күңелдән сезнең борчылмавыгызны үтенәм.

— Мин әле риза булырмын дип уйламыйм, — диде мисис Хоскинс, үртәлеп.

— Без бит инде мәсьәләне хәл иттек, кадерлем, — диде Хоскинс. — Минемчә, яңадан бәхәс кузгатып торуның кирәге юк. Төшер Җеррины идәнгә.

Хоскинс ханым ирен тыңларга мәҗбүр булды. Малай, аркасы белән әнисенә сыенган килеш, күрше бүлмәдәге балага текәлеп калды. Күрше бүлмәдәге малай да аннан күзен алмый карап тора иде.

— Тимми, кил әле монда, — диде мисс Феллоуз, — кил, кил, курыкма.

Әкрен генә атлап Тимми бу як бүлмәгә чыкты. Хоскинс иелеп, Җерриның бармакларын әнисенең итәгеннән ычкындырды.

— Бераз арткарак кит, кадерлем, балаларга танышырга ирек бир.

Малайлар бер-берсенә кара-каршы туктап калдылар. Җерри, Тиммидән яшьрәк булса да, буйга озынрак иде, һәм аның төз гәүдәсе, гәүдәсенә ярашлы гына булган матур башы янында Тимминең гадәттән тыш ямьсезлеге беренче көннәрдәге кебек дип әйтерлек күзгә ташланып тора иде.

Мисс Феллоузның иреннәре калтыранып китте.

Беренче булып неандерталь малай сүз башлады.

— Исемең ничек синең? — диде ул нечкә генә тавыш белән һәм, кунакны ныгытыбрак карарга теләгән сыман, йөзен генә ана таба якынайтты.

Көтелмәгән мондый хәлдән Җерри сискәнеп китте һәм җавап урынына Тиммигә нык кына итеп сугып җибәрде. Тимми, чайкалып, идәнгә барып төште. Балалар икесе дә кычкырып җыларга тотындылар. Мисис Хоскинс ашыгып Җерриның кулыннан тотып алды. Шул ук вакытта мисс Феллоуз да, күнелендә кузгалган ярсуын тыярга тырышып, кызарынып, Тиммине күтәреп алды да тынычландыра башлады.

— Әнә алар беренче күрүдән үк бер-берсен яратмадылар, — диде Хоскинс ханым.

— Алар урынында башка балалар булса, алар да шулай беренче күрешүдә үк бер-берсен яратмаган булырлар иде, — диде Хоскинс талчыккан кыяфәт белән. — Ә хәзер Җеррины идәнгә төшер, бераз иялансен. Дөресен әйткәндә, иң яхшысы, безгә моннан китәргә кирәк. Бераз вакыттан соң мисс Феллоуз Җеррины минем янга кабинетка китереп куяр, ә мин аны ничек тә өйгә озатып куярга тырышырмын.

Балалар әз генә дә бер-берсен исләреннән чыгармадылар. Җерри туктаусыз җылады да җылады һәм, мисс Феллоуз янына китәргә куркып, әледән-әле әнисен чакырды. Бары тик беркадәр вакыттан соң гына ул, ниһаять, мисс Феллоуз кулыннан конфет алды, юана башлады. Мисс Феллоуз Тиммигә дә конфет бирде, һәм бер сәгатьтән балаларның икесен дә шакмаклар белән уйнарга күндерә алды. Дөрес, балаларның берсе бер почмакта, икенчесе икенче почмакта уйнады.

Ул көнне Җеррины әтисе янына илткәндә мисс Феллоузның Хоскинска карата рәхмәт тойгысыннан күңеле шулкадәр йомшаган иде, — куанычыннан җылап җибәрмәс өчен ул күз яшьләрен көчкә тыеп торды.

Әкренләп-әкренләп бу шулай бер гадәткә кереп китте. Атнасына ике мәртәбә Җеррины берәр сәгатькә Тимми белән уйнарга алып килделәр. Соңыннан ул бер сәгатьне ике сәгатькә кадәр озайттылар. Шулай итеп, балалар таныштылар, бер-берсенең гадәтләрен белә башладылар һәм бергәләп уйный торган булып киттеләр.

Хоскинска карата булган рәхмәт тойгысы әкренләп сүрелә башлагач, мисс Феллоуз үзенең Җеррины яратмаганлыгын аңлады. Тиммигә караганда ул эре сөяклерәк иде һәм, гомумән, ул бар яктан да өстенрәк иде. Тимми янында ул баш булырга ярата иде һәм, ни генә эшләмәсеннәр, аны гел буйсынган итеп калдыра иде.

Җерри белән уйнавы никадәр кыен булмасын, шулай да аның килүен Тимми көннән-көн түземсезләнебрәк көтә башлады. Бары тик шул гына мисс Феллоузны балалар арасында барлыкка килгән тигезсезлек белән килешергә мәҗбүр итә иде.

* * *

— Мисс Феллоуз, мин кайчан мәктәпкә барырмын икән? — диде бер вакыт Тимми.

Мисс Феллоуз аның җавап көтеп ялварган коңгырт күзләренә карады да йомшак кына итеп куе бөрдә чәчләреннән сыйпады.

— Каян белдең әле син мәктәп турында? — диде ул.

— Җерри мәктәпкә йөри. **Балалар бакчасына**, — диде малай, сүзләрне ачык әйтергә тырышып. — Тегендә ирекгә Җерри төрле урыннарда була. Мин кайчан ирекка чыгармын икән, мисс Феллоуз?

Туташның аны кызганудан йөрәге кысылып куйды. Үзе беркайчан да аяк баса алмаячак тышкы дөнья турында Тимминең котылгысыз рәвештә беләчәген, торган саен күбрәк беләчәген һәм моңа каршы үзенең берни эшли алмаячагын мисс Феллоуз, әлбәттә, бик яхшы аңлады.

* * *

Жерри юк чагында Тимми зур кызыксыну белән төрле рәсемнәр карады, ә мисс Феллоуз кычкырып ана сәгатьләр буе китаплар укыды.

Гап-гади хикәядә дә Тимми өчен аңлашылмаган бик күп нәрсәләр бар иде. Ана «Стасис»ның өч бүлмәсеннән читтә — тышта булган иң гади нәрсәләрне дә аңлатырга туры килә иде. Хәзер ул, күңеленә тышкы дөнья килеп кергәч, еш кына төшләр күрә башлады.

Төшендә ул гел бер үк нәрсәләр — үзе яшәгән курчак өйдән тыштагы, үзе күрмәгән-белмәгән ниндидер нәрсәләр күрә иде. Мисс Феллоузга ул булдыра алганча сөйләргә тырышып карады. Төшендә үзен һәрвакыт ниндидер зур, буш дөньяда итеп күрә иде ул. Үзеннән башка анда тагын ниндидер балалар һәм китаптан укыганда бик үк аңлашылып житмәгән күренешләр тәэсирендә туган ниндидер аңлаешсыз, сәер әйберләр була иде. Яисә, аңа бик борынгы заманнардагы күренешләр, үзе әле неандерталь кешеләре арасында яшәгән чагындагы һәм күптән инде онытылып бетә язган күренешләр тыңгы бирми иде. Йокыдан уянганда аның күзләре һәрвакыт яшьле була иде.

Тиммине тынычландырмакчы булып, шаяртып, мисс Феллоуз аның төшләреннән көлгән булды, ләкин үз бүлмәсендә ул еш кына төннәрен күз яшьләре түгеп чыкты.

Бервакытны мисс Феллоуз кычкырып китап укыганда, Тимми кулын аның иягенә сузды да, туташның йөзен иплән кенә китаптан аерды, һәм аны үзенә таба каратты.

— Мисс Феллоуз, нәрсә әйтергә кирәклеген сез каян беләсез? — диде ул.

— Менә бу билгеләрне күрәсеңме? Нәрсә әйтергә кирәклеген менә шуларга карап беләм, аннары сиңа сөйлим. Бу билгеләрне кушкач, сүзләр барлыкка килә.

Тимми аның кулындагы китапны алды да кызыксынып озак кына хәрефләргә карап торды.

— Кайбер билгеләр бөтенләй бер-берсенә охшаган, — диде ул.

Малайның зирәклегенә куанып мисс Феллоуз көлеп җибәрде.

— Дөрес. Теләсәң, мин сиңа ул билгеләрнең ничек язылганын күрсәтермен.

— Күрсәтегез. Бик кызык уен булыр бу.

Берничә атнадан соң мисс Феллоуз моның әһәмиятен бөтен тулылыгы белән аңлый алды һәм ул, ни әйтергә дә белмичә, шактый аптырашта калды. Тимми, аның тезе өстенә утырган килеш, бер генә сүзне дә төшереп калдырмыйча, кычкырып балалар китабы укый иде. Ул укый иде!

Соң дәрәҗәдә тәэсирләнеп, мисс Феллоуз урыныннан торды.

— Мин хәзер килермен, Тимми, — диде ул. — Миңа доктор Хоскинсны күрергә кирәк.

Аның күңелен чиксез шатлык биләп алды. Ниһаять, Тиммине күпмедер дәрәҗәдә бәхетле итә алырдай чара таба алыр шикелле тоелды аңа.

* * *

Ул Хоскинс янына килеп кергәндә, ни сәбәптәндер докторның да кәефе нәкъ аныкы шикелле иде: аның бөтен йөзеннән тыелгысыз шатлык һәм тантана нуры бөркелеп тора иде. Идарәдә гадәттән тыш жанлылык сизелә иде. Мисс Феллоуз, аптыраган бер кыяфәттә кабул итү бүлмәсендә туктап калгач, бүген доктор Хоскинс белән сөйләшеп тә булмас әле дигән бер фикергә килде.

Ләкин Хоскинс аны күреп алды, киң йөзендә елмаю балкып китте.

— Килегез монда, мисс Феллоуз, — диде ул.

Селекторга тиз-тиз генә нидер әйтеп бетерде дә кнопканы ычкындырып куйды.

— Ишеттегезме әле сез?.. Юктыр, билгеле. Сез әле берни белә алмыйсыз. Теләгебезгә ирештек бит! Хәзер инде без бик үк ерак булмаган чорлардагы кешеләрне дә эзләп таба алабыз.

— Хәзер тарихи чордагы кешеләрне дә безнең чорга кайтарырга мөмкин дип әйтмәкче буласызмы? — диде мисс Феллоуз, үз-үзен беразга күңелле уйларыннан онытылып торырга мәҗбүр итеп.

— Сез мине бик дөрес аңладыгыз. Һәм менә без әлерәк кенә ундүртенче гасырда яшәгән бер индивидуумны эзләп таптык. Бу вакыйганың никадәр әһәмиятле икәнлеген күз алдына китерә алсагыз иде! Мин шундый шат! Ниһаять, мин хәзер бөтен көчне очы-кырые күренмәгән мезозой чорына сарыф итүдән котылачакмын. Палеонтологларны тарихчылар белән алыштыра алуга мин куанып бетә алмыйм... Сезнең миңа ниндидер сүзегез бар, ахрысы? Әйдә, әйтегез, ниләрегез бар анда? Минем кәеф яхшы чакта туры килдегез, мин сезгә ни теләсәгез, шуны эшләргә әзер.

— Мин бик шат, — диде мисс Феллоуз, елмаеп. — Мине бер мәсьәлә кызыксындыра: Тимми өчен без укыту системасы эшли алмас идек микән?

— Укыту? Нинди укыту?

— Нинди дип... гомуми белем дәрәҗәсендә... мин мәктәп турында әйтәм. Аңа укырга мөмкинлек бирергә кирәк.

— Ләкин ул **укый аламы соң?**

— Әлбәттә. Ул инде укый белә. Ул китап укый ала, мин аны үзем өйрәттем.

Мисс Феллоузга Хоскинсның кәефе кинәт бозылды шикелле тоелды.

— Ни дип әйтергә дә белмим инде мин сезгә, мисс Феллоуз, — диде Хоскинс.

— Ләкин бит сез әле генә минем теләсә нинди теләкне үтәргә сүз биргән идегез...

— Мин аны онытмадым. Кызганычка каршы, бу очракта мин уйламыйчарак әйтеп ташлаганмын. Беләсезме нәрсә, мисс Феллоуз, безнең Тимми белән тәҗрибә ясауны мәңге дәвам итә алмаячагыбызны сез бик яхшы аңлыйсыздыр дип уйлыйм.

Мисс Феллоузның кинәт йөрәге жу итеп китте һәм ул, әле генә Хоскинс әйткән сүзләрнең мәгънәсен тулысынча аңлый алмыйча, аның күзләренә текәлеп калды. «Дәвам итә алмау» дигән сүзе белән нәрсә әйтмәкче була ул? Аның зиһенен яшен яктысыдай кинәт бер нәрсә яктыртып җибәрде — ул профессор Адемевскийны һәм «Стасис»та ике атна торганнан соң кире озатылган минералны исенә төшерде.

— Бит хәзер таш кисәге турында сүз бармый, бала турында...

Хоскинс шактый уңайсыз хәлдә калды.

— Мондый очракта хәтта балага да кирәгеннән артык игътибар итәргә ярамый. Хәзер... озакламый без тарихи чорда яшәгән кешеләрне тартып чыгарырга өметләнеп торган бер вакытта безгә «Стасис»ның барлык бүлмәләре дә кирәк булачак.

Мисс Феллоуз һаман да төшенеп бетә алмады.

— Ләкин сез аны эшләмәячәксез. Тимми... Тимми...

— Ярар инде, ярар, һәрбер сүзне шулкадәр күңелегезгә якын алмагыз, мисс Феллоуз. Кем белә, Тимми әле, бәлки, монда тагын берничә ай торыр. Шул вакыт эчендә без аның өчен кулдан килгән барлык нәрсәне эшләргә тырышырбыз.

Мисс Феллоуз, берни әйтмичә, һаман да аңа карап торуында булды.

— Берәр нәрсә эчәсегез килмиме, мисс Феллоуз?

— Юк, миңа берни кирәкми, — диде мисс Феллоуз, пышылдап,

Үзенең нишләгәнен бик үк аңлап житмәстән, аягына басты һәм, ниндидер куркыныч төштән арынып житә алмагандай, әкрен генә бүлмәдән чыгып китте.

«Син үлмәячәксең, Тимми, син үлмәячәксең», — дип уйлады ул.

* * *

Шул вакыттан бирле аның күңеленә ничек кенә булса да Тиммине саклап калырга кирәк дигән уй кереп утырды. Ләкин уйлау бер нәрсә, уйлаганны тормышка ашыру — икенче нәрсә. Баштарак мисс Феллоуз ундүртенче гасырдан берәр кешене бүгенге көнгә күчерү уңышсызлыкка очрар дигән өмет белән яшәде. Тәжрибә теориясе күзлегеннән караганда, Хоскинсның берәр төрле хата жибәрүе ихтимал иде, шулай ук ул теорияне тормышка ашыру методында да берәр төрле житешсезлек булуы мөмкин иде. Ул чагында инде бөтен нәрсә элеккечә калачак иде.

Мисс Феллоуздан кала бөтен дөнья халкы, билгеле, әлеге тәжрибәнең уңышлы чыгуын тели иде, һәм мисс Феллоуз, акыл кушканга каршы булса да, шуның өчен бөтен дөньяны дошман күрә башлады. «Урта гасыр» дип аталган проект тирәсендәге шау-шу соңгы чиккә житте: матбугат һәм жәмәгатьчелек ниндидер гадәттән тыш вакыйгага сусаган иде. «Стасис Инкорпорейтэд» акционерлар жәмгыятенең күптән инде андый гадәттән тыш вакыйга биргәне юк иде. Берәр яңа таш яки жир астында катып калган балыклар инде беркемне дә кызыксындырмый иде. Бу исә нәкъ менә һәркем көткән вакыйга иде.

Тарихи чорда яшәгән кеше ул — хәзерге вакытта да аңлашылмаган ят телдә сөйләшүче олы яшьтәге индивид булачак иде. Галимнәргә ул тарихның бүгенге көнгә кадәр билгесез булган битләрен ачыкларга ярдәм итәчәк иде.

Мисс Феллоузның күңелендә кайнаган һәртөрле хис-тойгылар арасында бары бер генә тойгы юк иде — тәжрибәне ул һич тә башкалар кебек түземсезләнеп көтмәде. Гадәттәгечә Тимми белән уйнарга кечкенә Жерри килгәч, баланы бөтенләй диярлек танымады. Бүген Жерри мисс Феллоуз көткән бала түгел иде.

(Хоскинсның улын китергән секретарь хатын мисс Феллоузга баш какты да шундук китеп тә барды. Ул «Урта гасыр» проектын тормышка ашырганны карап тору өчен яхшырак урын алып калырга ашыга иде бугай. Мисс Феллоуз ачынып уйлап куйды: әгәр теге ахмак кыз тизрәк килсә, мин дә анда булган булыр идем инде диде. Тәжрибә вакытында анда булу өчен аңа, гади кызыксынудан башка, әлбәттә, житдирәк сәбәпләр дә бар иде.)

— Мисс Феллоуз, — диде Жерри, икеләнеп, оялчан гына һәм кесәсеннән ниндидер газета кисәге алды да туташка таба атлап куйды.

— Нәрсә? Нәрсә ул кулында, Жерри?

— Бу Тимминең фотографиясе.

Мисс Феллоуз балага бер күз карашы гына ташлады да, тиз генә аның кулындагы газета кисәген тартып алды. «Урта гасыр» проектына бәйләнешле рәвештә туган күтәренкелек матбугатта Тимминең шәхесенә карата яңадан беркадәр кызыксыну уяткан иде.

Жерри бирелеп мисс Феллоузның йөзен күзәтте.

— Анда Тимми турында маймыл-малай дигәннәр. Нәрсә ул, мисс Феллоуз?

Мисс Феллоуз кисәк кенә малайның кулыннан эләктереп алды һәм аны тәпәләп ташлаудан көчкә тыелып калды.

— Беркайчан да андый сүзне әйтмә, Жерри. Беркайчан да, аңлыйсыңмы? Ул әшәке сүз, син аны беркайчан да кулланмаска тиеш.

Шүрләп калган Жерри аның кулыннан ычкынырга азаплана башлады.

— Хәзер бар, өйгә кер, Тимми белән уйна. Ул сиңа үзенең яңа китабын күрсәтер.

Көткән кыз, ниһаять, килеп житте. Мисс Феллоузның моңарчы әле аны күргәне юк иде. Берәр эш буенча аңа курчак өйдән китәргә туры килгәндә «Стасис»ның кайбер даими хезмәткәрләре аның урынына калып торалар иде. Ләкин хәзер, «Урта гасыр» проекты тормышка ашырылганда, хезмәткәрләрнең берсе дә аңа ярдәм итә алмады. Шулай да Хоскинсның секретаре берәрсен табарга вәгъдә итте, һәм әлеге кыз менә шул «берәрсе» булырга тиеш иде.

— «Стасис»ның Беренче секциясенә беркетелгән кеше сез буласызмы? — диде мисс Феллоуз, тавышы калтыранганны сиздермәскә тырышып.

— Әйе, мин. Минем исемем — Мәнди Террис. Ә сез мисс Феллоузмы?

— Әйе. Керегез тизрәк, безнең вакыт бик аз калды.

* * *

Өйдә беркадәр тоткарлану сәбәпле, ул яхшы урын ала алмады. Бик авырлык белән бары Җыелышлар залының экранына кадәр генә барып житте, һәм шул чакны аның күңелен үкенү ачысы өтеп алды. Әгәр дә ул тәҗрибә ясала торган урынга якынрак бара алган булса, әгәр дә ул берәр сизгер прибор янына ук үтеп керә алган булса, әгәр дә ул берәр ничек тәҗрибәне өзә алган булса, ул чагында... Аның күңелен тыелгысыз бер ачу-ярсу биләп алды, шулай да ул үз-үзен тыеп калды. Бит приборларны бозып кына ул берни дә эшли алмас иде. Алар барыбер аны төзәтерләр иде дә тәҗрибәне яңадан кабатларлар иде... Аңа инде Тимми янына керергә беркайчан да рөхсәт итмәсләр иде.

Мисс Феллоузга берни ярдәм итә алмый иде. Әйе, тәҗрибәнең үзеннән-үзе уңышсыз чыгуы мөмкинлегеннән башка, һәм уңышсыз чыкканда да, беркайчан да яңадан кабатлана алмаслык дәрәҗәдә уңышсыз чыгуы мөмкинлегеннән башка аңа берни дә ярдәм итә алмый иде.

Шулай да аның өмете акланмады. Менә соңгы секундлар да үтеп китте һәм бик тыныч кына, бернинди шау-шусыз гына тәҗрибә уңышлы рәвештә тәмам булды!

«Стасис»ның күптән түгел салынган яңа бинасында аягына агач башмак кигән, өс киеме пычранып, ертылып беткән, сакал-мыеклы, бөкре бер авыл агае басып тора иде. Болай карап кына аңа күпме яшь икәнлеген белерлек түгел иде. Тупас бер кыяфәттә ул, коты алынып, тирә-якка карана иде, һәм аның аңы кинәт кенә булган бу үзгәрешне һич тә кабул итә алмый иде, ахрысы.

Бөтен дөнья шатлыктан нишләргә белми шашынганда, кайгысыннан тораташтай катып калган мисс Феллоуз тирә-яктагы ыгы-зыгы арасында ялгыз башы басып тик торды. Кемнәрдер аны этеп җибәрде, кемдер аягы белән тибеп китте, кемнәрдер төртеп җибәрделәр... бары аяк астына гына салып таптамадылар; ул, чәлпәрәмә килгән өметләренең авырлыгыннан башын иеп, куанычыннан нишләргә белмәгән халык уртасында тик басып торды.

Репродукторның карлыккан тавышы кинәт үз исемен кычкырып әйткәндә дә ул берни аңламады, һәм исеме бары тик өч мәртәбә кабатлангач кына ул үзен каядыр чакыруларын төшенеп алды.

— Мисс Феллоуз, мисс Феллоуз, сезне «Стасис»ның Беренче секциясенә чакыралар. Мисс Феллоуз, мисс Феллоуз... — диде репродуктор.

Бер секундка да туктап тормыйча, репродуктор бер үк сүзләрне кабатлый башлагач, кинәт ул:

— Каяле, юл бирегез! — дип кычкырып җибәрде,

Соңгы көчен жыеп, тирә-яктагы кешеләрне этә-төртә халык арасыннан алга омтылды. Берни алдында тукталып тормыйча, хәтта йодрыкларын эшкә җигеп, әледән-әле кешеләр арасында буталып, ул әкренләп-әкренләп шулай да ишеккә таба хәрәкәтләнде.

* * *

Ул килеп кергәндә, Мэнди Террис җылап тора иде.

— Кем белгән аны шулай булыр дип... Коридор башына куелган кечкенә экран янына бераз гына китеп барган идем. Бер-ике минутка гына.

— Тимми кая? — диде мисс Феллоуз, берни күрми торган күзләре белән кызга карап. Мэнди Террисның бөтен тәне дер-дер калтырана иде.

Шундагы шәфкать туташларының берсе кычкырып җылаган Җерриның кулын дезинфекатор белән сөртә, икенчесе агулануга каршы инъекция ясарга шприц әзерли иде.

— Ул минем кулны тешләде, мисс Феллоуз, — дип кычкырды Җерри, ярсуына буылып. — Ул минем кулны тешләде!

Ләкин мисс Феллоуз аңа сыңар күзе белән дә карамады.

— Нишләттегез Тиммине? — диде ул.

— Мин аны ванна бүлмәсенә ябып куйдым, — диде Мэнди. — Мин ул кечкенә хәшәрәтне шунда төртеп җибәрдем дә ишекне бикләп куйдым.

Мисс Феллоуз курчак өйгә ашыкты. Ванна бүлмәсенең ишек төбендә үк туктап калды; ишекне ачканчы һәм почмакка поскан баланы эзләп тапканчы, әйтерсең, бөтен бер гасыр үтеп китте.

— Кыйнамагыз мине, мисс Феллоуз, — диде Тимми, пышылдап. Күзләре аның кызарынып беткән, иреннәре калтырый иде. — Мин аны тешләргә теләмәгән идем.

— О, Тимми, нишләп әле син мине кыйнар дип уйлыйсың? — диде мисс Феллоуз. Баланы кулына алды да, каты итеп күкрәгенә кысты.

— Мэнди әйтте, сез мине озын бау белән кыйнаячаксыз дип әйтте. Ул әйтте, сез мине кыйнарсыз да кыйнарсыз дип әйтте... — диде Тимми, буталып, дулкынланып.

— Сине беркем кыйнамаячак. Алай дип әйтеп ул бик начар эшләгән.

— Нәрсә булды соң шулай да? Нишләдегез?

— Җерри мине маймыл-малай диде. Ул әйтте, син чын кеше түгел, диде, хайван диде.

Тимминең күзләреннән яшьләр тәгәрәп төште.

— Ул әйтте, мин маймыл белән уйнарга теләмим, диде. Мин әйттем, мин маймыл түгел, дидем. Мин маймыл түгел! Аннары ул әйтте, сиңа карасаң көләсе килә, диде, син бик ямьсез, диде. Ул бик күп әйтте, шуннан мин түзмәдем, тешләдем дә алдым.

Хәзер инде алар икәүләп җылыйлар иде.

— Ләкин син бит ул әйткән сүзләрнең дөрес түгеллеген үзең дә беләсең, Тимми, — диде мисс Феллоуз, үксеп. — Син чын малай. Бөтен дөньяда син иң яхшы малай. Беркем дә, беркем дә беркайчан да сине тартып ала алмаячак.

* * *

Хәзер инде тәвәккәлләү ул кадәр үк авыр түгел иде аңа. Хәзер инде ул, ниһаять, үзенең нишләргә тиешлеген белә иде. Ләкин барысын да бик тиз эшләргә кирәк. Хоскинс артык көтеп тормаячак — бит аның үз баласы зыян күргән...



Юк, ул төнлә, бүген төнлә хәл итәргә тиеш. Ул вакытта «Стасис» хезмәткәрләренең биштән дүрт өлеше йоклаган булачак, башкалары «Урта гасыр» проектының уңышлы тәмамлануы тәэсиреннән искиткеч күтәренкелектә булачаклар.

Мисс Феллоуз яңадан курчак өйгә кергәндә, Тимми әле йокламаган иде, һәм ул, баланы куркытмас өчен, үз-үзен гадәттәгечә тотарга тырышты.

Ул аның төшләре турында сөйләште, Жерри турындагы сорауларын тыңлап торды.

Мисс Феллоуз чемоданын ачты да аннан пальто, колакчынлы йон башлык һәм тагын шундый берничә кием-салым алды.

— Мисс Феллоуз, ник сез миңа бу киемнәрне кидерәсез? — диде бала, борчылып.

— Мин сине моннан алып чыгып китмәкче булам, Тимми. Без син төштә күргән дөньяга чыгачакбыз, — диде мисс Феллоуз.

— Мин төштә күргән дөньяга? — диде малай. Шатлыктан аның бит очлары алсуланып китте, тик шулай да аның куркуы бетеп җитмәгән иде әле.

— Курыкма, син минем белән булырсың. Минем белән бергә булганда син куркырга тиеш түгел, шулай ич, Тимми?

— Әлбәттә, мисс Феллоуз, — диде малай, килбәтсез башы белән мисс Феллоузга сыенды, аны кочаклап алды, һәм туташ үзенең кулы турысында аның кечкенә йөрәген тойды.

Менә төн уртасы җитте. Мисс Феллоуз баланы кулына алды да сигнализацияне ычкындырды һәм иплән кенә ишекне ачты.

Ләкин шул чакны ул искәрмәстән кычкырып җибәрде: бусага янында Хоскинс басып тора иде!

* * *

Хоскинс янында тагын ике кеше бар иде. Хоскинс та, мисс Феллоузны күреп, бик нык гаҗәпкә калды.

Мисс Феллоуз аңа караганда алданрак исен-акылын җыеп өлгерде һәм аның яныннан үтеп китмәкче булды, шулай да Хоскинс аннан да җитезрәк булып чыкты. Тупас кына итеп ул аны тотып алды да кире бүлмәгә этеп җибәрде. Аннары теге ике кешегә керегез дип ым какты һәм, бөтен гәүдәсе белән ишекне каплап, бусага янында туктап калды.

— Мин сездән мондый нәрсә көтмәгән идем. Сез чын-чынлап акылдан шашкансыз.

Хоскинс этеп жибәргәндә мисс Феллоуз ничектер жаны белән борылып өлгергән иде, шуңа күрә ул бүлмәдәге шкафка иңбашы белән барып бәрелде. Тиммигә берни булмый калды.

— Ни булган инде аны үзем белән алып чыксам, доктор Хоскинс? — диде мисс Феллоуз, ялынычлы бер тавыш белән. — Энергияне югалтмау кешене югалтуга караганда артыгракмыни шулкадәр?

Хоскинс бернинди икеләнүсез аның кулыннан Тиммине тартып алды.

— Шулкадәр күп энергия югалту акционерлар җәмгыятендә катнашучыларның бик күп миллион долларларын җилгә очырыр иде. «Стасис» алып бара торган эш котылгысыз рәвештә тукталып калыр иде. Ул чагында маймыл-малайны коткару өчен коточкыч зыян ясаган йомшак күңелле туташ турындагы вакыйга теләсә кемгә билгеле булыр иде.

— **Маймыл-малай!** — дип кычкырды мисс Феллоуз, ярсуына түзә алмыйча.

— Шул вакыйга турында сөйләгәндә аны шулай дип атарлар иде.

Хоскинс белән килгән кешеләрнең берсе ул арада стенаның югаргы өлешендәге тишектән нейлон шнур үткәрә башлады. Мисс Феллоуз шул чакны профессор Адемевскийның ташы сакланган камера стенасындагы шундый ук шнурны — Хоскинс тартып җибәргән теге шнурны исенә төшерде.

— Юк! — диде ул кинәт, кычкырып.

Ләкин Хоскинс Тиммине идәнгә төшерде дә ипләп кенә аның өстеннән пальтосын салдырып алды һәм:

— Син монда кал, Тимми, сиңа берни булмас, — диде. — Без бераз-га гына бүлмәдән чыгып торабыз, ярыймы?

Агарынган һәм кинәт телдән язган Тимминең шулай да баш кагарга көче җитте. Хоскинс мисс Феллоузны кырчак өйдән алып чыкты. Ул-бу була күрмәсен дип, үзе ул аннан арттарак калды. Күпмедер вакытка мисс Феллоуз каршылык күрсәтү сәләтеннән мәхрүм булды. Тонган күзләре белән ул тышкы стенага шнур очы беркетүләрен карап торды.

Мин моны сезгә күрсәтми генә эшләгән булыр идем, мисс Феллоуз, — диде Хоскинс. — Сез соңыннан гына белсен өчен мин аны бүген төнлә эшләмәкче идем.

— Шулай да сез үз балагыз зыян күргән өчен генә шулай кыланасыз. Сезнең ул Җеррыгыз бичара баланы шундый газаплаган — түзәрлеге калмагач, Тимми тоткан да тешләгән.

— Ышаныгыз миңа, хикмәт анда түгел. Бүген монда булган хәлнең төп сәбәбен мин бик яхшы аңлыйм, бөтен нәрсәгә Җерри гаепле икәнлеген дә беләм. Ләкин бу вакыйга инде бөтен дөньяга мәгълүм булды. Аннары, бүгенге көнне, монда шулкадәр күп хәбәрчеләр җыелган бер вакытта, моның башкача булуы да мөмкин түгел. Мин һич тә дуамаллык эшли алмыйм. Безнең игътибарсызлык һәм ниндидер кыргый неандерталь кешеләре турында матбугатта чыккан ялган хәбәрләр аркасында безнең уңышның... «Урта гасыр» проекты тормышка ашырылганнан соң яулап алынган уңышның әһәмиятенә зыян китерә алмыйм. Ничек кенә булмасын, Тимми барыбер юкка чыгарга тиеш, шулай булгач, нигә аны хәзер юкка чыгармаска? Тимми хәзер үк югалса, шаккатыргыч хәбәрләр ясатучы кешеләрнең кайнарлыгы бераз сүрелә төшәр һәм алар тарафыннан безнең өскә ташлана торган пычрак та кимер дип ышанырга кирәк.

— Ләкин бу бит таш кисәген узган гасырларга озату белән бер түгел ләбаса. Сез кешене үтерәчәксез.

— Бу кеше үтерү түгел. Ул берни сизмәячәк, ул бары элеккечә тагын неандерталь малае булып калачак һәм үзенең күнегелгән дөньясына кире кайтачак. Ул чагында инде ул мәңге ябылуга дучар ителгән

килмешәк булмаячак. Аңа ирекле тормышта яшәү мөмкинлеге туачак.

— Нинди мөмкинлек инде ул? Аңа нибарысы җиде яшь, ул үзе турында кайгыртуга, үзен ашатуга-эчертүгә, киендерүгә, карап-саклап торуга күнеккән. Ул анда ялгыз булачак бит, узган дүрт ел эчендә аның туган ыруы баштагы урыныннан күченеп киткән булырга мөмкин. Әгәр алар хәтта анда булсалар да, баланы беркем танымаячак, ул үзе турында үзе кайгыртырга тиеш булачак, ә ул монда үз-үзен кайгыртырга өйрәнә алмады.

Хоскинс, нишләргә дә белмичә, башын селкеп куйды.

— Я алла, сез соң, мисс Феллоуз, безне әллә бер дә ул турыда уйламаганнар дисезме? Соң сез аңламыйсызмыни — үзебез эзләп тапкан иң беренче кеше, дөресрәге, иң беренче кеше сыман җан иясе булган өчен генә без ул баланы борынгы гасырлар эченнән тартып алдык та һәм икенче тәҗрибәнең дә беренчесе кебек үк уңышлы чыгачагына бик үк ышанып җитмәгән өчен генә аны монда тотарга мәҗбүр булдык! Тиммине узган гасырга кире озату кирәклеге безне уңайсыз хәлгә куймаган булса, без соң әллә аны шулкадәр озак тоткан булыр идекме? Безнең тагын да көтеп торырга мөмкинлегебез юк, шуңа күрә дә без аны кире җибәрәбез, — Хоскинсның тавышында тәвәккәл кеше кискенлеге сизелеп китте. — Без хәзер бөек ачышлар алдында торабыз һәм, никадәр кызганыч булмасын, мисс Феллоуз, без Тимминең безгә комачаулавына юл куя алмыйбыз. Булмый. Бик кызганыч, мисс Феллоуз, ләкин булмый.

— Нишлисең инде, алайса, — диде мисс Феллоуз күңелсез генә. — Һич югы миңа аның белән хушлашырга рөхсәт итегез. Миңа бары бишалты минут ирек бирегез, миңа башка берни кирәкми.

— Барыгыз, — диде Хоскинс, бераз икеләнеп торганнан соң.

* * *

Мисс Феллоуз бүлмәгә керү белән, аның каршысына Тимми йөгереп килде. Соңгы мәртәбә ул аның янына йөгереп килде, һәм соңгы мәртәбә туташ аны күкрәгенә кысты.

Күпмедер вакыт ул аны тавыш-тынсыз гына кочып торды, аннары урындыкны аягы белән стенага таба этәрде дә урындыкка утырды.

— Курыкма, Тимми, — диде ул.

— Сез минем янда булганда мин берни дән курыкмыйм, мисс Феллоуз. Теге ишек артында торган кеше миңа бик ачуланамы?

— Юк. Ул бары синең белән мине аңлый алмый... Тимми, әнинең кем икәнлеген беләсеңме син?

Мисс Феллоузның йөзен күрмәкче булып, Тимми башын артка ташлады. Әкрен генә кулын сузып ул аның битен, чәчләрен сыйпый башлады. Кайчандыр бик күптән, Тимминең «Стасис»та яши башлавының беренче көннәрендә мисс Феллоуз аның үзен шулай сыйпаган иде.

— Мин сезнең исемегез мисс Феллоуз икәнлеген бик яхшы беләм, ләкин кайчакта мин сезне үз алдыма «әни» дип атыйм. Алай дип әйтү начар түгелме ул?

— Юк, юк. Мин беркайчан да сине ташламаячакмын, сиңа берни булмаячак. Мин һәрвакыт синең белән бергә булырмын, һәрвакыт синең турыда кайгыртырмын. Миңа «әни» дип әйт, мин ишетерлек итеп әйт.

— Әни! — диде Тимми, куанып, бите белән аның битенә сыенып.

Мисс Феллоуз урыныннан торды һәм, баланы кулыннан ычкындырмыйча, урындыкка менеп басты. Ишек артында кинәт шау-шу купты, кычкырган тавышлар ишетелде. Буш кулы белән мисс Феллоуз стенадагы ике тишек аша сузылган шнурга тотынды һәм бөтен авырлыгы белән бауны аска тартты.

«Стасис» өзелде, бүлмә бушап калды.

# Наҗар Нәҗми

Башкорт шагыйре

## Куркам!..

Мин курыктым. Мин гел курыктым...
Балачакта җеннән курыктым.
Мин курыктым бер чак алладан,
И әнием, синнән курыктым.
Ялган булыр иде сугышта
Курыкмадым дисәм, курыктым.
Мин яшь идем. Дошман алдында
Куркырмын дип, хәтта курыктым.
Көннәр, еллар, юллар арасын
Өйрәттеләр безгә укырга.
Әйе, заман безне өйрәтте
Үз-үзеңнән хәтта куркырга.
Бер карасаң, гомер узган бит,
Мин курыккан күлмәк тузган бит,
Ләкин миндә һаман курку бар,
Канымамы сеңгән куркулар!
Җиде үлчәп һаман бер кисәм,
Дөрес булмас кыю мин, дисәм.
Куркам, әгәр дөнья буталса,
Куркам — кеше юкка ышанса,
Чебеннән фил ясап куйсалар,
Шул «филгә» баш иеп торсалар,
Каптырсалар миңа авызлык —
Куркам;
Авызлыксыз калса явызлык —
Куркам;
Куркам дөньям, балам өчен дә,
Синең өчен, үзем өчен дә,
Язмыш өчен, сезнең өчен дә
Куркам! Куркам!

*1967*

## Татар теле

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да,
Гасырларның афәт җиле.
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле.

Кабатланмас үткәннәрең —
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

*1966*

# Карлар ява...

«Очты дөнья читлегеннән».
Г. Тукай.

Карлар ява, ява карлар...
Көннәрнең иң кыска чагы.
Йоклый гөлләр, тынган сулар,
Сайрар кошлар киткән ары...

Тып-тын гына ява карлар,
Җил исмичә, чыкмый буран.
Аяк өсте йоклый агач,
Шыр ялангач йоклый урман.

Аһ, миндә дә карлар ява,
Ява карлар — еллар кары.
Гомер дигән урманымда
Коела агач яфраклары.

Ачылмыйча калды миндә
Күпме чәчкәм бөреләре.
Уянмады хисләремнең
Тереләрдән тереләре.

Күп елларым — миндә шытмый
Калган алтын бөртек кебек.
Мин дә моңнар оясыннан
Очалмаган бөркет кебек.

Дөньяның тар читлегендә
Очты бары күңелем кошы.
Шундый булып туганмынмы,
Әллә тормыш шулай кушты.

Карлар ява, ява карлар,
Көннәрнең иң кыска чагы.
Бар булганы булган инде,
Ничек булыр булачагы.

*1967*

●

Төн уртасы. Леп-леп сүнә
Тәрәзләр берәм-берәм.
Калдым кебек мин күзгә-күз
Берүзем дөнья белән.

Ә ул һаман да борчулы, —
Тынгысыз әле заман.
Йоклый калам, йоклый балам,
Ә мин утырам һаман.

Килә йокым, ә уйларым
Карый кыйтгалар өстен.
Йоклап китсәм, дөнья белән
Берәр хәл булыр төсле.

**Якуп Колмый**

Башкорт шагыйрэ.

## Каен да мин

Сары тэлгэшлэрен сэлындырып,
Уйга калган ялгыз каеным,
Элеккедэй тартып тормаса да,
Бер күрүдэ үзен таныдым.

Яшь чакта мин чибэр кызны назлап,
Утырмадым каен төбендэ.
Автоматым кысып, туган илне
Яклап йөрдем сугыш көнендэ.

Каен белэн таң аттырдык ул көн,
Томан качты уйсу җирлэрдэн.
Ә ул тэлгэшенэ кочты мине,
Яшергэндэй яман күзлэрдэн.

Артта Мэскэү. Алда дошман тора,
Каен да мин — ике арада.
Дошман йөзен ялмап, ракетам
Сигнал булып янды һавада.

Кинэт давыл купты. Давыл белэн
Кояш чыкты Мэскэү өстендэ.
Килмешэкне җиргэ ябыштырдык
Каен өчен, Мэскэү өчен дэ.

Каен да мин. Безне эзлэп килгэн
Мина җирне уеп ярылды.
Бер ярчыгы минем тэнгэ тиде,
Яралады берсе каенны.

Тэлгэшлэрен калтыратып каен
Башын иде Мэскэү ягына.
Ярасыннан тамган ширбэт суын
Охшаттым мин аккан каныма.

Менэ эле дэ бөгелэ-сыгыла каен,
Яфраклары җилгэ коела.
Сугыш ярасыннан, минем кебек,
Ул да сызлангандай тоела.

Җиллэр иссэ, каен тетрэп китэ,
Суы ага яра эзеннэн.
Уттан сакла мине, дигэн кебек,
Ул Мэскэүгэ карап иелгэн.

## Кем бай?

Сорадылар миннэн:— Әйт син, шагыйрь,
Кем бай без тир түккэн дөньяда!
Бу сорауга җавап бирермен дип,
Килмэде бит минем уйга да.

Күккэ бактым җавап эзлэгэндэй,
Йолдызлардан ява нур безгэ.
Күк эндэште гүя миңа карап:
— Мин бай, шагыйрь, мин бай йолдызга!

Аста диңгез ак яулыгын болгый,
Тоташкан киң, ерак офыкка.
Әйтэ кебек миңа ул ухылдап.
— Суларга бай мин ул, онытма.

Тук башаклар шагыйрьгә баш ия,
Кайда гына аяк басмасын,
Әйтә кебек алар шыбырдашып:
— Бу җирдән дә бай җир тапмассың.

Алларымда яткан Урал тавым
Серен ача җырчы улына:
— Мин бай хәзинәгә, бер дә бетмәс,
Казысыннар гомер буена!

Баш очымда, сөйгән иркәм кебек,
Миңа карап кояш елмайды.
Ул да әйтте гүя: — Мин нурга бай,
Яктыртам мин бөтен җиһанны.

О, юк, дидем, зәңгәр күккә карап,
Минем күңел синнән киңрәк.
Күпме йолдызың бар, барысы да,
Күз алмама сыйган мөлдерәп.

Ярсыма син, тыңла йөрәгемне,
Көчлерәк бит, диңгез, мин синнән.
Урал тавым, ышанасыңмы мине,
Күкрәгемә сыйган хәзинәң.

Җирем, сиңа үзем орлык чәчтем,
Мин бит аңа үзем хуҗамын.
Дым кирәксә — яңгыр булып явам,
Нур кирәксә — кояш буламын.

Сорадылар миннән: — Әйт син, шагыйрь,
Кем бай без тир түккән дөньяда!
— Мәхәббәте булган кеше бай ул,
Өстендә бер күлмәк булса да.

## Елмай әле

Кояш чыкса, чәчәк күзен ача,
Син дә миңа назлы гел генә.
Күңел күгем бер ачылсын, иркәм,
Елмай әле, елмай бер генә.

Тулган айдай кара төнне яктырт,
Яшьлек мәхәббәтен сүндермә.
Керфегеңнән нурлар коеп миңа
Елмай әле, иркәм, бер генә.

Йөрәк кылларымны тибрәтерлек
Җырчы сандугачым син генә.
Күзләремә тутырып кара да син.
Елмай әле тагын бер генә...

———◆———

# Фотула Яннакопулу

Грек шагыйрәсе

*Фотула Яннакопулу грек язучысы. Ул 1955 елда, эзәрлекләүләр аркасында, үз иленнән качып Советлар Союзына килә һәм Грузиянең башкаласы Тбилисида тора башлый.*

*Ул уналты яшьтә чагында үзенең беренче шигырен бастыра. 1958 елда аның «Кече туганым» исемле хикәяләр китабы чыга. Аннан бер-бер артлы «Эллада язы», «Мәхәббәт һәм хыял», шулай ук башка исемдәге шигырь китаплары мәйданга килә.*

*Журналыбызның бу санында без Фотула Яннакопулуның татар халкының батыр улларына багышлап язган ике әсәрен урнаштырабыз.*

## Сандугач һәм бөркет

БАЛЛАДА

Фашистлар төрмәсендә һәлак булган татар шагыйре Муса Җәлилгә багышлана.

Йокы һәм ял белми чишмә ага җырлап,
Сулары саф аның, язгы иртә сымак,
Өсләрендә балкый ачык, зәңгәр һава,
Горур таулар күләгәсен ташлый аңа.
Ул ялтырап ята нурда, ага чыңлап,
Һәм юл биреп ташлар аны тора тыңлап.
Шундый гаҗәп серләр сөйли салкын чишмә,
Узгынчылар үтми аңа иелмичә,
Аның тере суларыннан китми читкә,
Бәллүр дулкыннарга ирен тидермичә.
Әгәр кеше аны эчсә — бәла килмәс,
Авыр йөгә җиңеләер, билен имәс.
Бер чылтырап ага яшәү күк, бер тына,
Охшап татар моңы, татар җырларына.

Чишмә...
        Бәлки фәкать чишмә кебектер ул,
Бәлки теге гаҗәп бөркет-егеттер ул,
Биеклеккә очып, канат кагып шуннан
Көнчыгыш һәм Көнбатышны тоташтырган.
Бәлки ул кар күк саф Муса хыялыдыр,
Төштәгедәй аның өмет-уйларыдыр.
Төштәгедәй.
                Ләкин син бит йокламыйсың.
Яз кебек яшь һәм якты көн нурлары син.
Юмарт һәм бай кырларга бал кортлары
Җыялар бал синең чәчкә-җырларыңнан.
Син Казанда кабыздың ал таң утларын,
Синең йөздә чагыла бөтен Татарстан.

— Нигә, — ди сандугач,— урыныңнан тормыйсың,
Нигә юлыңны тау, үрләргә бормыйсың,
Ник бармыйсың атлап яшел иминлектән?
Син утырткан идең аны үзең күптән.
Күтәрел дә Урал тауларына таян,
Безне шатландырып, балкып кара аннан.
Яшәргә иң хаклы батыр егет идең,
Кем җырыңны дәвам итәр икән синең?!
— Син бик хуплап әйттең, гүзәл
сандугачым.
Мине кабат син хәятка кайтармакчы.
Җир улы мин, җиргә салдым газиз башны,
Һәм ул мине җибәрмәскә кочак ачты.
Тылсымлады ул куенында,
күкрәгемә
Үсеп чыкты мәңге яшәр яшел үлән,
Ә җырларым — дәвам итәр, кошкай, беләм,
Киләчәккә барыр яңа көннәр белән.
Элек мин дә күрә идем биеклектән,
Үбә идем чишмәдәге саф суларны.
Сез җырлагыз, тауга, кыяларга, күккә —
Болытларга ашырыгыз ул җырларны.

## Син дустыбыз безнең, туганыбыз

Газап чигүче халкым бәхете өчен Эллада тауларында 1949 елда татар халкының батыр улы Марат Саидов һәлак булды. Бу җырымны мин аңа багышлыйм.

Марат! Син түбәсе күккә ашкан
Татар каены идең,
сөйкемле,
Җитди иде йөзең, матур идең,
Ачык идең кояш шикелле.

Туганлык һәм дуслык чәчәкләре
Язлар килгән саен балкырлар,
Бар агачлар яшел яфрак ярыр,
Элеккечә җырлар яңгырар.

Илеңнән син давылларда киттең,
Үлем сине екты көнләшеп.
Тик калдың син истә якты көндәй,
Туганкаем, дустым, иптәшем

Синдә булган ышаныч нуры белән
Тулсын минем моңлы күзләрем.
Хәзер башка давыл җир өстендә,
Безнең тавыш, безнең сүзләрнең

Күгәрчене канат җәя күктә.
Илем күкрәгендә яралар... —
Таш һәйкәлләр кебек тынлык саклап,
Яшь түгәләр барлык аналар.

Тик таң килер тиздән җылы бирел
Аналарның изге багыренә.
Шунда бөек җиңү чәчәкләре
Келәм булыр синең кабереңә.

Татар дустым, җиңелмичә үлдең,
Башың салдың минем җиремә...
Ләкин синең изге хыялларың
Илләр гизә кәрәш җилендә.

Караңгыда балкып киләсең син,
Оясыннан синең өстеңә
Ук яудыра дошман шашып, каушап,
Син атлыйсың һаман,
Аяк тавышларың ишетелә.

Элладаның халкы богауларда,
Тик кол түгел — азат, канатлы!
Янгыннардан алып килә үзенә
Яңа таңны, яңа хәятны.

Кара төнне кусын хаклык нуры,
Тимер койма җирне бүлмәсен,
Сүзлекләрдән сызсын килер буын
Сугыш сүзен;
сугыш булмасын!

Нури АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

**В. Скворцов**

КДУ аспиранты

# КЫРЫС МАРКСИСТ



**Шәһәребездә аны һәркем яхшы белә: Казан урамнарының берсе Федосеев исеме белән йөртелә.**

**Николай Евграфович Федосеев марксизм тәгълиматын пропагандалау һәм фәнни социализм идеяләрен үстерү эшенә зур өлеш керткән күренекле марксист иде. В. И. Ленин аны искиткеч талантлы һәм үз эшенә искиткеч бирелгән революционер, дип атады [1]. Ихтимал, аның каршында беркайчан да кем белән барырга дигән сорау тормагандыр. Дворян гаиләсендә туып үскән Федосеев 17 яшьтән үк революция юлына баса, үзенең бөтен көчен царизмга каршы көрәш эшенә багышлый. Мохтаҗлык, хәерчелек күрә, әнисе каргышына тап була, ялгыз камераларда җәфа чигә, сөргеннәр газабын татый, әмма, башка революционерлар кебек үк, үзе сайлаган юлдан бер генә адым да чигенми.**

**Совет тарих фәнендә Николай Евграфович Федосеев тормышының Казан, Владимир чорлары чагыштырмача тулы өйрәнелгән. Ә менә Себердә һәм Сольвычегодскида узган еллары хакында алай әйтеп булмый. Архангельск, Вологда архивларында табылган яңа материаллар нигезендә язылган бу мәкалә күренекле революционер тормышының Сольвычегодск чорына багышлана.**

**Салкын яңгырлы көз. 1893 елның 24 ноябре. Федосеев Владимир шәһәреннән Вологдага озатыла. Аннан инде, кораллы сак астында, ерак Сольвычегодскига, өч еллык сөргенгә җибәрелә [2]. Шулай мәшәкатьле һәм тынгысыз авыр көннәр, сөргенлек көннәре башлана.**

**Әмма чын революционерлар төрмәләр һәм сөргеннәрдә дә төшенкелеккә бирелмәделәр. Кыен шартларда да яшәп килүче стройга каршы актив көрәш алып бардылар, революциягә, азатлык эшенә булыштылар. Н. Е. Федосеев шундый марксистларның күренеклесе иде.**

**Сольвычегодскида ул киеренке иҗат эше белән шөгыльләнә: күп укый, Казанда ук башлаган фәнни хезмәтләрен төгәлли [3]. Аның либераль рус народникларының «патриархы» Н. К. Михайловскийга каршы язылган полемик хатлары да нәкъ шул чорларга туры килә. Ул Михайловскийга каршы барысы ике хат яза. һәм аларда, рус марксистларыннан беренче буларак, либераль народниклар алга сөргән линияне кискен тәнкыйть итеп, революцион марксизм тәгълиматының төп положениеләрен һәм социализмны яклап чыга. Марксизм көн тәртибенә куйган бурычларны тормышка ашыру өчен, ди Федосеев, түбәндәге шартлар үтәлергә тиеш: революциядә проле-**

---

[1] В. И. Ленин. Полное собрание сочинений. Рус телендә. 45 том. 324—325 битләр.
[2] Вологда өлкәсенең дәүләт архивы. 18 фонд. 2926 саклану берәмлеге. 42 бит.
[3] Вологда өлкәсенең дәүләт архивы. 108 фонд. 214 саклану берәмлеге. 335 бит. (Җандармерия документларында Федосеевның сөргендәге тормышы турында шундый сүзләр бар: «Бүлмәдә утырып эшләргә ярата, үзен тыйнак тота...»).

тариатның гегемонлыгы; крестьяннар массасына пролетариат җитәкчелеге; сыйныфларны бетерү һәм социалистик эре промышленностьны үстерү нигезендә сыйныфсыз җәмгыять төзү.

Федосеев тарафыннан көн тәртибенә куелган бу бурычлар шул заман өчен гаять актуаль, мөһим идеяләр. Безгә алар Николай Евграфовичның тирән һәм искиткеч тирән белемле марксист булуы турында сөйлиләр.

Сольвычегодскига килеп төшү белән, Федосеев җирле яшьләрдән һәм бирегә сөрелгән революционерлардан яшерен түгәрәк оештыру эшенә алына [1]. Ул төзегән түгәрәккә И. Козин, ирле-хатынлы Шлихтерлар, П. Морозов, В. Лилиенштерн, А. Голодникова, Н. Сигорский, С. Суворов кебек революционерлар йөргән. Соңыннан, Петербург, Мәскәү, Казан һәм башка шәһәрләрдән сөргенгә җибәрелгән кешеләр хисабына, түгәрәк тагын да зурая, тулылана.

Федосеев түгәрәгенә йөрүчеләрнең тормыш-язмышлары, биографияләре дә шактый кызыклы. Алар арасында марксизм тәгълиматын әйбәт үзләштергән, революцион көрәш юлында бай тәҗрибә туплаган кешеләр дә була. П. Морозов, мәсәлән, М. И. Брусневның Петербург оешмасы белән даими элемтәдә яшәгән эшче түгәрәкләренең бер вәкиле. 1891 елда ул демократ язучы Н. В. Шелгуновны күмү уңае белән оештырылган демонстрациядә катнаша, 1893 елдан 1894 елга кадәр Петербург түгәрәкләрендә В. И. Ленин һәм Г. М. Кржижановскийлар белән бергә эшли. 1896 елның язында ул Сольвычегодскига сөрелә һәм Федосеев оештырган түгәрәк утырышларына йөри башлый. П. Морозов вафат булгач, ленинчыл «Искра» газетасы аның хакында: «Мәрхүм безнең хәрәкәтнең иң яхшы агитаторларыннан исәпләнә иде», — дип язып чыкты [2].

Түгәрәк члennарының тагын берсе — Иван Козин Маркс, Энгельс әсәрләрен оригиналда укый алырлык зур белемле, киң карашлы эшче була. Ул Ростов-Дондагы марксистик түгәрәкләрдә эшләп тәҗрибә алган, шундагы түгәрәкләрнең җитәкчесе, Казан ветеринария институтының элекке студенты Н. А. Мотовилов белән якыннан таныш кеше. Мотовиловны исә үз чиратында Николай Евграфович та әйбәт белгән.

1894 елда Иван Козин Ростов-Дон тимер юлчыларының зур стачкасына җитәкчелек итә һәм, шуның өчен кулга алынып, Сольвычегодскига сөрелә. Биредә ул Федосеев белән очраша, ул оештырган түгәрәк утырышларына йөри башлый.

Федосеевның һәм сөргендәге башка революционерларның хатлары, нинди юллар белән, еш кына жандармнар кулына да эләккәләп торган. Бүгенге көндә архивларда сакланып калган шул хатлардан күренгәнчә, түгәрәк члennары гаять кыю һәм эчтәлекле тормыш белән яшәгәннәр. Алар Россиядәге эшчеләр хәрәкәте белән даими һәм эзлекле бәйләнеш тотканнар, политик мәсьәләләр буенча чыккан яңа хезмәтләрне, брошюра һәм рефератларны үз вакытында ала барганнар. Түгәрәк члennары карамагында хәтта яшерен китапханә дә булган. Ул китапханә фондының төп өлешен Федосеев исеменә килгән политик китаплар тәшкил иткән.

Түгәрәк, аның члennарының эшчәнлеге белән полиция дә кызыксына башлый. 1895 елның 25 июлендә Федосеев квартирында тенту ясала. Шуннан озак та үтми, аны кулга алалар һәм, ныклап тикшерү өчен, Владимир шәһәренә озаталар. 1896 елның март башларына кадәр ул төрле төрмәләрдә утыра, еш кына бер урыннан икенче урынга күчерелеп йөртелә. Әмма шундый кыен шартларда да революцион эшчәнлеген туктатмый.

1896 елның 8 һәм 21 августларында Архангельск сөргенендәге кәләше М. Гопфенгаузга язган хатларыннан Николай Евграфовичның Мәскәү, Владимир, Нижний Новгород шәһәрләрендәге марксистик түгәрәкләрнең эшчәнлеге белән дә таныш булуы [3] аңлашыла. Сольвычегодск түгәрәге члennары, М. Гопфенгауз аша, Архангельск сөргенендәге революционерлар белән хатлар язышып, яшерен матбугат әсәрләре алмашып торганнар икән. Бу чорда исә Архангельск сөргенендә марксистик Казан

[1] Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, Федосеевның Михайловскийга каршы язган хатларын да, аның тарафыннан төзелгән марксистик түгәрәкне дә В. И. Ленин әйбәт белгән.

[2] «Искра» газетасы. 1901 ел. 4 сан.

[3] Н. Е. Федосеев. Статьи и письма. Рус телендә. Мәскәү. 1958 ел. 246 бит.

түгәрәгенең элекке членнары М. Григорьев, А. Санин, А. Петров һәм шулай ук мәшһүр революционер, В. И. Ленинның көрәштәше һәм якын дусты А. П. Скляренко-Попов була [1].

Яңа хөкем карары чыгаруларын көтеп, бер урыннан икенче урынга күчереп йөртелгән көннәрдә дә Федосеев Сольвычегодскидагы иптәшләре белән язышып, хәбәрләшеп тора. Ләкин аның Н. Сигорскийга адресланган хаты 1895 елның 31 декабрендә полициягә эләгә, тагын күпмедер вакыт үткәч, жандармнар түгәрәк членнарының Федосеевка язган хатларын да кулга төшерәләр. Нәтиҗәдә, жандармерия идарәсе өчен Федосеевның революцион хәрәкәттәге роле дә шактый ук ачыклана төшә [2].

1896 елның март башларында ул яңадан Владимирдан Сольвычегодскига әйләнеп кайта. Бу юлы инде Федосеев өстеннән каты күзәтү оештырыла, аны беркая да чыгармыйлар. Әмма ул бирешми. Дәртләнеп, революцион эшчәнлеген дәвам итә. Ул кайткач, түгәрәк эше тагын җанланып китә. Чираттагы утырышларның берсен «Безнең хуҗалык үсешен бәяләүгә карата материаллар» исемле җыентык буенча фикер алышуга багышлыйлар. Анда исә В. И. Ленин, Г. В. Плеханов, П. Н. Скворцов мәкаләләре дә урнаштырылган була. В. И. Ленин мәкаләсенә югары бәя биреп, Н. Е. Федосеев: «Иптәшләрнең фикеренә карагандa, ул бөтен җыентыктагы иң яхшы мәкалә», дип язды [3].

1896 елның 27 маенда түгәрәк членнары ирле-хатынлы Шлихтерларны Уфага озаталар. Алар китеп күп тә үтми, «Самарский вестник» газетасының туксан җиденче елгы бер санында Н. Е. Федосеевның «Тарихи бөлешмә...» исемле мәкаләсе басылып чыга. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, Николай Евграфович легаль юл белән редакциягә мәкалә җибәрә алмаган. Безнең уебызча, аның ул мәкаләсен Самарага Шлихтерлар алып кайткан булырга тиеш.

Федосеев, ашкынып, сөргенлек вакыты тулганны көтә. Тик юкка гына. 1895 елның 15 июлендә кузгатылган «Владимир эше» кабат карала. Шул эш буенча аны яңадан кулга алалар һәм Владимир шәһәренә озаталар [4]. 1896 елның 28 октябрендә Н. Е. Федосеевка яңа хөкем карары җиткерелә: ул биш елга Себергә сөрелергә тиеш. Аны авыр, мәшәкатьле, озын юл көтә. Һәм ул 21 ноябрьдә, этап белән, шул авыр сәфәргә кузгала...

◇◆◇

[1] Архангельск өлкәсенең дәүләт архивы. I фонд. 4 тасвирлама. 166 саклану берәмлеге.

[2] Вологда өлкәсенең дәүләт архивы. 108 фонд. 226 саклану берәмлеге. 246 бит.

[3] Н. Е. Федосеев. Статьи и письма. 253.

[4] Федосеев сөргеннән эчке эшләр министрына ике гариза язып җибәргән була. Беренчесендә үзен М. Гопфенгауз янына — Архангельскига күчерүләрен үтенә. «Синең белән Европаның төньягында очрашу насыйп булмас, ахры», ди ул яңа хөкем карары алгач М. Гопфенгаузга язган хатларында. Сәламәтлеге какшый башлагач язган икенче гаризасында үзен Полтавага кайтаруларын сораган була.

**Рөстәм Надиев**

# АРХИТЕКТОР



Революциягә кадәр Россиядә архитекторлык иҗаты бары югары катлау кешеләре генә булдыра ала торган хезмәт булып саналган, ә түбән катлау, бигрәк тә азчылык милләт кешеләре бу эшкә кулай саналмаган. Шуңа күрә Октябрьга кадәр безнең татарлар арасыннан бер генә архитекторыбыз да булмавы һич тә гаҗәп түгел. Хәтта халык арасыннан чыккан талантлы кешеләр дә бу гаҗәеп күпкырлы, мавыктыргыч һәм гүзәл профессиягә юл таба алмаганнар. Әмма бу безнең тарихта татар халкы арасында, талантлы һәм оста куллы төзүчеләр булмаган дигән сүз түгел. Идел буенда урнашкан борынгы Болгар, Биләр шәһәренең гүзәл корылышлары, Казанда һәм башка шәһәрләрдә, авылларда салынган бик күп биналарның үзенчәлекле милли архитектура үрнәкләре халкыбызның борынгы заманда ук биналар салу сәнгатенә зур сәләте турында сөйлиләр.

Ләкин бары тик Бөек Октябрь революциясе җиңеп, Совет власте урнашкач кына, милли белгечләр, шул исәптән архитекторлар, әзерләп чыгарырга мөмкинлек ачылды.

Хәзер без халыкның арасыннан күтәрелгән архитекторларыбызның бөтен бер плеядасы булуы белән горурланабыз. Биналар салу сәнгате осталары Исмәгыйль Гайнетдинов, Әхмәт Бикчәнтәев, Мәхмүт Игъламов, Рәшат Мортазин һәм башка архитекторларның проектлары буенча Совет власте елларында бик күп гүзәл биналар калкып чыкты.

Татар халкы тарихында беренче архитектура профессоры Исмәгыйль Гайнетдиновның тормышы һәм иҗаты тоташ эзләнүләрдән гыйбарәт: ул архитектурада гүзәллеккә һәм камиллеккә ирешү юлларын эзләи. Аның иҗаты безнең заман архитектурасының үсеш тарихында якты бер сәхифә булып тора.

Ул 1908 елда Татарстанның Арча районы, Олы Мәңгәр авылында ярлы һәм укымышсыз крестьян семьясында туа. Аларның семьялары мохтаҗлыкта интегә. Әтисе Гали абзый, рус-япон сугышы инвалиды, еш кына Казанга яки башка шәһәрләргә акча эшләргә йөри. Ләкин читкә йөрү өйгә бәхет китерми. Мохтаҗлыкның чигенә җиткәч, 1911 елда, бөтен семья, барлыюклы әйберләрен төяп, күч-хәл белән Чиләбегә барып җитә. Ләкин Мәңгәр кешеләрен анда да фәкыйрь тормыш көтә. Гали абзый кара эшче, йөк ташучы, ишек алды җыештыручы булып, кыскасы, бөтен авыр эшләрдә эшли. Исмәгыйльнең әнкәсе Маймүнә апа да байларга пешекче булып яллана.

Авыл тынлыгыннан соң шау-шулы зур шәһәргә килеп төшү кечкенә Исмәгыйльгә әкият дөньясына керү белән бер була. Монда күне буе өйгә кайтмыйча урамда йөрергә, зур биналарга, матур кибет витриналарына карап сокланырга мөмкин. Ләкин мондый бәхет Исмәгыйльгә сирәк килә. Алты-җиде яшеннән ук ул я әтисенә, я әнисенә булыша башлый, аларның төрле



вак йомышларына йөгерә. Ә бушаган араларда урамга малайлар янына чыга һәм кызыклы «шәһәр» уеннары уйный. «Сызыкташ» уйнаганда аның кебек тротуарга тигез һәм төгәл итеп квадратлар сызучы булмый. Кеше сурәте ясаса да бик килешле чыга. Кичләрен ул тонык керосин лампасы яктысында сәгатьләр буе рәсем ясап утыра. Урамда гармонь уйнап җибәрсәләр, тизрәк музыка тыңларга чыгып йөгерә...

Гали абзый белән Маймунә апа Исмәгыйльне башка күрше балалары белән мәктәпкә йөртергә тырышалар. Ләкин фәкыйрьлек бик озак вакытлар бу изге теләкне тормышка ашырырга мөмкинлек бирми. Тик 1917 елда, тугыз яшендә чакта гына, Исмәгыйль башлангыч татар мәктәбе бусагасын атлый. Биредә ул дүрт ел гына укып кала. Авыр тормыш шартлары, даими мохтаҗлык аркасында укуын ташларга мәҗбүр була. Шуның өстенә 1921 елгы ачлык семьяны аяктан ега. Үнөч яшьлек Исмәгыйль итекче һөнәренә өйрәнеп, икмәклек акча эшләргә тырыша. Укуын да онытып бетерми. Кичләрен китаплар укый, дәреслекләр актара...

1927 елның көзе. Казанга Свердловскидан килгән поезддан уң кулына кечкенә агач сандык тоткан киң җилкәле, карасу йөзле, үткер күзле бер егет төшә. Ул бик ярлы киенгән, аякларындагы итекләре генә яңа: аларын ул үзе тегеп кигән. Бу — Исмәгыйль, Казанга ул ничек кенә булса да укуын дәвам иттерергә дип кайткан.

Авыр студентлык еллары башланды. Башта рабфак, аннан төзүче инженерлар институты...

Исмәгыйль бөтен көчен куеп, тырышып укыды, уку белән бергә әдәбият, музыка һәм сынлы сәнгать белән мавыкты. Шактый матур шигырьләр язды, Гадел Кутуй җитәкчелек иткән әдәбият түгәрәгенә йөрде. Тиздән булачак архитектор белән ул чакта инде танылып өлгергән шагыйрь арасында чын дуслык башланып китте. Гадел Кутуй Исмәгыйльне Һади Такташ, Демьян Фәтхи һәм башка шагыйрьләр белән таныштырды. Күренекле әдәбият осталары белән аралашу Исмәгыйльне рухи яктан нык кына баетты. Студентлык елларында ул дәртләнеп рәсем ясау белән шөгыльләнде. Аның төрле темаларга ясалган рәсемнәрен, иллюстрацияләрен еш кына «Кызыл яшьләр», «Кызыл Татарстан» газеталарында, журналларда күрергә мөмкин иде. Исмәгыйль Гайнетдиновның шулай ук институтта укыган чорда башкарган проект эшләре дә графика һәм художество сыйфатлары ягыннан аерылып торалар. Шуңа күрә бу әсәрләр озак еллар буена студентлар өчен күргәзмә әсбап булып хезмәт иттеләр, архитектура кабинеты стеналарын, күргәзмә залларын бизәп тордылар.

Шулай итеп, кичәге итекче малай беренче бишьеллыклар чорында кабынып киткән зур тормыш ялкынына чумды.

Һәм, ниһаять, менә аның тормышында күренекле урын алган 1931 ел. Бу елның гыйнварында Исмәгыйль Гайнетдинов, Казан коммуналь төзелеш институтын тәмамлап, төзүче-инженер дигән диплом алды. Шул көннән аның төзелеш өлкәсендәге актив эшчәнлеге башланып китте. Берничә ел буена ул Казанның күп кенә төзелешләрендә башта прораб ярдәмчесе булып, аннан Ленин районындагы социалистик шәһәрчектә күп катлы йортлар төзүдә прораб булып эшләде. Бер үк вакытта яшь инженер, күптән түгел үзе тәмамлаган институтның архитектура факультетында ассистент буларак, педагоглык эшчәнлеген дә башлап җибәрде.

Бу юлларның авторына студент чакта нәкъ әнә Исмәгыйль ага Гайнетдинов җитәкләгән группада укырга туры килде. Һәрвакыт җитди һәм гаҗәеп ягымлы остазыбызның аудиториягә килеп керүләре, сәгатьләр буена түземлек белән сызым такталары янында безнең беркатлы, ләкин тырышып эшләгән проектларны тикшерүләре әле дә хәтердә. Шул чакта ук ул безгә болай дип сөйләгән иде:

— Моннан ике мең еллар элек Римда, император Август хөкем сөргән заманда, Марк Поллион Витрувий дигән архитектор яшәгән. Ул үз заманы өчен гади булып саналган җәмәгать биналары салдырган. Үзе туплаган тәҗрибәне башка архитекторлар, үзенең шәкертләре белән уртак-

лашу өчен ул «Архитектура турында ун китап» дигән гыйльми әсәр язган. Бу трактат безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Рим архитекторын иң беренче чиратта: «Архитектураның төп нигезе нәрсәдә, ул нинди таләпләрне канәгатьләндерергә тиеш», — дигән мәсьәлә борчыган. «Архитектура корылмасы өчен зарур булган бары өч сыйфат бар, — дип җавап биргән ул моңа. — Алар — файдалы булу, ныклык һәм матурлык».

Бу өч төшенчә хәзерге заман архитектурасы өчен дә тулысы белән үз гамәлендә кала. Исмәгыйль ага «файда» дигән төшенчә астында, бүгенге көн терминологиясен кулланып әйткәндә, архитектураның функциональ ягын, ягъни бинаның кешеләргә нинди уңайлыклар тудыруын күздә тотарга кирәк, дип аңлата иде. «Ныклык» — ул бинаның инженерлык-конструкторлык яктан эшләнеше. Ул корылманың озак елларга чыдамлыгын, ныклыгын тәэмин итәргә тиеш. «Матурлык» исә — ул корылманың сәнгатьчә эшләнеше, бинаның эстетик сыйфатлары. «Теләсә кайсы объектны проектлаштырганда менә шушы өч төп принципны кулланып эш итәргә кирәк», — дип өйрәтә иде безне Исмәгыйль Галиевич. Без, студентлар, үзебезнең яшь остазыбызны гадилеге, туры сүзлелеге һәм таләпчәнлеге өчен ярата идек.

1934 елда төзүче инженер буларак шактый зур практик тәҗрибә туплаган Исмәгыйль Гайнетдинов Казан шәһәр Советы башкарма комитетының проект мастерскоенда местәкыйль автор-архитектор булып эшли башлады. Өч ел дәвамында ул байтак кына мөһим проектлар иҗат итте. Шушы проектлар буенча Карл Маркс урамында С. М. Киров исемендәге Казан химия-технология институты бинасы, Жданов урамында мәктәп, Тукай урамында мехчыларның культура сарае, шәһәрнең төрле районнарында берничә күп катлы йорт салынды. Дөресен әйтергә кирәк, аларның күбесе әле камил түгел, авторның үзе әйтмешли, «капшанып», интуиция ярдәмендә генә башкарылган биналар иде. Аларда архитектура өлкәсендә профессиональ белем җитеп бетмәгәнлеге сизелә иде. Шуңа күрә Исмәгыйль ага, проект мастерскоенда эшләгән һәм институтта педагогик эшен алып барган хәлдә, архитектура теориясен өйрәнүгә, халык архитектурасы буенча материаллар җыйнауга, аларны тикшерүгә дә күп көч һәм вакыт багышлап, иң яхшы, алдынгы милли традицияләрне үзенең проектларында чагылдырырга тырышты. Жданов урамындагы мәктәп проекты һәм мехчылар культура сараеи бизәү — әнә шундый уңышлы тәҗрибәләрнең берсе булды. Исмәгыйль Гайнетдинов ул вакытта ук үз проектлары өчен халык алдында гаять зур җаваплылык сизә иде. Менә бер мисал.

1935—1936 елларда мин мехчылар культура сарае төзелешендә прораб булып эшләдем. Тамаша залында һәм фойеда эчке бизәү эшләре бара иде. Барлык бизәк эшләре, югарыда әйтелгәнчә, Исмәгыйль ага эскизлары буенча башкарылды. Көннәрнең берсендә төзелешкә проект авторы үзе килде. Ул дикъкать белән бөтен төзелешне карап чыкты, аннан мастерскойга керде. Анда бизәү эшләре остасы Григорий Бубнов, үзенең уллары Володя һәм Коля белән бергә, фойеның булачак купертмә бизәкләре өлгесен әзерләп ята иде. Исмәгыйль ага әзер өлгеләрне бик җентекләп карап чыкты да кашларын җыерды.

— Нәрсә тоҗырдыгыз сез монда, дуслар?.. Бизәкне үзгәртергә кем рөхсәт бирде сезгә? — диде ул, кырт кистереп.— Сызымда ничек күрсәтелгән булса, шулай эшләгез!

— Исмәгыйль Галиевич, аерма бөтенләй юк диярлек бит. Сезнекеннән чак кына үзгә, аннан әллә ни булмас, — дип, мин дә, бизәк остасы да аны үгетләргә тырышып карадык. — Шуның өстенә сроклар да кыса, объект Октябрьның 18 еллыгына әзер булырга тиеш...

Архитектор кашларын тагын да җыера төште, күзендә ачулы очкыннар чагылып китте.

— Ишетәсем дә килми. Мин таләп иткәнчә эшләми торып, бер генә детальне дә куярга рөхсәт итмәячәкмен, — диде ул һәм төзелештән китеп барды.

— Менә сиңа архитектор... Мондыйны күргәнем юк иде әле, — дип мыгырданды карт оста һәм сораулы караш белән миңа текәлде:

— Я, нишлибез соң?

— Берни эшләр хәл юк, дядя Гриша, архитектор хаклы, гаеп бездә. Өлгеләрне үзгәртеп эшләргә туры килер. Мин аны институттан ук беләм, брак эшкә юл куймаячак, — дип әйтергә мәҗбүр булдым.

Берничә көннән Исмәгыйль ага төзелешкә тагын килде һәм туп-туры бизәкчеләр янына юнәлде.

— Я, эшләр ничек? — диде ул, дусларча елмая төшеп.

— Бары да тәртиптә, — диде Гриша агай, бераз уңайсызланып, һәм яңа өлгеләрне күрсәтә башлады.

— Минә монысы әйбәт! Хәзер бизәкләр бөтенләй икенче булачак. Сез минә гафу итегез, Григорий Иванович... Игътибарсыз эшләнгән эшне яратмыйм.

— Юк ла, Исмәгыйль Галиевич, киресенчә, рәхмәт сезгә, яхшы сабак бирдегез...

Шул вакыттан архитектор белән безнең арада тыгыз контакт һәм бердәмлек башланып китте...

Исмәгыйль Гайнетдиновның беренче архитектура әсәрләре киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде.

Мәсәлән, 1936 нчы елда СССР архитекторлары союзы органы булган «Архитектурная газета» болай дип язган иде:

«Совет Татарстаны башкаласында архитекторлар оешмасы утыздан артык мастерны берләштерә. Алар арасында комсомолец Исмәгыйль Гайнетдинов алдынгы урыннарның берсен алып тора. Аның проектлары буенча Казанда ун объект: мәктәпләр, җәмәгать биналары салынды. Ул конкурсларда берничә тапкыр бүләкләр алды.

...Комсомолец-архитектор Гайнетдиновның исеме Совет Татарстанында популяр булып китте. Исмәгыйль Гайнетдиновның тырыш иҗади хезмәте, туктаусыз практик эшчәнлеге орденлы республикада яңа, матур тормыш төзүче татар халкының нинди зур энергия һәм көчле ихтыяр белән культура биеклекләрен, белем, фән һәм сәнгать крепостьларын яулавын ачык чагылдыра».

Үзәк матбугат һәм илнең күренекле архитекторлары тарафыннан үз иҗатына югары бәя бирелү Гайнетдиновның башын әйләндермәде. Архитектура буенча махсус белемгә омтылышы тагы да көчәя төште.

Һәм менә 1936 елда Гайнетдинов, илебез башкаласы Мәскәүгә барып, СССР архитектура академиясе аспирантурасына гариза бирде.

Бик авыр имтихан иде бу. Бер урынны тугыз кеше дәгъвалый иде. Ләкин Исмәгыйль Гайнетдинов белеме һәм тәҗрибәсе белән үзенең күп конкурентларын узып китте һәм аспирантурага алынды. СССР архитектура академиясе тарихында беренче тапкыр аның сафларына татар халкы вәкиле кабул ителде.

Бу Гайнетдиновның шәхси уңышы гына түгел, ә бәлки үсеп килүче милли архитектор кадрларының гомуми уртак уңышы иде.

Аспирантурада укыган чакта Исмәгыйль Гайнетдинов, бөтен көчен һәм тырышлыгын биреп, узган заман мирасын, рус архитекторлары Казаков, Баженов, Захаров, Воронихин һәм башка бик күпләрнең иҗатын һәм архитектура истәлекләрен, бүгенге техника яңалыкларын өйрәнде, академиклардан Щусев, Желтовский, Лансере, Семенов һәм башка күренекле совет архитекторлары җитәкчелегендә эшләде.

Өч ел вакыт узды. 1939 елда ул аспирантура программасын уңышлы тәгаллап, «Торак йорт архитектурасында керамик материаллар» дигән темага диссертация яклады һәм күп катлы торак йортның конкрет проектларын иҗат итәргә керешге.

Ниһаять, аның күптәнге хыялы тормышка ашты. Хәзер Исмәгыйль Гайнетдинов югары квалификацияле архитектор гына түгел, татарлар арасыннан беренче архитектура фәннәре кандидаты да. Аспирантураны тәмамлагач, СССР архитектура академиясе президиумы карары буенча ул академиянең шәһәрләр коруны проектлаштыру институтында фәнни эшкә калдырылды. 1965 елның октябрендә СССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгының югары



*Бөтенсоюз халык хуҗалыгы күргәзмәсендә ТАССР павильоны.*



*Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы.*

аттестацион комиссиясе карары белән аңа профессор исеме бирелде.

Фәнни һәм педагогик эшкә күмелгән булуына карамастан, Исмәгыйл Гайнетдинов үзенең практик иҗат эшен һәм туган Татарстаны белән элемтәсен бер генә минутка да өзми.

1937 елда, аспирант вакытында ук, ул Бөтенсоюз Авыл хуҗалыгы күргәзмәсендәге Татарстан павильоны проектын эшләде.

Күргәзмәдә булган һәр кеше бу павильонны яхшы хәтерлидер.

Фасад ягындагы челтәрле арканы узкәч, ике фонтан бәреп торган җыйнак ишек алдына керәсең. Ул төп порталга алып килә. Төсле майолика белән бизәлгән портал башына Ленин ордены төшерелгән. Шулай ук ян-як ишекләргә дә матур төстәге майолика белән милли орнаментлар ясалган. Ян-якларда яшеллек белән үрелгән беседкалар бинаны тирә-юньдәге бакча белән тоташтыра. Биредә һәр нәрсә милли колорит белән сугарылган.

«СССР архитектурасы» журналы бу павильон турында менә нәрсә язган иде:

«Зур осталык белән башкарылуы, идея һәм форма эчтәлегенең ачыклыгы һәм бердәмлеге бу павильонны күргәзмәдәге иң яхшы биналар рәтенә куя. Татарстан павильоны авторы башкаларга караганда шактый бәхетлерәк. Аның композициясен төзүгә татар архитектурасының, башлыча, торак архитектурасының сокландыргыч һәйкәлләре илһам биргән. Павильон өстендә эшләгәндә иң мөһим нәрсәләрне билгеләүдә, нечкә зәвык белән бергә, хәзерге заман биналарын коруда кирәк булган иҗади мөстәкыйльлек тә ачык чагылган».

Шуңа күрә дә Бөек Ватан сугышыннан соң күргәзмәгә реконструкция ясалганда, Татарстан павильонының архитектура эшләнеше зур кыйммәткә ия булуын күздә тотып, аны шул килеш калдырырга карар бирелде. Бу гүзәл эше өчен бинаның архитектура авторы Исмәгыйл Гайнетдинов күргәзмәнең Баш Комитеты тарафыннан «1955 елда Бөтенсоюз Авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашучы» дигән таныклык һәм медаль белән бүләкләнде.


Исмәгыйл Гайнетдиновның күренекле архитектура әсәрләре арасында Казанда Ирек мәйданында салынган Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы аеруча зур урын алып тора. Чын халык традицияләрен һәм формаларын кулланып, зур осталык белән башкарылган бу гүзәл монументаль корылма архитекторның чираттагы иҗади казанышы булды. Алгы портик фронтонының скульптура композициясе, скульпторлар Н. К. Венцель һәм Л. И. Шулик белән берлектә эшләнгән А. С. Пушкин һәм Г. Тукай һәйкәлләре, театрның көньяк мәйданчыгындагы фонтан һәм, ниһаять, колонна капительлә-

ре һәм барельефларның нәфис, тасвирлы бизәкләре бинага мәһабәт төс биреп торалар. Тамаша залының алтынланган милли орнаментлары, ишекләрдәге нечкә инкурстация — кыскасы, мондагы һәр нәрсә кешедә шатлыклы тантана һәм соклану тойгысы уята. Театрның бөтен тышкы һәм эчке архитектурасы, Татарстанның халык художнигы Бакый Урманче әйткәнчә, рухландыргыч дәртле музыканы хәтерләтә.

1962 елда Исмәгыйл Гайнетдинов проекты буенча Идел буенда төзелгән Казан елга вокзалы ансамбле — авторның яңа иҗади уңышы. Бу ансамбльнең архитектура композициясе технологик һәм функциональ яктан бер-берсе белән нык бәйләнгән архитектура корылмаларыннан гыйбарәт. Ансамбльнең композицион үзәге — вокзалның пыяладан һәм бетоннан корылган төп корпусы. Аның биеклеге ун метрга җиткән, берьюлы 600 кеше сыйдыра торган зур һәм якты залы башкарылыш ягыннан гадилеге белән аерылып тора. Шәһәр ягыннан да, елга ягыннан да төп фасадларга чамалап кына милли форма элементлары һәм детальләре кертелүе, причалга чыга торган баскыч мәйданчыкларындагы тәрәзәләрнең тесле пыялалар белән бизәлүе, вокзал мәйданыннан гостиницага керә торган ишекләрнең матур итеп керамика белән рамлануы «Казан — культура үзәге», «Казан — индустрия үзәге һәм биш диңгез порты» дигән темаларга художниклар В. Гаврилов һәм Т. Крылова белән берлектә башкарылган монументаль паннолар — болар барысы да пассажирларга аларның нәкъ менә Татарстан башкаласына килеп төшүләрен ачык аңлатып торалар.

Үзенең монументаль һәм бер үк вакытта искиткеч якты һәм ягымлы эстетик кыяфәте белән Казан елга вокзалы ансамбле Идел буенда иң яхшылардан санала. Аның авторы Исмәгыйл Гайнетдинов СССР халык хуҗалыгы күргәзмәсенең бронза медале белән бүләкләнде. Исмәгыйл Гайнетдинов Татарстанда гына түгел, аның чикләреннән тыш та иң күренекле архитекторлар сафында тора.

Аның күп тапкырлар республика, Бөтенсоюз һәм халыкара архитектура конкурсларында катнашып, югары бәя алуы һәм күп тапкырлар бүләкләнүе дә әнә шул турыда сөйли. 1934 елда, әле гади төзүче инженер һәм институт ассистенты булган дәвердә үк, ул Свердловск шәһәрендә СССР Фәннәр академиясенең Урал филиалы ансамблен төзү буенча иң яхшы проект өчен үткәрелгән Бөтенсоюз конкурсында дүртенче урынны алды һәм 1940—1946 елларда аның архитектура проектлары: Севастополь шәһәре өчен 1941—1945 елгы Бөек Ватан сугышы геройларына һәйкәл, Германия Демократик Республикасының Алленштейн шәһәре өчен 2 нче Бело-



*Казан елга порты. Пассажирлар залы.*

руссия фронты гаскәрләренең җиңүе хөрмәтенә монумент, фасадларында керамик материаллар кулланып салына торган күпкырлы типовой торак йортлар һәм башка әсәрләре беренче Бөтенсоюз премияләренә лаек булды. 1959 елда Мәскәүнең көньяк-көнбатыш өлешендә торак район төзү буенча эксперименталь проектка үткәрелгән халыкара конкурста иң югары премияне яулап алуы да аның зур иҗади җиңеше.

Ашкынулы һәм тынгысыз характерлы, югары эрудицияле һәм эштә ару-талуны белми торган бу кеше илебез тормышындагы бөтен вакыйгаларга актив катнаша, бүгенге көн белән бергә атлый һәм кызыксынып киләчәккә карый.

Әле Бөек Ватан сугышы бара иде, ә ул, архитектура академигы В. И. Семенов белән бергә, Гитлер гаскәрләре тарафыннан җимерелгән Ростов-Дон шәһәрен торгызу проектын төзүгә катнашты, немец-фашист яулары куылганнан соң торгызыла торган колхоз һәм совхозлар өчен төрле материаллардан торак йортлар салу буенча мөстәкыйль рәвештә дистәләрчә типовой проектлар эшләде. Хәзер бу проектлар буенча Украинада, Белоруссиядә, Смоленщинада һәм чиксез Ватаныбызның башка бик күп өлкә һәм крайларында меңнәрчә яхшы, уңайлы йортлар салынды. Алар чын типовой йортлар булып калдылар һәм СССР Министрлар Советының төзелеш буенча Дәүләт Комитеты рәсми альбомнарына һәм каталогларына керделәр.

Исмәгыйль Гайнетдиновның күпкырлы иҗаты турында сөйләгәндә, аның эшчәнлегенең тагын бер ягы турында: илнең күренекле скульпторлары белән берлектә, граждannар һәм Бөек Ватан сугышы геройларының, күренекле партия, культура һәм сәнгать эшлеклеләренең исемнәрен мәңгеләштерү өстендә дә эшләвен әйтмичә китеп булмый. Мәсәлән, 1950 елда, атаклы скульптор В. И. Мухина һәм осетин скульпторы С. Д. Тавасиев белән берлектә, ул ике тапкыр Советлар Союзы геройлары Н. И. Столяровның Казандагы һәм армия генералы И. А. Плиевның Орджоникидзе шәһәрендәге һәйкәлләренең архитектурасын иҗат итте. Аның скульптор Карандиевский белән берлектә иҗат иткән проекты буенча Мәскәү өлкәсенең Хотьково шәһәрендә В. И. Ленинга һәйкәл куелды.

Осетин әдәбиятына нигез салучы, демократик шагыйрь һәм мәгърифәтче Коста Хетагуровка 1955 елда Төньяк Осетия АССРның башкаласы Орджоникидзе шәһәрендә куелган монументаль һәйкәл аның иҗатында аерым урынны алып тора. Орджоникидзе шәһәрендә татар архитекторы проекты буенча шундый һәйкәл корылуы чын-чыннан символик күренеш һәм ул Исмәгыйль Гайнетдиновның халык традицияләрен куллануда гы үз принцибына һәрвакыт тугры калуын күрсәтә. Коста Хетагуровка һәйкәл куйганы һәм сәнгать өлкәсендәге хезмәте өчен 1955 елның январенда Төньяк Осетия АССР Верховный Советы Указы буенча Исмәгыйль Гали улы Гайнетдиновка Төньяк Осетиянең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Ә 1958 елда КПССның Төньяк Осетия өлкә комитеты һәм Төньяк Осетия АССР Министрлар Советы Коста Хетагуровка куелган һәйкәл авторларын Ленин премиясенә тәкъдим итте.

Татар халкы тарихында беренче архитектор, художник, педагог һәм архитектура профессорының тормышы һәм иҗаты гаять бай. Аларның барысы турында сөйләү өчен тулы бер монография кирәк булыр иде. Аның утызынчы елларда ук беренче тапкыр татар телендә чыккан басма хезмәтләре — «Сызымнар, аларны таный һәм яза белү», «Шрифт үрнәкләре» дигән китаплары, үзәк нәшриятларда чыккан тирән эчтәлекле гыйльми һәм тарихи әсәрләре — «Авыл төзелешендә торак йорт» (1948 ел), «Казан татарларының агач биналар архитектурасы» (1960) һәм башка хезмәтләре турында да күп язарга мөмкин.

Исмәгыйль Гайнетдинов шулай ук вакытлы матбугатта да актив катнаша, актуаль темаларга фәнни-теоретик мәкаләләр белән дә еш кына чыгыш лар ясый.

Татарстанның, Башкортстанның һәм Төньяк Осетия АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, татар халкының талантлы улы, архитектура профессоры Исмәгыйль Галиевич Гайнетдиновның бөтен тормышы туктаусыз эзләнүдән, тырыш һәм түземле хезмәттән гыйбарәт.

Аның бөтен иҗади эшчәнлеге зур идеяле, тулы канлы сәнгатькә, көчле, тирән мәгънәле образлар, монументаль формалар сәнгатенә омтылу белән характерлы.

**Нәкый Исәнбәт**

# УНСИГЕЗЕНЧЕ ЕЛДАН БЕР СӘХИФӘ[1]

## Сүз башы



*Үткән мәкаләмдә Шәйхзадә Бабичны 18 елның җәендә Өфедә Дарелмөгаллиматта ничек күргәнемне язган идем. Ул көннәрдә минем үз язмышым да шактый гыйбрәтле булганга, бу юлы укучыларым алдына үз хәлемнән бер сәхифә ачып үтәргә җөрьәт итәм. Аңа тукталуымның, билгеле, үз сәбәбе бар.*

*Күп милләтле Россиядә төрле тарихи һәм иҗтимагый формациядәге халыкларның милли азатлык хәрәкәтләре революция белән бик нык бәйле. Шулай ук интеллигенциянең революциягә нинди мөнәсәбәттә булуы һәм роле кызыклы. Русларда бу хакта күп языла. Бездә бик аз. Хәлбуки, татар интеллигенциясенең революциягә катнашуы аеруча киң һәм көчле булды. Моның сәбәбе бик ачык: революциягәчә рус хөкүмәте татар милли азатлык һәм культура хәрәкәтенә каршы дошманлык сәясәте тотып килде; татар милли мәктәпләрен танымады, бер мәктәп тә салмады, салынганын яптырды һәм бер мөгаллимгә дә хезмәт хакы түләмәде. Октябрь революциясе, рус патшалыгының бу кара мәкерле империалистик һәм руссификаторлык политикасын җимертеп ташлап, совет милли автономияле республикалар игълан итте һәм милли мәктәпләрне тигез хокуклы ясап, азчылык милләтләр арасыннан чыккан интеллигенциянең, шул исәптән татар интеллигенциясенең дә, мәхәббәтен казанды. Шунлыктан чинсыз һәм хокуксыз татар укымышлыларының революциягә мөнәсәбәтен хаким милләт яки пайтәхет интеллигенциясенең мөнәсәбәте белән бергә куярга ярамый.*

*Бабич та, мин дә бу революцияне һәр икебез дә укытучы һәм формалашкан шагыйрь булып каршы алган кешеләр. Без интеллигентлар... Алай дигәч тә сез тагын бу сәхифәдән ул ялкынлы көннәрнең бар яктан да яктыртылуын көтмәгез. Бу тик үз башымнан үткән бер вакыйгага гына. Шулай да ул минем генә түгел, бәлки ул көннәрдәге Бабичның яки безнең сыман кайбер яшьләрнең хәлен дә күзалларга бераз ярдәм итәр.*

АВТОР.

●

Җиктереп пар ат, Арыйга
Туп-туры киттек карап...

. . . . . . . . . . . .

**Шулай дип, без Һади абзый[2] белән пар атта төньякка карап китеп барабыз...**

[1] Кыскартылып басыла. Редакция.

[2] Һади Сәгъди Атаулы — мәгърифәтче, философ, язучы; «Бәхетсезләр» хикәясе, «Шура» журналында басылган житди мәкаләләр һәм «Сабир» псевдонимы белән язылган кайбер әһәмиятле хикәяләр авторы. Габдрахман Сәгъдинең агасы. Башта мулла, мөгаллим, соңыннан укытучы, революционер.

Һади Сәгъдигә һәм монда язылачак вакыйгаларга бәйләнешле тагын бер истәлек басылып чыкты. Кара: «Агыйдел» журналы, 1967, № 9, 78—83 битләр, «Яңы дәвер таңында», Мәрьям Сәгъдиева мәкаләсе.

Юк, без башта бер дә төньякка дип түгел, көньякка, Ләмәз башкортлары арасына барып ял итәбез дип, юлга чыккан идек. Шулай дип, кичә Атаудан Малаязга килеп кунган да идек. Анда безгә Ләмәз ягы тыныч түгел, башкортлар кузгалган дигән бер хәбәр җиткерделәр. Инде кая барырга? Кичә Һади абзый белән Малаяз тавына менеп, ерак-еракларга карап, шул хакта уйлаштык. Ярый, без әйтәбез, көньякта Өфе асты Ләмәз башкортлары кузгалса, ай алла, төньякта аның кузгалмый ятканы юкмы? Менә үзебезнең Залтауыс[1] өязендә үк, Сикияздан арырак Арый дигән авыл бар, шунда Һади абзыйның бик хөр табигатьле, шаян сүзле бер башкорт дусты бар икән. Ял өчен шуннан да күңелле, тыныч җир булмас. Барабыз да шунда ятабыз. Әнә Ярулла карт Алтафының пар аты бар, төшәбез дә шуны яллыйбыз дип, аңа киттек.

Алтаф абзый... Сүз рәте килгәч, аның кем икәнен сезгә дә әйтмичә булмый. Хәер, озак сөйләп торасы юк, сез аны үзегез дә бер күрүдә таный алырсыз: аның теле, ни өчендер, һәрвакытта да авызыннан бераз алга чыгып торыр. Әмма авыз дигән нәрсәсен әйтсәң, ул аны җәй көне генә түгел, хәтта кышкы нинди каты бураннарда да япканы юк, диләр.

Әнә ул үзе дә күренде: өстенә ак мәллә[2] чикмәнен кигән, билен буган, юка гына гәүдәле бер нәрсә. Күрер күзгә дивана сыңары инде. Алай дигәч тә, көләргә ашыкмагыз, эше бер дә дивана түгел аның. Пар атын да, менә дигән тарантасын да үз акылы белән тапкан. Ә бит үзе моннан бер-ике ел элек кенә кеше ишек төбен таптаган Алтаф! Шунсын да әйтим, ул тагы кешенең үзе белән бик кызыксынучан. Белмим, аның күз алдында үскәнгәмедер, үзе миннән биш-алты яшькә генә олы булса да, мине малайсытып сөйләшә. Тәүдә ул баштанаяк үземне карый, киемнәремә хәтле тикшерә. Менә әле дә шулай. Мин аңардан — атларың бушмы? Ул — буш, ди. Үзе минем эшләпәмә сузыла:

— Нигә мондый кырыйлыны киден? — ди, тотып-тотып карый. Үзенең теле һаман авызыннан чыккан. Менә шүрәле. Бер дә юньләп сөйләшеп булмый. Мин сүзне Һади абзыйга тапшырам. — Арыйгамы? — ди. Анда сезгә нәрсәгә, — ди. Китте бу тагын. Ахырында шул мәгълүм була: Алтаф абзый безне анда алып барырга әллә кайчаннан бирле ике куллап әзер икән. Арыйга гына түгел, аннан да арыга алып китәр. Хет җәһәннәм тишегенә хәтле. Тик менә «кирнески» ягыннан безнең эш ничек тора?

— Керенский?

— Әйе, әйе, «кирнески», — ди. Алтаф абзый бер чыгарган телен кире алмый. Ул уйнап сөйләшми. Күренеп тора, абзый Малаязда торса да, эшне бары «кирнески» белән генә йөртә. Шунсыз үзе дә, аты да беркая да атламый. Болай булгач беленде, эш Алтаф абзыйда түгел, үзебездән тора икән. Ярый, Керенский икән Керенский. Без дә, бүтәнчә булмагач, эшне аның аша йөртербез... Шуңа ныклы вәгъдә алгач кына, менә хәзер ул үзенең әйбәт тарантасының алынтактасына утырып, безне Арыйга алып китеп бара...

Кайсы число булды соң әле бүген? Әйе, әйе... 12 нче июнь. Мең дә тугыз йөз дә унсигезенче ел...

...Барабыз...

Яңгырдан соң көн дә ачылып китте. Тәгәрмәчләр юлдан балчык алып ара-тирә безгә дә атып шаяралар. Бигрәк тә тарантас артына турпышага төреп бәйләгән ике зур саквояжның кирәген бирә. Тарантас нык, атлар шәп. Алтаф абзыйның ак мәлләгә төренгән юка гына хәйләкәр аркасы һаман безнең алда селкенә.

Хәер, бу абзый эшне Керенский белән генә йөртә дигәч тә гел аның аркасына карап барырга димәгән. Күреп кал, без хәзер дөньяның иң матур почмагы булган бер җирдән үтеп барабыз. Муеннарымны бора-бора, шул тирәне күзләрем белән ашардай булып, бер күреп калырга тырышам. Каршыдарак, алсу-көрән бит очларын күрсәтеп, безгә карап торган нииндидер яшерен серле Янгантау[3]. Аңа каршы су аша мәһабәт

---

[1] Залтауыс — Златоуст. Урал татар, башкортлары телендә шулай дип кенә йөртүдән, монда да шулай алына.

[2] Мәллә — нык, нечкә, пеше итеп басылган тула.

[3] Янгантау — җир астыннан шифалы пар бәреп яткан, бик сирәк тауларның берсе. Бу тау хакында проф. Г. Терегуловның бик мөһим һәм кызыклы гыйльми хезмәте бар. Бу тауда хәзер курорт.

Каратау торып баскан. Аны әйтмәгез!.. Ул минем өчен җир йөзендә бердәнбер мөкатдәс, изге тау! Теләсәгез сез мине шаман дип атагыз, бала чактан бирле күңелем үзеннән-үзе шул тауның тиңсез матурлыгына табына. Белгән кешеләр аның текә биеклеген бер чакрым имеш, дип сөйлиләр. Түбәсе күккә тигән карлы Илберес, Алатауларны күргәнем бар. Матур алар; ялангач, карлы алар, салкын алар... Каратау башка. Ул — төбеннән алып түбәсенә хәтле калын карурманнар тавы. Әә ерактан карагайда, ул, үзәнгә су эчәргә килеп туктаган күксел фил кәрваны кебек, тезелеп тора. Шуңадырмы, иң алдагысын Фил тау дип тә йөртәләр. Үләм мин шуның мәһабәтлелегенә! Юк, юк, сөйләтмәгез, филләре белән Һиндстанның да кирәкми. Тау түгел, җыр бу, үзе бер сөйләнмәгән тылсымлы әкият! Кем белә, бәлки борынгы төрки халыкларның мифик бабалары, булган Угыз ханның улларына йорт итеп биргән Каратавы да шушы булгандыр [1]... Аңсы җитмәсә, әнә тагы монда аста, безнең алдан-арттан калмыйча, сузылып әйләнеп бер гаҗәп елга агып ята. Оста курайчылар кулындагы курайдан сызылып чыккан иң матур башкорт көе кебек, борылып-борылып аккан шул сихерле елга — минем тәннәремне үзенең көмеш якты сулары белән коендырып үстергән Үзән түгелме соң! Белгән кешеләр аны да сәгатенә 14 чакрым тизлектә юрткан ат йөреше белән агадилар. Шул сыгылма биллелеге, шул йорлыгы өчен аның үзен дә бит Үзән генә димичә, Йорүзән [2] дип атыйлар. Әнә күр, аның юлын Каратау булып Каратауның фил кәрваны да кыеп үтә алмаган, шунда килеп борыны белән терәлгән дә әле булса Йорүзәннең агып бетеп юл биргәнен көтеп тора... Менә без хәзер пар атта шул ямьле Йорүзәннең бу як сыртына менеп барабыз. Тик, нигәдер, Һади абзый гына бу ямьләргә күтәрелеп карамый, бик тын. Соң ул философ кеше, билгеле, безнең шагыйрь халкы кебек ашкынучан түгел. Бәлки, әле ул шушы минутта дөнья күләм ниндидер бик зур мәсьәләне хәл итеп килә торгандыр. Яки ниндидер бик мөһим хакыйкатьнең ноктасына ирештем дигәндә генә җеп очын югалтып яңадан эзли торгандыр...

Шулай матур гына китеп барганда, Алтаф абзый атларын туктатты. Сикереп төште. Без дә төштек. Карыйбыз: алдарак, юлда калкып, бер капчык ята. Ярты капчык чамасы булыр, солы. Алтаф абзыйның күзләре тыҗрый, ялт-йолт карана башлады. Якын тирәдә кеше заты күренми. Алай да алла сакласын, чак кына көт, без әйтәбез. Иясе-ние килеп чыкмасын...

Мин Һади абзыйны тарантас артынарак алып киттем:

— Нәрсә бар? — мин әйтәм. — Ни уйлап киләсең, Һади абзый? Әллә һаман шул кичә күргән төшеңнеме?

Сөйләгән иде: кичә төнлә Малаязда ул ниндидер бик гаугалы, куркынычлы төш күргән. Бик зур мәхшәр купкан да без икәү шул гарасатта буталабыз, имеш. Аныңча, безнең хәзер пар атта китеп барган бу матур юлыбызның өсте бер нәрсә, асты аның, нәрсәдер, бөтенләй-бөтенләй икенче. Без үзебез дә белмичә ниндидер кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күперен яки, гыйлем кешеләр теле белән әйтсәк, тарих күперен кичеп барабыз шикелле. Үзебез генә түгел, халкыбыз белән. Шушы биек Каратау, шушы ямьле Әй, Үзән буйлары белән; шуларны биләгән халкыбыз белән... Безне нидер, нидер көтә. Бик һәйбәтләп язмышның көре кылычы аша кичеп барабыз без, беләсең килсә...

Нәрсә сөйли бу, Һегельгә охшаган зур күзле кеше? Әллә мин белмәгән берәр нәрсә бармы?

— Ташла, Һади абзый, — дим. — Ил башында нинди генә фаҗигаләр, нинди генә авыр язмышлар уйнамасын, яңадан безгә патша кайтмас; яңадан цензура белән полиция дигән ике скелет, кабердән кубып, җилкәбезгә атланмас [3]. Бетте халыклар төрмәсе булган Рәсәй! Кайтара алмаслар! Ә бу төшеңне әйтсәң, мин үзем дә әллә ниләр күреп, мәйханә килеп бетәм. Төшкә ышану характерсызлык ла ул. Әнә, Үзәнне карап кал!..

Һади абзый артта калган Үзәнгә, Илтәй авылы янында күренеп торган паромга карады да, кинәт кенә миңа сорау бирде:

---

[1] Борынгы «Огузнамә» китабын кара.

[2] «Казан утлары»ның былтыргы 5 санында басылган тарихи «Салават бәете»ндә китерелгән Йорүзән елгасы шушы. «Йелүзән» яки «Йөрүзән» дию ялгыш.

[3] ... «Өстебездә торды шайтан скелеты селкенеп»... Ул көннәрдә «Кызыл байрак» газетасында басылган шигыремдә дә шундый юллар бар.

— Ә син әле генә, без шул паромда чыкканда, бер әйбер сизденме — юкмы?

Мин сискәнә калдым:

— Нинди әйбер? Юк, мин бит паром тартыштым. Әйе, анда тагын арбалар, кешеләр бар иде. Ә нәрсә?

— Ике кеше, берсе озын, берсе гәүдәгә базык, бик елгыр күзле, безне бик каты күзәттеләр. Берсе, елгыр күзлесе Алтафтан безнең кая баруыбызны сорашты. Аннан койрыкта басып торган Озын янына килде. Бер безгә, бер аңа карап, күз очы белән бик мәгънәле итеп Үзән төбенә таба ымлады...

— Безне Үзәнгә салырга дипме әллә? Китче әле... ха-ха-ха! Я, я? Шуннан? Ә тегесе?

— Ә тегесе дәшми. Тора. Аңа да, безгә дә карамый, күзен кыса төшкән дә, беләсеңме кая? Әнә теге Янгантау битенә караган. Берни дә әйтми. Аңлыйсыңмы син, тора! Бары Янгантау, бары тик аның кызарып янып торган битенә караган. Шул үзе сиңа берни дә сөйләмимени?

— Ягъни, тимә, китә бирсеннәр, әнә барыр юллары җәһәннәм, диюе. Ха-ха-ха! Ай Һади абзый! Шомлансаң, шулай күкле-яшелле күренә шул ул. Бу төш. Әлеге синең кичә күргән куркынычлы төшең башыңнан чыгып бетмәгән. Шуның тәэсире.

— Көләсең әле син, малай...

Алтаф абзыйның табылдык мал хуҗасын артык күтәр әмәле юк, кулы һаман капчык өстендә... Ул, куанычыннан телен тагын да чыгара төшеп, аны күтәреп алып килеп, алынтакта астына тыкты.

— Бәхетле юлга чыкканбыз икән. Юлдан солы тиде, сездән дә, алла бирса, тегесе тия; на!.. Киттек!

«Теге» дигәне, билгеле инде, әлеге «кирнески», «кирнески» дигән «керенька» дип йөртелгән кәгазь акчалар инде.

Мин шунда:

— Керенский былтыр, марҗа сарафаны киеп, заграницага качкан, син шуның гамәлдән чыккан кәгазен җыеп йөрисең, — дип котырта башладым.

Чыдамады, үзе дә серен чиште. Я әйт үзең, ди, Алтаф абзыең моннан бер ел элек кенә атлы-арбалы кеше идеме? Шул «кирнески» акча чыккач, аның бар бәхете ачылган. Ул акча бит үзе дә бик матур: шундый кечерәк кенә, үзе дүрткелле. Аннан тагы ул бит әле ике генә төрле: егермелек тә кырыклык! Андый акча Рәсәендә булганы бармыни? Гомердә юк! Рәсәйдә түгел, загранитсада да юк! Ә Кирнески загранитса китсә китә бирсен, бигрәк тә яхшы. Үзе дә анда йөри, акчасы да. Загранитсада банкыда боларның (большевикларның диюе) бернинди кәгазь акчасын да танымыйлар, моныкын гына таныйлар икән. Анда ул алтын бәһасенә, ди. Әйтсәм әйтим, бу хәзер чыккан кәгазь акчалар чын түгел, бар да бетәчәк, бу Рәсәйдә иң ахырында бары тик кулында «кирнескиe» булган кешеләр генә чын акчалы булып калачак икән. Чын, чын. Менә ни өчен Алтаф абзыең Арый авылына хәтле ялланып сезне алып бара...

Алтаф агай яңа властьның көчен, аның торачак-тормаячагын бары тик акчасының ныклыгына карап кына үлчи икән. Ә менә бу «кирнески»не, бу үзе дә, бәясе дә квадрат, сәер акчаны ул, аерым бер төрле серле, хикмәтле тылсым әйбере итеп күрә. Фитиш! Син аны, үлсәң дә, бүтәнчәгә ышандыра алмыйсың инде. Мин аның «кирнески»еннән көлгәч, ул моңа бөтенләй бүтән мәгънә биреп, күземә карана башлады. Карашыннан ук сизеп торам, әллә болар ул акча белән түләмәскә итәләрме, я булмаса үзләре дә «керенька» җыярга чыккан кешеләр түгелме, дигән куркулы бер төс йөзенә чыкты.

...Бер сәгать тә бармадык, без инде әйләнеп-әйләнеп аккан ямьле Әй елгасына килеп җитә яздык. Алдыбызда Еланыш күренә. Кечкенә генә бер авыл. Аңа җитәрәк юл буенда ук аунап яткан зур-зур чуен казаннар күренә. Сүнгән җимерек учак кирпечләре өстендә озын турпыша күлмәкле, зур-зур ак сакаллы өч-дүрт урыс карты утыра. Алар тып-тын, бернинди хәрәкәтсез. Без, Мияшәгәргә кермичә, моннан Сикияз-га турыдан барып буламы, дип алардан сорыйбыз. Картлар урыннарыннан торалар. Әйтерсең, алар түгел, шул сүнгән учаклардан ниндидер аксыл төтеннәр кубып аякка баса. Алар берни дәшмиләр. Безгә карамыйлар да. Шул аякланган төтеннәр кебек төрлесе төрле якка китеп баралар. Мин якыннанрак узып барган бер аксакалның колагында алкасы да бар икәнен күрәм. Сабаклы алка түгел, ул аның колак йомша-

тында ук утырып торган зәбәрҗәт сыман ниндидер җемелдек кашлы алка. Күрәм — староверлар. Алар — бервакытта да бер патшага да солдат бирмәгән, хөкүмәт чиркәвенә йөрмәгән, адәм баласына адәм каны түгү хәрам икәнен үз табигый хисләре белән сизенеп, үз ирекләрен, үз иманнарын беркемгә дә сатмыйча борынгыча яшәргә өйрәнгән кешеләр. Алар безнең ише басурманнарга җавап биреп торсыннармы тагы! Күзебезгә алар җир кендегеннән чыккан ниндидер бер пәри кавеме кебек күренсәләр, ихтимал, безнең үзебезгә алар дөнья бутап йөрүче шайтан токымы дип караганнардыр. Алай да бу аунап яткан чуен казаннар, ташландык сөякләр монда нәрсәгә соң? Әллә чынлап та кичә төнлә монда шайтан туе булганмы?

... Юлыбыз безне Мияшәгәрнең кыр капкасына ук китереп тери. Без анда кермичә, кырый юлдан Сикиязга үтмәкче булабыз. Шул юлга борылабыз дигәндә генә, кыр капкасы төбендә басып торган бер агай, «тпру!» дип кычкырып, атыбызны туктатты. Бер кулында ике генә җапле көлтә сәнәге. Капканы тибеп ачып җибәрде, килеп ат башыннан каерып тотты да безне эчкә кертте, «аристауын!» дип кычкырды һәм... арттан капка ябылып та куелды. Бер күзе зур, берсе йомыкый булган бу йолкыш кыяфәтле кеше күп сөйләшеп тормады, хәрәкәтеннән дә эш нидә икәне тиз аңлашылды: сәнәкчеләр күтәрелгән. Авылга килгән керә, кергән чыкмый икән.

Нишләргә? Кемгә төшәргә? Урамга кердек. Кайбер тәрәзәләр өлгесез, мендәр капланган. Аргы аралыкта, ат койрыгын төйнәп атланып пычракта чапкан ниндидер кешеләр күренеп кала. Русча майтлап сүгенгән тавышлар ишетелә. Кулларда — кайсының сөнге, кайсының сәнәк. Кайсында бүре үтерә торган кистән.

Монда Һади абзыйның дусты Кара мулла Әхмәдулла дигән кеше бар. Аның җил капкасын ачып, ишек алдына килеп төштек. Шундук артыбыздан сәнәк-сөнге тоткан агайлар, тентү килеп җитте. Кем булуыбыз, нишләп йөрүебезне сорау башланды. Алтаф абзый паникага төште. Ачылып торган авызыннан теле тагын да ныграк чыкты. Ул, билгеле, үзенә тиешле «керень»ка алды. Куенына салгач, әйттемме сезгә дип, түшенә кагып куйды. Күрәсең, аңа хәзер «керенька» белән бергә Керенский власте да кайтты. Аны әле тегендә, әле монда тартып сөйләшә башладылар. Ул аларга нидер әйтеп, читтә нидер сөйләшкәләп, алынтактасына тиз генә утырып китеп тә барды. Соңыннан белдек, ул безнең өскә әлләниләр сөйләп, «Атаманнары шушы, мин сезнең монда бу эшне башлавыгызны ишеткәч тә, аларга ялланган булып, юри туп-туры үз кулыгызга алып килдем» дип, әллә ниләр ялганлап киткән булып чыкты. Билгеле, Алтаф абзый моны безгә дошманлыктан эшләми, аның үз кайгысы кайгы, аңа хәзер үзен һәм яхшы пар атын бу җеннәр кулыннан коткарып, исән-сау ычкыну кыйбат. Аңа хәзер «Җир кендегенә бер генә юл!» Шуңа күрә ул «пәригә яулык, миңа саулык! Җиргә салмый, җенгә салам!» дип әйтә дә, бу «Җир иясе җирән сакал»ларга үзенең пар аты урынына безнең пар башыбызны тоттырып китә...

Без Әхмәдулла мулла порукасына калдык. Ул бу фетнәле эшне безгә болай аңлатты: монда, Мияшәгәрдән ерак түгел җирдә, Сикияз дигән бай урыс авылы бар. Анда Үзән буе башкорт җирләрендә утарлар тоткан калын помещик Мурашевлар, тагын башка зур кулаклар, урынсыз калган ниндидер земский чиновниклар, погонсыз калган эфисәрләр, поплар күп. Шулар ерак Ярслау губернасына хәтле агент йөрткәннәр. Аннан безнең як Чиләбе-Мияс вокзалындамы-кайдадыр чехлар кузгалуын ишеткәннәр. «Советлар хәзер җиргә социализация ясый башлый, җирсез каласыз!» дип, урта хәллене дә котыртып, астан коралланып, кичә төнлә андагы волостьны басканнар. Шундук «ак» штаб корып, тирә-як авылларга ат чаптырып, кәгазь таратканнар: «Без совет властен бетердек, бу кәгазьне алу белән үзегездәге бетерегез, бетермәсәгез, кызыл буласыз да үзегезне төшеп кырабыз!» Шундук тирә-яктан бөтен өяздә капыл гына стихияле күтәрелеш, дәһшәтле крестьян күтәрелеше башланган. Олы юл өстендә яткан Мияшәгәр авылы теләсә дә, теләмәсә дә хәзер шул яу астында калган. Кызыл гвардиячеләр үтерелгән, кайберсе качкан. Моннан дүрт кенә чакрым җир Сикиязда кичәдән бирле үлеш тә кырылыш, ди. Туры барып төшсәк инде беткән буласыбыз икән. Шулай итеп без нәкъ эшнең дуенына килеп эләккән булып чыктык.

...Бу Кара мулланы әйтәм, кызык кына кеше: ярлы гына бер мулла үзе, хөр фикерле, аз сүзле. Тукайның «Бер рәсемгә» дигән шигыре бар. Анда бер матур кыз рәсеменә сокланып:

Бу озын сачне каян алган икэн соң бу кояш? —

дигән юллар бар. Тукай гына әйтә алган искиткеч гүзәл һәм оригинал бер сурәтләмә ул. Безнең арада үткен теллелеге белән мәшһүр булган Миркәй матрос дигән кеше әнә шул шигырь юлын Әхмәдулла муллага борып:

Бу каралыкны каян алган икән соң бу кояш? —

дигән сүз тараткан. Ягъни аның тәне нихәтле кара булса, күңеле шулкадәр ак — якты булуына ишарә иткән иде. Менә бүген шул аз сүзле, сабыр табигатьле кешенең башына кисәү булып без килеп аудык. Бу хәл нинди авырлыклар китерсә дә, ул аны безгә белдерми, шулай булса да сизеп торабыз, үзен хәзер безнең өчен кара көчләр кыса, ә ул һаман халык арасында йөреп, сабырлык белән аларны тыныч булырга өнди иде.

Мияшәгәр авылы сәнәкчеләр кулында булса да, эшнең үтерешкә кадәр барып житмәвенә бернечә шундый яхшы кеше сәбәпче иде. Ул төнне шул «мулла өе» безне хәвеф-хәтәрдән саклады. Ишектә сәнәкле каравыллар торды.

Икенче көнне төш вакытларында безне авыл уртасына алып чыктылар. Һаман шул кара яу кебек халык. Безне китереп кулларны артка каерып бәйләп, олау арбасына салдылар. Штабларына, әлеге Сикиязга дип, алып киттеләр. Арттан да атлы сәнәкчеләр килә. Сикияз тегермәненә житәрәк, безне атка менгән аксакаллы бер мәһабәт урыс туктатты. Конвойлардан сорашкач, үзенең Сикияздан штабтан жибәрелгән кеше икәнен, штабта безнең хакта ишеткән булуларын, ләкин хәзер анда арестантлар салырга урын юклыгын, шунлыктан бүгенгә Мияшәгәрдә кундырсыннар дип әйтергә жибәрелгән кеше икәнен сөйләп, олауны Мияшәгәргә кире борды.

Мияшәгәргә кире әйләнеп кайтып житкәч, мәйдан гөж килде. Кара мулла авыл халкына безнең укытучылар булуыбызны һәм партиясез икәнлегебезне кат-кат әйтеп караса да, халык ни эш белән йөргәнебезне белми дә, ышанмый да иде. Нәкъ гарасат эченә туп-туры үзебез ат яллап килеп кергәч, безне большевиклар жибәргән яшерен агент дип шикләнәләр. Чөнки, бер яктан, бу канлы эшкә үзләренең катышкан булып күренүләреннән куркалар, эшнең ахырын кем белгән?.. Шул ук вакытта безне үтереп, жинаятьне үз өсләренә алырга да бик үк базмыйлар, чөнки Мияшәгәр череп беткән байлар авылы түгел, күбесе жирсез олаучы («прасел») лар. Шуның өстенә, күреп торабыз, былтыр көз генә фронттан «большевикланып» кайткан солдатлары, укучы яшьләре, безне түгәрәк алка эченә киртәләп алып, кара көчләрдән кыйнатмаска тырышалар иде. Инде без кире әйләнеп кайткач, кара көчләр тәмам котыра башлады: «Без бу кешеләрне белмибез, бәлки аларны монда Ленин жибәргәндер? Штаб аларны ни өчен Мияшәгәргә кире кайтара? Үз кулыгызга тапшырдык, эшләрен үзегез күрегез, дип бирүләре бит!» — дип кычкырыну, сүгенү китте. Тавыш зурайды. Арттан, яннан кушчаннар тыгызлашып кереп кул озатулар башланды.

Шул чагында кемдер: «Шәрип авыллар килә!» дип кычкырып жибәрде. Йөрәкләр жу-у итте. Чөнки Шәрип авыллар фәкыйрь шагыйрь Акмулланы талау өчен юлда тотып үтергәннәр дип, усаллык белән дан тоткан авыл иде[1]. Шунда икенче бер житез күзлесе юлга карап: «Юк, болар Кадер авыллары! Башкортлар килә!» дип төзәтте. Юлда чабышып килгән сыбайлар (ат менгәннәр) күренде. Халык уртага ярылды. Яхшы атка менгән, бер олы яшьле кеше арадан юрттырып килеп керде. Артындагы сыбайларга нидер әйтеп кычкырды, алар ян-яктан мәйданны чолгап алдылар. Алдагы озын

---

[1] Акмулла — атаклы шагыйрь, акын һәм галим; үзе ясаган ике тәгәрмәчле арбага утырып авылдан авылга, Уралдан Себергә, Төркстанга кадәр йөреп, һәркайда шигырь ярышлары ясап, беркемне дә үз алдына чыгармаган кеше. Арбасының аскы тартмасына китаплар, алынтакта астына балта, тимер кораллар тутырып, (үзе оста!) үзе тегеп кигән бишмәтенең кесәсенә «сугып уйный торган әргән» салып йөргән. Аның хәтта жиккән аты да казакъ акыннары белән ярышып бүләккә алынган булган. 1895 елның 8 октябренда шул ялгыз аты, арбасы белән Троицкидән Залтауыска китеп барганда, Мияс заводы белән Сарслан авылы арасында Гафиятулла белән Дәүләтша дигән кешеләр аны талау нияте белән үтергәннәр. Безнең өяздә «Акмулланы Шәрип авыллар үтергән» дип кенә өзеп әйтәләр. Әмма бу ике кеше икесе дә шул авылныкымы яки берсе генәме, анда барып йөреп төпчи алмадым. Аның революциягә кадәр чыккан тәржемәи хәле китабында, бу ике кешенең башкорт булуы күрсәтелә.

Мин яшь чакта әле Акмулланың үзе дә, телдән әйткән шигырьләре дә безнең Залтауыс өязендә бик мәшһүр иде. «Шагыйрь каны атлатмый» дип, Шәрип авылларына да шуның өчен бер шом белән карыйлар иде.

буйлысы, атын туктатып, уртада басып торган Һади абзый белән мине тиз генә күзләре белән сөзеп чыкты. Өстендә һәйбәт юка кара бишмәт, аның өстеннән каеш буып казачи кылыч таккан, озынча йөзле, бөркет карашлы, кара мыек, ияк сакаллы. (Әйтүләренчә, Кадер авылының Сабирҗан дигән башкорт икән.) Ул халыкка карап:

— Нишләп үтермәйһегез? Быларды нишләтеп авылыгызза яткыраһыгыз? — диде. Ялт итеп атыннан сикереп төште. Аңарга безне әле генә Сикияздан штаб кире борып кайтаруын әйттеләр. Акт язып утыручы бер яшь егет, дипломатия үткәрү өчен, алдына караган килеш кенә:

— Партийный түгелләр икән. Красный гүәрдин дә түгел, укытучылар икән, — дип өстәде.

Хәер, Сабирҗан агайга тылмач кирәкми, безнең хакта Мияшәгәрлеләрдән артык белмәсә, ким дә белми икән, халыкка карап.

— Большевиклар түгел тиһегез икән. Ярай. Ә был нәмә?

Ул кесәсеннән газета чыгарды да, ачып бер җирен сугып күрсәтте:

— Бына «Чулпан» газеты. Мәскәү Сентралнай кәмитәт. Большәвик Мулланур Вахитов белән Галимьян Ибраһимовтар сыгара! Ленин янында! Бак, монда статия: «Съезд булды, безнең Залтаус өязе советлар власын котлап каршы алды». «Яшәсен пролетарият революциясе!» «Җиргә социализация!» Был кем һүззәре? Астына Һади Сәгъди тип кул куйган. Алдыгызза басып торган ошы кеше түгелме был?.. Менә бында бер шигырь дә басылган. Нәкый Исәнбәт тип кул куйган. Кем һоң ул? Монавы бер колас сәс үстергән, алдыгызза басып торган ошы егетме һин?

Шулай диде дә кылычын суырып алып, алдыбызда айкап җибәрде. Баш түбәмнән кызу бер җил исте, көпә-көндез яшен чагылды. Күрәсең, ул казачи солдат булганмыдыр, кылычы кыл кадәр дә ялгышмый йөри. Гайрәт белән нык-нык басып алдыбыздан үтте. Әйләнеп Һади абзый каршысына туктады да менә бер вакыт кычкырып-кычкырып аны орыша башлады [1]:

— Әйт: синең анаң безнең Ташауыл кызымы? Үзең зур укымышлы Һади мулламы? Нишләп әле син нәсел-нәселдән килгән шул имамлык урыныңны ташлап, шаулап торган мәхәлләңне боздың? Атаң михрабын ятим калдырдың?.. Әнә, Торналинскидәге бер библәтикә марҗасына йөреп, урыстан кыйнала яздың! Курыкма, алар сине онытмаганнар, әле генә Торналылар, синең арттан киләбез дип, балта кайрап калдылар [2]. Ярый бәхетең, сиңа алар кулыннан түгел, үзебезнең мөэмин-мөселман кулыннан — менә безнең кулдан үләргә язган! (Шулай дип кулындагы гәзитне безнең күз алда яман бер шатырдатты, шул гәзит артыннан аның каһәрле йөзе кырыкка сынып кат-кат булып күренде.) Сатсиялизмме? Җиргәме? Әйт, ул җирләр синекеме? Җир бүлү синең эшеңме? Уйнама олы башың белән! Үзең тарих укыган, кем җирләре икәнен бик яхшы беләсең! Син монда гәзитеңә нәрсә ялганлап язып ятасың?

Гәзитне кул сырты белән бәреп атты. Кылычын суырып алып, башкорт җирләренең чиге кайдан кая ята икәнен Һади абзый белән миңа шул басып торган урыныннан ук ишарәләп күрсәтте: саташа күрмәгез, аның чикләре менә бу Әй, бу Агыйдел сулары гына түгел икән, кылыч очы ялт итеп Каратау аша китте, бер чиге Нокырат белән Кәтринбур [3], бер чиге Ырынбур арты Тозтүбәдә булды. Шуңа Иван Грозный үзе «падпис һалган», «урыс батшалары» шул «падпис»ка үзләре хыянәт кылган булып чыкты. «Бояр — помещик, зауытсылардың» башкорт җиренә кул салулары әйтелде. Шуның артыннан «Ни өсен без башкорттар ике йөз ел буе был каланистарга каршы һугышканбыз, каныбыззы койганбыз, ә?» дип, безнең йөзгә туп-туры таш кебек каты бер

---

[1] Әйтергә кирәк, бу сәнәк вакыйгалары минем үзәгемә үткәнгә һәм туганнарыма бик кыйммәткә төшкәнгә, мин ул елларда бу хакта берничә кат истәлекләр язган һәм шулар буенча 1925 елда «Сәнәк сугышы» дигән кинохроника да бастырган идем. (Өфе, «Йәш юксыл» газетасы.) Шул уңай белән, бу Сабирҗан агайның сүзләре дә үз вакытында хәтердә калганча язылып сакланган. Аның безне бу тиргәве ул чорның бер почмагын үзенчә ачып куйганга, аннан да бигрәк безнең шикелле «телгә аллага шөкер» ике кешене кылыч астына куеп, шулхәтле яндырып тирги алган икенче кешене гомеремдә дә бүтән күрергә туры килмәгәнгә, сүзләрен тулырак китерәм. Аңлашылсын өчен, сүзләре татарча бирелә.

[2] Торналылар Һади абзыйны (һәм мине дә булса торгандыр?) үтерергә чынлап та Мияшәгәргә килгән булуларын соңыннан ишеттек. Без ул чагында Сикияз юлында олауда булып калганбыз.

[3] Нокырат — Вятка елгасы, Кәтринбур — хәзерге Свердловск шәһәре.

сорау ыргытты. Аның белән дә безнең күзебез чыкмаганны күргәч, — «Әнә, күзе чыкмаган кеше күрә дип, бу юлы кылыч очы безгә Салаватның Пугачау гаскәренә «аш биргән»[1] урынын төртеп күрсәтте. Һәм шунда кинәт кенә без кичә күргән Еланыш яны юл читендә аунап яткан казаннар, сөякләр күз алдыбызга килеп китте. Теге алка таккан староверларның үз авыл тирәләрен шул җәһәннәм калдыгыннан тазартып йөргән булулары хәзер әйтмичә үк аңлашылды. Шуннан безгә Сабирҗан агай каты итеп, хәзер революция булгач, бу җирләр берсүзсез төп башкорт халкыныкы булып калуын, «революциянең үзенең булуы да иң элек безгә ошоның өсөн!» икәнен әйтте. Шуны әйткәндә аның буе-сыны тураеп китте. Сабирҗан агаем торган җиреннән үзе дә бер минут эчендә бу җирләрнең төп борынгы хуҗасы гайрәтле башкортка әйләнде. Әйләнеп килде дә менә ул бүген үз тарихын үзе ясаучы халык булып, «үз йөмһүриятен беркемнән дә һурап тормай үзе яһап үзе игълан иткән башкорт» булып, безнең алга нығытып килеп басты. Баса биреп кулындагы яшен кылычын шундый бер коточкыч айкап җибәрде — кем агай, шуннан соң да башым беркая да очып китмичә әле һаман үз җилкәмдә, үз урынында кала икән, бу могҗиза, билгеле, минем башымның шәплегеннән түгел, Сабирҗан агайның кылыч һөнәре шәплегеннән иде. Әмма ләкин өерманең тагын да кызурагы Һади абзый өстенә китте.

— Син монда гәзитеңә нәмәкәйләр ялганлап язып ятасың? Кемнең җирен буләсең? — дип ул җирдә яткан гәзитнең өстенә үк басып, үкчәсе белән аны артка тибәрде. — Син әле үзеңне пырлитар димәкче буласыңмы? Син дә? (Монсы миңа.) Халык, халык имеш! Менә халык алдында басып торасың. Җавап бир: ни хакың бар синең халык исеменнән мондый ялганнар язып ятырга? Ни хакың бар синең безнең динебездән көләргә? Әллә синең үзең тапкан бер хак юлың бармы? Саескан җырын откан карга кебек, син дә кешегә ияреп кенә Маркс дип кычкырасың бит!

Пешерә генә, малай... Моннан да ары теләсәң кая бар! Үзе һаман кылычын безнең муен тирәсендә биетә. Билгеле, аңа хәзер безне үтерү бернәрсә дә түгел, моның өчен аңа җавап та юк, суд та юк. Ләкин ул кылычның кыл хәтле чамасын да белә, каһәр. Ул үзе болай башка сәнәкчеләр кебек безгә бернинди оятсыз сүз әйтми, сүгенми. Әмма ләкин теле! Шунсын да әйтим, ул мәсьәләдә без үзебез дә аллага шөкер, бирешкәннәрдән түгел, кулыбызга кылыч тотмасак та, өяздә алдыбызга кеше чыгарганыбыз юк. Ләкин бу кешеме?.. Кылычы кылыч, әмма теленә караганда аның ул Залтауыс кылычы нәрсә! Шуның белән башны чабып кына өзгән булса, мең яхшы буласы икән. Шулай дип торсам, туктап тор әле син, бу әле аның безнең белән бик әдәп даирәсендә, шәригатьчә генә сөйләшүе икән. Шуннан, тыңла әле син, нәрсә ди бит бу каһәр:

— Әйтер идем инде мин сезгә, ярый инде, уразалы авызымны пычратасым килми, калып торсын. Кулымны да канга тыкмыйм. Иманга килегез! Тәүбә итегез! Моннан болай халыкны болгап йөрмәбез дип, Коръән тотып ант итегез! Уразадан качып, көндез сәхәр ашар өчен мөсафир булып та йөрмәгез!

Шулай дип, кылычын шалт иттереп кынга тыкты да, мәйданга карап: «Шулай бит, җәмәгать? Шулай бит картлар?» дип кычкырды. — «Шулай мәслихәт, шулай!» дип картларның сакалы селкенеп алгач, «Каләме Шәриф[2] китерегез!» дип боерык бирде.

Каршы өйгә кеше йөгерттеләр. Бик тиз арада калын Коръән килеп җитте. Сабирҗан агай бисмилла әйтеп кулына алды. Нык-нык басып безнең каршыга килде. Очраклы бер җирен ачып, Коръәнне Һади абзыйга тоттырды.

— Укы, бер тынышыннан алып икенче тынышка тиклем. Кыскырып укы ла мәгънәһен бир!

Олы күз Һади абзый, белмим шул арада Коръәннең үзенә кирәкле бер җирен күреп өлгерде — бер аятен кычкырып укыды да шаулатып болай дип мәгънәсен бирде:

— «Сезгә залимнар ничек кенә явызлык итәргә тырышсалар да аларның эшләре барып чыкмас, сезгә әҗере генә булыр, алар алдашалар», диде. Мондый төбе белемсез, хәтәр эштә халык Коръәнгә бер төрле серле, хикмәтле фал әйбере итеп карап өйрәнгән. Инде Мәккә кафирләрен тиргәп әйткән мондый сүзләр килеп чыккач, үзләре дә шул кыяфәткә кергән бу кешеләр кинәт кенә тып-тын булып калдылар. Нинди каты чырайлы Сабирҗан агай, хәтта ул да сискәнде. Коръәнне Һади абзый кулыннан алып

[1] Бу урын Сабирҗан агай күрсәткән җирдән чынлап та ерак түгел, Мөсәт җирендә, әле дә «Аш биргән» атала.
[2] Каләме Шәриф — Коръән. Олылап әйтү.

минә тоттырды. «Укы шуннан», дип бармагы белән күрсәтте. Үзе күрсәтә, үзе минем укыганны күзәтеп бара. Билгеле, мин көйләп укымыйм, гарәпчә текст укып күрсәтәм. Ләкин аның бу хәреф күзәтеп торуы, бу цензурлыгы минем җенемне чыгара. Күзем чуарлана, бер хәрәкәсенең астынмы-өстенме ялгышам, хата җибәрәм. Янымда басып торган Сабирҗан агай үзе дә гарәпчә укымышлы икән, сизде каһәр, төзәтеп җибәрде, ләкин анысына бәйләнеп тормады, тынышка җиткәч:

— Үзегез дин таныган, укымышлы кешеләр, үзегез шул эштән көлеп, дин таптап йөрисез. Моннан болай кеше сүзенә карап, ата-баба юлын ташлап хур булып йөрмәгез. Ишеттегезме? Тәүбәгез шул булсын! дип Коръәнне кулымнан алды. Аннан:

— Барыгыз төшкән фатирыгызга! Беркая җибәрмәгез боларны! Аннары эшләрен үзебез күрербез! — дип, атына сикереп менде дә егетләре белән каядыр чабып китеп күздән дә юк булды.

Без тагын фатирыбызга юнәлдек. Егерменче гасырда нәкъ Мөхәммәт пәйгамбәр заманындагыча кылыч астында Коръән уку, дингә көчләү минем күңелемне бик каты рәнҗеткән, хөрриятемне мыскыл иткән иде. Мин Һади абзыйга моны әйтергә ашыктым:

— Ике саквояж китап төяп чыктык. Кешелек... Хөррият. Идеология, имеш! Менә сиңа нәкъ пәйгамбәр заманындагы кебек, кылыч белән көчләп яңадан кабул иттерелгән иске дин!

Һади абзый шуннан да арысын уйлап өлгергән, ахрысы, чуалган мыекларын тарткалап алды.

— Курыкма, — диде, — шулай халыкны үзенә кылыч белән ышандырырга калса, яңа идеология дә яңа керәшен дине оештырудан башкага ярамас...

Шулай гына дидеме, әллә бүтәнчәрәкме, бик үк хәтеремдә юк, һәрхәлдә, Һади абзый Толстоенны да җитәрлек укыган кеше, аннан да хәтәррәк йомры-йомры сүзләр ычкындырырга ярата иде. Ләкин мин аңа бу юлы эшне теориягә борып калдырырга бирмәдем, бөтен бу уңышсызлыкның ачуын хәзер аңардан алырга теләгәндәй үзенә ташландым:

— Синең бывщий мулла булуың хакына мин дә синең артыннан Мияшәгәр урамында Кәламе Шәриф укып күрсәтергә калдым, дидем.

Һади абзый олы күзләрен миңа күтәрде, үзе көлә:

— Син нәрсә, чынга алдыңмы әллә? Театр корды бит ул, — ди.

— Ничек театр?

— Соң сизмәдеңмени? Миңа бит ул «синең анаң Ташавыл кызы», диде. Ташавыллар — башкорт, минем инәкәй[1] Сафия да башкорт кызы лабаса. Ул бит шуның хакына, әти татар булса да, мине үтерми алып калырга булып килгән. Ә Коръән укыткан булуы — ансы безгә сәнәк тидермәс өчен. Ишеттең ич, халыкка безне сакларга дип кушып китүен? Менә шул, бу безнең өчен, безнең файдага ясалган эш, малай... Соң шулай булмаса, үзең уйлап кара: кылычлы-гаскәрле Сабирҗан агай сәгать буе безнең белән сөйләшеп торыр идемени!

Һади абзый шулай үзе өчен генә философ булып калмыйча, кешенең тел төбен сизәргә, фәлсәфәсен ачарга бик оста иде. Сабирҗан агайның килүе ул әйткәнчә булганмы-юкмы, ансын белмим, бу юлы да мин аның сүзенә шундук ышанып, үзем дә көлә башладым. Чөнки әйткәннәре бик мантыйкый һәм тапкыр булып тоелды.

Аннан да бигрәк миңа бу гарасатта башкортларның үзләрен тотышы кызык тоела иде. Сабирҗан агай бирегә бу башсыз сәнәкчеләр кебек түгел, асылда ул үз эшен бик белеп, бик аңлап, план белән хәрәкәт итә иде. Ул кылычын кыл кадәр генә усаллыкка тотса, командасы да коры башкисәрләр бандасы гына булса, ул бит хәзер монда теләсә нишли ала, дөнья аныкы иде. Хәлбуки мәйданны камап алган ялан кылычлы егетләре берни дәшми-кузгалмый, эшне башлыкларына тапшырган хәлдә тыптын тордылар. Бу исә башкорт хәрәкәте белән сәнәкчеләр хәрәкәте ике юлдагы нәрсәләр булуын күрсәтә булса кирәк.

...Икенче көнне тагын безне мәйдан уртасына тотып алып килделәр. Тагын безнең кулларны артка бәйләп кабык арбага салдылар. Бу юлы безне Аркавылга илтәбез дип алып киттеләр. Чөнки Һади абзый Аркавыл волостеныкы. Сикияз төрмәләре тулы булса, Һади Сәгъдине Аркавыллар анда үзләре карасыннар дип уйлаганнар, ахры.

[1] Инәкәй — анакай.

Безгә дә анда башкорт арасында яхшырак булыр кебек тоелды. Атау татарлары безне йолымга алырлар. Тик менә 20 чакрымлап юл барасы бар. Артыбыздан безне озатып сәнәкле ике сыбай килә. Аларга юлда ни эшләргә кушылгандыр, анысын бер шайтан да белми.

Шундый шомлы-хәтәр юлда без бер-беребезнең күзендә өмет чаткысы эзләп карашып бара торгач, авылдан чыгып күп тә китмәдек, артыбыздан атлы-мылтыклы чабар куып килеп җитте. Безне юлдан туктаттылар, борып Сикиязга, штабка алып барырга куштылар! Штаб!.. Бөтен өязне дәһшәткә салып канга батырган үлем учагы... Монсы тагын да шомлырак!

... Сикияз.

Авылга килеп кердек. Урысның нинди дини көне булгандыр, дулап чиркәү кагалар, урамда тәре походы... Корсагына көмеш чылбырлап тәре аскан поп аждаһа кебек ямьсез улап, кулындагы каделен ян-якка айкап, төтен пөскертә. Артында самогон эчеп шешенгән, жилет кесәсенә сәгать чылбыры аскан кып-кызыл мужиклар попка кушыла-кушыла улыйлар, әче тавышлы марҗалар нәрсәдер чыйныйлар, монда чын мәгънәсендә кулак тантана сөрә. Без олаучыларның атны тиз генә аралыкка боруларын үтендек, алла сакласын, бу җенле шайтан туена эләксән, Иисус хакына улап-улап, итең иткә, сөягең сөяккә ботарлап ташларга да бер тиен алмаслар...

Безне штабка китерделәр. Ниндидер мәктәп бинасымы, зур тәрәзәле яңа агач өй. Барлык китап һәм язмаларыбыз белән безне икенче катка менгезделәр. Тәрәзәсез почмакта, зур гына контор өстәле янында ике кеше күренә. Менә ул бөтен өязгә һәлакәт чәчкән үлем штабы! Менә аның геройлары! Белмим, баш каһарманнары сугыш мәйданына киткәнмеде, бу ике кеше бик шымыкый күренә. Өстәл артындагысы чәче коела башлаган, урта яшьләрдә, кызыл шешмә битле, җилкәсен чыгара төшкән, ул каядыр ашыккан, бераз каударланган кебек, һаман аяк өстендә килеш, куллары белән өстәлдәге ниндидер кәгазьләрне капшый, үзе безгә дә караган кебек. Артында гына ишек, ул анда да чыккалап керә, тагы өстәлгә килә. Ул берәр бывший земский чиновник, берәр террорист уң эсер булса кирәк. Икенчесе өстәлнең бер башында урындыкка аркасын терәп утырган, френч кигән, яшь, какча кеше. Монысы коры һәм хәрәкәтсез. Ул кузгалмый, чиста итекләрен алга сузып җибәргән. Кечкенә кансыз ябык йөзе, калайланган хәрәкәтсез күзләре бернәрсә дә тәгъбир итми. Казарма муштрасын үткән берәр авантюрист поручик кисәге һәм өстәвенә кокаинчы булса кирәк. Кулларын күкрәгенә көрмәкләп утырган килеш туп-туры һәм салкын гына безгә карап тора. Бәлки ул бу минутта үзе турында Наполеон Бонопарт булып күренәм дип уйлый булыр. Ул да бит башта поручик кына булган...

— Паспортыгыз! — диде.

Без документлар чыгарабыз. Аякта торганы ашыгып күз сала. Кенәгәсенә терки. Бүлмәдән тагын бер кеше керә. Безне тентиләр. Саквояжны ачалар. Чәчәләр. Урындыкта утырган теге мөгезсез тәкә кебек поручик үрелеп кенә безнең бер-ике китапны карый. Толстой. Бокль. (Аның «Англия цивилизациясе тарихы».) Бакунин... Хатха-Иога... Заратустра. Татарча китаплар... Язма дәфтәрләр... (Без кайбер революцион «хәтәр» китапларны Мияшәгәрдә Кара мулла өендә яшереп калдырырга өлгергән идек.) Әһәмиятсез генә бер якка ташлый. Артык күз дә салмый. Күрәсең, без юк идеяләр белән саташып, Россия тикле Россиядә сәнәк астында хакыйкать эзләп, эшкә мишәйт итеп йөрүче ниндидер хәтәр элементлар. Җитмәсә татарлар...

Әмма бу штабчылар, никтер, сүзгә бик саран‌нар. Юньләп сорашмыйлар да. Күзгә-күз очраудан качалар, сөйләшмәскә тырышалар. Без кем икәнлегебезне, нишләп йөрүебезне әйтәбез. Өстәл артындагысы килешкән булып башын кага, ләкин тыштан гына. Төбендә безгә ышану да, безне аңлау да күренми. Без аларга юлыбыздан тотарга хаклары юк икәнлекне, безне җибәрергә тиешләр икәнен әйтәбез. Алар дәшмиләр. Саквояжга китапларны ничек эләкте шулай салалар да аны ярты ачык килеш арткы бүлмәгә шудырып алып китәләр. Җәл. Аның шулай билгесезлеккә кереп югалуы кызганыч. Ул китаплар белән, аларда сызып-сызып укылган юллар белән бергә безнең дә кайбер уйларыбыз, кешелеккә булган хыялларыбыз билгесезлеккә китеп бара шикелле... Ишектән ялан кылычлы бер калын урыс керә. Урындыктагы теге поручик кулларын тагы күкрәгенә каушарып утырган. Тәкәббер генә коры тавыш белән:

— Уведи их, — ди.

Ялан кылычлы урыс безне урамга алып чыкты, артыннан барырга кушты. Ул бик калын, зур, төз гәүдәле. Өстендә тез башыннан куртка. Урамда кеше, хәрәкәт күп. Шулай да безне күрү белән әллә кайдан ук уртага ярылып юл бирәләр. Бирмәслек тә түгел: бу калын, төз буйлы кеше, нәкъ борынгы тәре сугышындагы христиан фанатигынча, изге бер дини гамәл үтәгән кыяфәттә, киң һәм төз кылычын тантаналы рәвештә туп-туры өскә төзәп, ике каш арасына тоткан, артыбыздан да каравыллар бар. Безне волость йортына китереп керттеләр. Бер якта баскыч, тимерле тәрәзә. Бүген самосуд беткән, димәк, безне теләсә кем, теләсә ничек уртага салып суймаячак... Ләкин шунда баскыч төбендә үк бүген төнлә туралган кешеләрнең каннары, җәзаланган гәүдәләре юньләп җыештырылмаган, шунда ук чәчелеп ята... Без аларга аяк очыбызны тидерми атларга тырышып үтеп зинданга кердек.

...Берничә көннән Һади абзыйның кулларын артка бәйләп Аркавыл волостена алып киттеләр. Аның урынына Пашка дигән бер рус егетен китереп яптылар. Башында артка яньчеп кигән казачи бүрек, өстендә уңа төшкән ыкчым гимнастерка. Кыяфәте нәкъ Чапаев! Мине күрде, ябык һәм бераз сипкелле йөзе аша малахит яшел күзләре белән елмаеп туп-туры карап торды, кул бирде. Таныш булып чыктык. Ул кайчандыр Мурашев имевьесендә ялчы малай булып эшләгәндә, Үзәндә бергә су кереп йөргәнбез икән. Унбер кеше яткан тыгыз сәкедә минем яннан урын алды. Төнлә колагыма пышылдап кына:

— Сезне Сикиязга беренче башлап китергәндә, тегермән янында атка менгән бер карт очрап, штаб исеменнән Мияшәгәргә кире кайтарырга кушты, исеңдәме? ди.

— Исемдә, — дим.

— Исеңдә булса, мәнә шул: анда бернинди штабның сезне кире борып кайтарырга кушканы юк иде. Ул вакыт мин шул тегермән астында качып ята идем. Карт — минем атай ул. Сезне Сикиязга китерәләр икәнне ишеткәч, картны юри ат мендереп мин чыгардым, сезне юри мин кире бордырттым. Чөнки ул көнне Сикиязда бернинди хөкем юк, китерелсәгез, сезне вәхшиләрчә тураклаган булалар иде, диде. Үзенең большевик икәнен, өяздә хәзер завод кызыл отрядлары белән сугыш баруын, хәзер безне суймыйча торулары заложниклыкка ярау ихтималыбыз булганга күрә икәнен әйтте. Шулай итеп Һади абзый белән без, кемнәр аркасында ничек үлемнән калуыбызны үзебез дә белмәстән, әллә ничә сәнәк җәпләре арасыннан үтеп йөри биргәнбез икән.

...Тимер челтәрле тәрәзә артында, каравыл астында, кулы артка бәйле бер кыз үтте. Аның йөзе коточкыч: адәм карагысыз шеш тә кутыр. Пашка аның белән күз ишарәсе ясап кына исәнләште.

— Бу безнең Лида, — диде ул. — Счетовод. Большевичка. Аны кыйнап терели килеш җиргә күмгәннәр. Ул мәнә үлмәгән, төнлә туфракны тырнаклары белән казып гүрдән чыккан. Ну кыз!

...Бер көнне мине тыштан чакырган тавыш ишетелде. Мин килеп тимер тәрәзә аша карагач, каршымда басып торган әти белән Зыятдин бабайны күрдем. Әтинең өстендә үзе тегеп кигән карасу бишмәт, башында сайрак кара илтер бүрек, бичара, гадәтенчә, үзенә хөрмәт саклаган кебек миңа да угыллык хөрмәте күрсәтеп, аз гына башын игән хәлдә карап тора. Зыятдин бабай (яшь әнием Зәкиянең атасы) какча буе белән аның янында озаеп басып, минем күңелне күтәрү өчен, гадәтенчә, күңеллерәк берәр сүз кыстырып, башын артка каккалап куя. Ләкин күңелле хәбәр юк. Әти мине порукага алырга килсә дә, штаб бирми, авылыгыз приговор ясап сорасын, ди икән. Малаязлар — Нәкый читтә эшләгәч без аны большевик та, түгел дип тә әйтә алмыйбыз, белмибез, диешеп приговор бирмәгәннәр. Белми түгел, анда мине белгән, сорарга иткән кешеләр аз түгел икән дә, сәнәкчеләр хәзер ул эшкә юл бирми, ди. Бигрәк тә анда, безнең волостьта, канлы сугышлар бара икән... Бөтен өяз хәзер сәнәкчеләр кулында, ди. Тәрәзә аша барын да сөйләп булмый.

Каравыллар «Кончай, кончай» дип торалар. Картлар кечерәк кучтәнәч төенчекләрен тапшыртып, саубуллашып китеп баралар.

...Мин Сикияз төрмәсендә ике атна яттым. Кытаутамак заводыннан Тарасов командасында килгән эшче отрядлар безне үлем кочагыннан коткарды. Мин Малаязга кайттым.

Монда кайтсам, күргәннәрем кечкенә бер эш булып калды. Бәләнең зурысы минем туганнар башында: әниенең Нисебаштагы бертуган энесе коммунист Шаяхмәт абзыйны

сәнәкче Куркин урыслары ташлар белән бәреп үтереп, Йорүзәнгә салганнар. Икенче бертуган энесе коммунист кызыл гвардияче Сәгыйт абзыйны шул ук Куркиннар ат янына бәйләп Сикиязга хәтле кыйнап алып килгәч, мине ябып яткыручы штаб аны чокыр башына чыгарып аттырган булып чыкты. Әниемнең абзыйсы «кызыл мулла» Шакирҗан бабайны бәйләп илтеп Кыйгы төрмәсенә салганнар, волость җир бүлегендә эшләүче Рәхимҗан җизнине Залтауыс төрмәсенә озатканнар. Соңыннан аны үлем эшелонына утыртып алып китеп юк иткәннәр. Волревком Миңлеәхмәт җизни көч-хәл белән урманга качкан, аннан ул Кытаутамакка барып җитеп, өяздәге хәлләрне завод комитетына мәгълүм иткән, анда әлеге Тарасов командасында 150 кешедән гыйбарәт кораллы эшче отряд төзеп, алар Нисебашны яңадан килеп алганнар. Аларның халыкны үгетләп, ашау-эчү, ял итү өчен өйләргә таралуы булган, шул араның эчендә тирә-яктан 17 авыл сәнәкчеләре Нисебашны бердән килеп басып, авылга ут салганнар. Авыл эчендә зур канлы сугыш купкан. Ахырында сәнәкчеләр мәетләрен калдырып, пулемет-мылтык уты астында чигенеп качарга мәҗбүр булганнар. Шул һәлакәтле сәнәк вакыйгаларында Нисебашның агроном Һади Исмәгыйлов, Таһир Габделлатыйповлар революция өчен каһарманнарча корбан булганнар, бер Нисебашның үзеннән генә унбишләп большевик үтерелгән булып чыкты [1]. Бөтен өяздә, Кыйгы, Ылаклы, Атау кебек зур авылларда йөзләрчә революционер, нык большевик татар егетләре һәлак ителгән иде. Атауның куркусыз большевигы Зәбих һәм Мөхәммәтшиннары, Ылаклының мәшһүр Хамматовлары да шул канлы һәлакәттә корбан булганнар.

... Мин бу хәлләрдән айнып авылыбызда бераз баш-күз алырга да өлгермәдем, Чиләбедән купкан чех-словаклар безнең өяз үзәге Залтауысны басып алды. Алар тимер юл сызыгы белән Өфегә таба хәрәкәт итә башладылар. Икенче яктан Өфегә чехлар Самардан киләләр иде. Әле генә коточкыч сәнәк явыннан арынган өязебезгә инде интервенция һәм Антанта көченә таянган аклар хакимияте урынлаша башлады. Сәнәк явыннан очраклы котылган кешеләр, фәкыйрьләр качып-посып ындыр-урман арасына киттеләр, партизанга әйләнделәр. Кызыл мулла Шакирҗан бабай салам асларында посып яши, ул салам өемнәрен сәнәкләр белән чәнчеп-чәнчеп аны эзлиләр, бабай «алла кодрәте белән», ничектер, шул сәнәк җәпләре араларында әлегә исән калып килә иде. Шулай итеп туган абзыйлар, җизниләр һәлакәтеннән соң, елашып, апалар белән балалар калган, мин исә совет матбугатында язышкан һәм сәнәкчеләр төрмәсеннән кызыллар кулы белән генә чыгарылган кеше булгач, акларның күз өстендә сөял булып, аптырап ята идем.

Шундый көннәрнең берсендә безнең өйгә Пашка белән бер кыз килеп керде. Икесе дә мылтык асканнар. Гаскәри формада. Пашканың кыяфәт бөтенләй Чапаевча. Кыз шулкадәр чибәр, йөзе яңа туып килгән таң кебек алсу балкый, күзеңне алалмассың.

— Таныйсыңмы? — ди Пашка, үзе көлә, — күргән идең бит, теге вакытны төрмә тәрәзәсе алдыннан үтеп киткәнен? Бу шул кыз, — ди.

Күзләремә ышаныйммы икән, бу шул тере килеш күмелеп, гүр ярып чыккан Лида! Моннан өч атна элек кенә тапталып — яньчелеп бетсән бу коточкыч ямьсез йөзнең, ләкин яшь йөзнең шулкадәр тиз төзәлүенә, шулкадәр нәфис матурлануына мин ни әйтергә дә белмичә аптырап калдым. Менә алар хәзер икесе дә өйләнешкәннәр, икәүләшеп мылтык тагып сугышка барырга чыкканнар. Интервенциягә каршы... Мин тагын гаҗәпләндем:

— Сез нәрсә? Шулай икәүдән икәү чехсловак корпусына каршы тормакчы буласызмы әллә? — дим.

— Ә без моннан Миньяр заводына чыгабыз, анда безнең ишеләр күп булыр әле. Син үзең ни уйлыйсың? — ди Пашка.

Алар ашап-эчеп күп тә ял итмәделәр, юлга ашыктылар. Мин аларны бераз озата бардым. Яхшы теләкләр әйтеп аерылыштык.

Мин калдым.

Миньяр дигәне моннан 40 чакрым җир. Безнеңчә, Көрәк заводы. Шулай итеп мин Көрәккә китмәсәм дә, аңа карап мин монда «Сәнәк» җәпләре арасында да утырып

---

[1] Нисебашта аларга һәйкәл куелган, башка авылларда куелганмы-юкмы, белмәдем.

кала алмыйм бит әле. Шунлыктан бу мәсьәлә һаман үзенең очлы җәпләре белән минем кабыргага төртеп торуында дәвам итте. Ул минем каршыма икенең бөре булып басты.

Сәнәкме, Көрәкме?

Бу сорау бер минем башта гына туган эшме? Бала чакта уйнаганда да шулай бит: ике малай парлашып, берең «Сәнәк», берең «Көрәк» булып, ике атаман алдына килә-сең дә «Сәнәкме, Көрәкме» дип үзеңне тәкъдим итәсең. Ике атаман шул ике исемнән берсен әйтеп, һәрберебезне үз ягына сайлап ала. Шуннан без малайлар ике партия — ике лагерь булып бүленеп алабыз, менә бер заман бер-беребезгә каршы туп белән бәреш тә куыш китә! Атаманның ике булуы да яхшы. Бер генә булса, сайлау да булмас, сайлау булмаган җирдә безгә андый уен да, ирек ачу да булмас иде. «Бер»нең исеен сайлыйсың? «Бер» ул «алла» гына була. Аны кем сайлаган? Ул — абсолют. Хәер, алла да үзенең аллалыгында бөтенләй тынып-катып калмас өчен, бу хәлennән чыгып хәрәкәткә килү, үз иркен — ихтыярын күрсәтү өчен, үзенә каршы Иблисне бар иткән, ди бит. Аны әнә бывший мулла һади абзый әйтә. Белмим, Коръәннән алып сөйләве, белмим, һегел белән Гетедән. Күрәсең, анынча, хәтта алла хөкеме дип куелган абсолют дини законда адәм балаларына икенең берсен сайларга ирек куелган. Ягъни, кайсына иярсәң дә дөньяда үз ихтыярың. Сиңа ирек. Ә калганы? Калганы теге дөньяда, җаным. Аксын индә анда карарбыз... Янадан кубарылгач...

Балачак үтте. Менә бу «Сәнәкме, Көрәкме»нең уены бетте, чыны башланды. Тукта, язгы өзекләрдә авылдан эшкә китеп, абзыйлары белән Көрәккә барып «курин кискән» Минһаҗ дус бар, аның кылын тартып карыйм әле.

Минһаҗ, Зәкия тәтәйнең энесе, күршедә генә. Кердем. Тальян тартып утыра.

— Әйдә, — мин әйтәм, — Көрәккә киттек. Күрәсең мондагы хәлләрне...

Мин сөйлим, ул уйный. Шулай уйнады-уйнады да гармунын куйды.

— Юк,— ди,— бармыйм мин Көрәккә. Алар әлектән дә безнең крәстиянга гыйбатлар дип кенә карарга өйрәнгәннәр; авыл кешесен мыскыл итәргә яратучан халык. Үзләренең күбесендә менә диган йорт, арт бакча, сыер... Ни эшче, ни крәстиян дигәндәй. Кем булганнар диерсең... Син Сикияз төрмәсендә ятканда, алар монда, бу тирәдә ни эшләп киттеләр, белмисең бит әле.

Сөйләп тә бирде. Сәнәкчеләргә каршы Көрәк заводыннан җыентык һәм юньләп өйрәтелмәгән дә бер команда Үзән буйлап төшкән дә, фетнә бастырабыз дип, башкорт авылларын яндырып, талап бара башлаганнар. Әби патша заманындагы каратель-ләрмени! Без теге вакыт паромында чыккан Илтәйдә башкортларның ирләре генә түгел, җан саклау өчен, хәтта хатыннары да балталар тотып каршы сугышканнар. Җан газиз.

Билгеле, мондый гомуми суешта сыйнфый аерма да, интернационализм да саклана алмый. Сәнәккә каршы Көрәк... Үзләре дини, милли яктан да башка халыклар. Минһаҗ безнең авылның аңлы яшьләреннән, бу хәлгә чиылап борчылуын әйтте:

— Җитмәсә бит,— ди,— шушы хәлләр өстенә тегеннән әнә чехлар килеп ята. Һич тә эшче-крәстиян дуслыгын ныгытуга алып бармый бу!

Мин:

— Революциядә андый аңлашылмаулар була, автономияләр мәсьәләсендә бу көрәкләр аңлап җиткермиләр, күрәсең. Әнә шул бөек державачылык шовинизмының иң хәтәрлеге турында Ленинның нык кисәтүләре бушка түгел, — дип, Минһажның кәефен бераз йомшартырга тырыштым.

Ул кулын гына селекте.

— Аларга синең милли азатлыгың ни? Хаким милләт өчен аның кирәге дә юк. Ул мәсьәләдә алар үзләре патша заманнарыннан бирле азат ич.

Билгеле, монда Сәнәктә дә, Көрәктә дә гаеп бар. Әмма ләкин төп җирле халыкларның милли хокукларын, автономияләрен танымаска тырышу һәм аларга каршы репрессияләр алып бару ул вакытта шактый киң урын алган типик күренеш иде. Эшнең бу җитди ягына да аз гына тукталыйк. Хәтта регуляр Кызыл Армия командирлары арасында да «Россия бернинди автономиягә бүленмәс, ул бөтен булырга тиеш!» диган бөек державачылык тезисе белән эш итүчеләр булуы мәгълүм хәл. Мәсәлән, 1919 елның 3 июлендә Көнчыгыш фронтының Көньяк төркеме Реввоенсоветы тарафыннан В. Куйбышев имзасы белән чыгарылган боерыкта төп җирле милләтләргә, мәсәлән, башкортларга, каршы шундый репрессия алып баручы командирларга карата

кискен кисәтүләр ясала. Анда шушындый сүзләр әйтелә: «...Башкортларга һәм аларның вәкилләренә карата ышанмау һәм шикләнеп карау политикасын үткәрә башладылар... Ә тыныч башкорт халкына каршы берничек тә аклап булмый торган репрессия белән дошманлык мөнәсәбәте тудырдылар... Кызыл Армия эченә үтеп кергән бу «явыз җинаятьче элементлар», җәзага тартылганга кадәр байтак ерткычлык эшләп өлгерделәр: алар кылган һәртөрле «мыскыл итүләр, мәсхәрәләүләр соңында башкорт солдатларын һәм аларның җитәкчеләрен, совет яклы кешеләрне масса төстә атулар итте... Революциягә хыянәт итүчеләр тарафыннан Башкортстанның революцион эшлеклеләре, шагыйрьләре, художниклары атылдылар» [1].

Бездәге бу «сәнәк-көрәк» вакыйгаларыннан соң, бер ел да үтми, Преображенский заводы отрядлары тарафыннан Шәйхзадә Бабичның үтерелгәнен ишеткәч, мин аның да нәкъ шундый «революция ясаучылар» хөкеме буенча корбан ителүен аңладым [2].

... Әйе... Менә ул сиңа Сәнәк тә Көрәк!

Мин шул дилемма алдында калдым. Минем башымны ул көннәрдә дә бу бик нык мәшгуль итте. Авылда — Сәнәктә дә калмыйм, Көрәккә дә бармыйм. Бара алмыйм. Мин бер мәгърифәтче татар мөгаллиме. Шагыйрь... Мин Көрәккә нәрсәгә кирәк? Анда барып та нишләрмен?

Юк, яшь булсам да, минем үз аңым бар. Мин һәр сәнәккә җәп була алмаган кебек, һәр көрәккә сап булып та йөри алмыйм. Мин үз ышанычыма туры кеше, иреклe кеше. Миңа үз җәмгыятем, үз мәйданым, үз мөхитем кирәк! Мин язучы! Кайда, бармы шул җир? Калдымы шундый җир? Булырга тиеш ул!

...Киттем. Аркага капчык астым да җәяү шул җирне эзләп киттем. Бездән утыз чакрымда тимер юл станциясе, шунда килдем. Ниндидер ватык кызыл вагоннар тезмәсе, бер состав тора. Тимер юлның йөз чакрыммы, аннан артыкмы бер өзеге әле аклар кулында түгел. Состав кузгала... Мин дә бер вагон баскычын чамалап, сикереп асылындым.

Әкияттәгечә түгел, акрын бара. Озак бара. Туктый. Менә бер станция. Укыйм: — Миньяр! Бу шул — әлеге Көрәк!

Мин аны үтеп киттем. Ике көнме баргач, поезд алла кодрәте белән мине Өфегә китереп җиткезде.

...Өфе. Ул чагындагы Өфе. Иарапби, андагы гүзәллек! Өфе дигәч, аның ул чагындагы ул матурлыклары хакына бер авыз сүз әйтми үтәргә мөмкинме? Аңа минем хакым бармы?

Яңа Өфе бу вакыт минем өчен үзенең мәһабәт тау башлары, төпсез серле чокырлары, әйләнә-тирәсен урап аккан ямьле Агыйдел, Карандел, Димнәре белән генә түгел, минем өчен иң элек ул үзенең кешеләре, яшьләре белән, шуларның урам тулып күперелеп агып торулары белән матур. Әйтеп ышанмассыз, кая карама, безнең яшьләр: кыйммәте бер җәүһәр-байлыклар белән дә алмашынмый торган гөлдәй кызлар, уттай егетләр. Кая карама — шуларның балкыган йөзе каршы ала. Юк, алар шулай кәязкәяз басып йөрсәләр дә, үз кыйммәтләрен үзләре дә белеп бетермиләр булыр...

Әнә авыл шикелле берәр генә катлы өйләр арасында, йөк арбасы йөрткән Ломовойлар урамында, Хәсәния җәдит мәдрәсәсе. Ул мин укыган, кичә генә сәнәкчеләр кулында үтерелгән Сәгыйт абзыем укыган, Әхмәт Хәбиби [3], Әхмәт Фәйзиләр укыган изге йорт. Әнә Өфенең теге башында күренеп торган данлы Галиясе, бу башында Госмания мәдрәсәләре. Дарелмөгаллимат... Әллә нихәтле ирләр, кызлар мәктәбе... Менә хәзер җәй көне алар урынына педагогия курслары киткән. Каян бу кадәр татар яшьләре. Бөтен Өфе шулар белән тулган. Бөтен Россиядән. Мондагы күңеллелек, рух күтәренкелеге! Кичә генә рус империалистлары сәясәте белән ябылып, куылып, погром астында тотылган җәдит мәктәп-мәдрәсәләренең буасы бүген ничек җырылып киткәнен

[1] Бу документ Ә. Харисов мәкаләсендә китерелгән буенча алынды. «Ш. Бабич, Һайланма әсәрләр», Өфе, 1958.

[2] Ә менә Тарасов командасында Кытаутамак заводыннан чыгып сәнәкчеләрне бастырырга килгән эшче отрядлар турында андый сүз әйтеп булмый. Алар кирәк урынында корал кулланса лар да, крәстиән белән мөмкин кадәр сак, аңлашып эш итеп, үз маршрутларында Советларны яңадан торгыздылар. Н. И.

[3] Әхмәт Хәбиби — Өфедәге 17 нче елның августыннан татар большевиклары органы «Алга» газетасын чыгаручы.

монда күрәсең. Курслар! Курслар! Бүген монда бар да җыр, мандолин да скрипка! Бүген монда бар да шигырь, гыйлем дә уку! Шушы яшьләр бар да иртәгә мөгаллим-мөгаллимә буласы! Аларның үз милли мәктәпләре хөкүмәт хисабыннан булачак! Менә Ленин нишләттерә! Менә безнең Халык Комиссарлары ничек эшли!

Ә монда һәвәскәр концертлар, бу курсларда уздырылган төрле матур кичәләр? Булса да булыр, әмма мондагы кадәр грандиоз кичәләрне мин шуңа хәтле дә, шуннан соң да беркая да күрмәдем. Әмма ләкин шушы кадәр зур мәһабәт яшәешнең гармониясен бозган бер генә ялгыш нота да юк! Шунсы гаҗәп, бер генә дә исерек, мәҗлесне бозган бер генә дә хулиган, бер генә дә җәнҗал, тәрәзә вату юк! Хәтта милиция дә күренми! Бәлки бусы да Ленинның социализмны аракы сәүдәсе хисабына корудан баш тартып, кабакларны яптыруы белән бәйле бер нәрсәдер. Бу вакыт рус халкы да җырында инде шуны әйтеп җырлый бит:

Царь Николашка вином торговал,
Гришка Распутин на скрипке играл...

Өфенең ул чагындагы бу һәм башкача да гүзәллеге миндә шулхәтле матур хатирәләр калдырган ки, мин ул хакта болай аяк өсте үтешли генә барын да сөйли алмам.

Өфе бу вакыт татар яшьләренең кайнап торган мәгърифәт учагы, безнең өчен бер мәдәният шәһәре. Хөррият шәһәре!

...Өфе менә шул. Бүген аның бөтен тирә-ягы ут. Үлеш тә кырылыш, гарасат. Шулар уртасында утрау булып күперелеп, татар мәгърифәт кояшы булып балкып Өфе тора. Ленинчылар кулы белән кабызылган ул мәгърифәт нурларын кем сүндерә алыр! Менә мин хәзер шул Өфедә, шул балкыган Дарелмөгаллиматта. Әнә ул безнең сөекле шагыйребез, талантлы Шәйхзадәбез. Ул юлга ашыгуын белдереп, кулын кулга учлап күтәреп барыбыз белән бер юлы исәнләште дә ниндидер бер гаскәри һәм башка иптәшләре белән ишеккә юнәлде. Мин кешеләрне ерып артыннан бара башласам да, булмады. Артыннан куа чыксам, җиткән дә булыр идем. Чыкмадым. Хәер, тагы туры килер, күрешербез әле, дидем. Менә яшьлекнең иң зур хатасы! Күрәсең, ул чакта алда бер бетмәс гомер бар, күңел үлемгә ышанмый, бары яшәүгә генә ышана. Һәй, дисең, тагын бер туры килер, бер генә түгел, әллә ничә кат очрашырбыз әле кебек тоела. Юк икән. Исереккә генә үз башының әйләнүе дөнья әйләнү булып күренә икән, шуңа күрә ул өенә кайтмый талпынып басып тора, өе әйләнеп килеп җитәр, керермен, дип көтә икән. Мин дә, күрәсең, ул чагында исерек булганмын; аракыдан түгел, билгеле, мин ансыз шәбрәк исерек. Яшьлек исереклеге, ирек исереклеге, шигырь исереклеге, гыйшык... Шул әйләндергән минем башымны. Кеше китә икән китә бирсен, юлыннан тотма, дөнья тагын әйләнеп бер килер, очрашырбыз дип, уйлаганмын.

Мин ут эченнән чыгып, бөтен җирем төтәп торган килеш матур яшьләр Өфесенә килеп, дуслар кочагына килеп егылсам, Шәйхзадә шул Өфедән каядыр башкорт арасына, Уралга, үз стихиясе ут эченә китеп югалды.

Ул заманнарда алланың кеме юк иде, авызларында нинди-нинди генә догмалар юк иде. «Татардан пәйгамбәр булмый, аның иманы үз теленда була алмый, булмаган; Коръән — иман безгә гарәп телендә ингән» дип йөрүчеләр дә бар иде. Бабич нәкъ шундый ачык авызларга үзенең бик тере, мәсхәрәле күзләре белән карап, татарча итеп:

Салкын гакылың
Үзеңә булсын,
Тимә күңлемә!
Үземдә торсын.

. . . . . . . .

Иманым — үзем,
Коръәнем — сүзем!

дип үз теленнән үз аять сүзен әйтте дә, үз язмышын үзе билгеләүче булып, кылдан нечкә, кылычтан үткен фаҗигале галәм күперенә менеп күздән югалды. Без артык очраша алмадык.

**Азиз Шәриф,**
әдәбият галиме, профессор

# ТУКАЙ ҺӘМ ӘЗЕРБӘЙҖАН ӘДӘБИЯТЫ[1]

Тукай һәм әзербәйҗан әдәбияты... Шушы зур һәм актуаль тема өйрәнелми ята. Ни өчендер, ул татар галимнәрен дә артык кызыксындырмый, безнекеләрнең дә аңа кулы җитми. Хәлбуки, бөек татар шагыйре иҗатын әзербәйҗан язучылары иҗаты, 1905 елгы революциядән соң Әзербәйҗанда җанланып киткән әдәби хәрәкәт белән бәйләп өйрәнгәндә, кыйммәтле ачышлар ясарга, Тукай мирасының әлегә билгесез күп кенә якларын ачыкларга мөмкин булыр иде.

Беренче рус революциясе көннәрендә Кавказда «Мулла Насретдин» исемле сатирик журнал чыга башлый. Революцион-демократик рухтагы бу журнал тормыштагы һәртөрле искелеккә каршы кискен көрәш ача, мәдәният һәм фән казанышларын пропагандалый, халыкны бәйсезлеккә, азатлыкка өнди. «Мулла Насретдин»ның горур тавышы бөтен Кавказ артына тарала, Идел буйларына килеп җитә, татар егетләренә дә ишетелә.

Хәер, бу аңлашыла да. Ике халыкның — татар һәм әзербәйҗан халыкларының — тормышында, язмышларында күп уртак яклар булган. Язмышлар уртаклыгы исә теләкомтылышлар уртаклыгына китергән. Шуңа да һәр ике халыкның алдынгы уллары бер үк сүзләрне сөйләгәннәр, бер үк идеяләр өчен көрәшкәннәр. Мәсьәләнең шул якларын күздә тотып фикер йөртсәк, «Мулла Насретдин» журналы тирәсенә тупланган әзербәйҗан язучылары, аеруча ялкынлы сатирик Сабир (1862—1911) һәм бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатлары арасындагы якынлык тагын да тирәнрәк аңлашылачак, мәгънәлерәк күренәчәк.

Бу ике бөек шагыйрьнең биографияләренә кадәр охшаш. Дөрес, Сабир үзенең каләмдәш дустыннан 24 яшькә олырак. Әмма әдәбият мәйданына алар бер үк чорда — 1905 елгы революция көннәрендә килеп керәләр. Нәкъ шул елда Тукай «Хөррият хакында» исемле шигырен яза. Сабир иҗтимагый-политик эчтәлекле беренче мөһим әсәрен — «Бәйнәлмиләл» исемле шигырен бастырып чыгара. Анда ул әрмән һәм әзербәйҗан халыкларын үзара татулашырга, дуслашырга өнди.

Менә шул шигырьнең соңгы юллары:

Илгә хаклыкны сөйләп, ташлыйк түбәнлекләрне без!
Һәм кояштай нур сибеп, таптыйк кара төннәрне без!
Күрсәтик гайрәт бу данлы, изге юлда һәммәбез!
Калмасын иске низаглардан күңелдә һичбер эз!

---

[1] Мәкалә бераз кыскартылып басыла.

Бар халык тату яшәп, дуслыкта үтсен гомеребез!
И Сабир! Күреп чара, тизрәк күрик шул көнне без!
И гүзәл сүз остасы, ак юлга әйдәү вакты бу!
Бар кешелек дөньясын дуслыкка өндәү вакты бу! [1]

Әгәр Сабир шигырен Тукайның «Хөррият хакында», «Гыйлемнәр бакчасында...» исемле әсәрләре белән чагыштырып карасак, без ике шагыйрьнең мәдәният, мәгърифәт мәсьәләләренә карашлары да, халык язмышы, әдипнең халык алдындагы бурычы турындагы уйлануları да охшаш булуын күрербез.

Тукайның беренче шигыреннән бәләкәй генә өзек:

Барча цензур ябылгач,
Дәрткә дәрман табылгач,
Кызыл кара ясаган
Кярханәләр бөлдия.

Күп яшь егетләр үлде,
Мәетләр дөнья тулды,
Намнары бакый булды
Та кыямәт тидия...

Хәзер Тукайның икенче шигыреннән дә бер мисал алыйк. Анда яңгыраган мотивлар соңрак һәр ике шагыйрь иҗатында еш кабатлана.

Шөкер улсын, уянып тордылар әүлятлары гасрын,
Безез әсхабы, әуляды бу гасры мәгърифәт хасрын.
Сарылды милләтең яшь каһраманнары каләмнәргә:
Мәхәл вармы борынгыдай хәзән, хәсрәт, әләмнәргә? [2]

Беренче шигырьләре басылуга барлы-юклы бер ел гомер уза. Һәм шул бер ел вакыт эчендә аларның иҗаты танымаслык булып үзгәрә. 1906 елда инде алар үз халыкларының гына түгел, бик күп мөселман халыкларының да мәхәббәтен һәм ихтирамын яулыйлар. Ике шагыйрьнең дә шуннан соңгы иҗат гомере артык кыска булып чыга. Тукай нибары җиде ел иҗат итеп кала — 1913 елның апрелендә үпкә авыруыннан үлә. Сабир үзенең үлемсез әсәрләрен тагын да кыскарак срокта — биш ел эчендә яза һәм илле яше дә тулмаган килеш вафат була.

Күрәсез, шәхси тормышлары һәм язмышлары белән дә, иҗатларының характерлары белән дә алар бер-берсенә бик якыннар. Болай алар бервакытта да очрашмаганнар. Әмма шагыйрь буларак, бер-берсен белгәннәр, бер-берсен укыганнар. Бу кадәресен генә шикләнмичә әйтергә мөмкин. Тарих безгә бу хакта сөйли торган дәлилләр дә калдырган. Сабирның кайбер шигырьләрен Тукай татар теленә тәрҗемә иткән (мәсәлән, «Шикаять» исемле сатирик әсәрен). Тбилисида чыккан «Мулла Насретдин» белән Казанда чыккан «Яшен», «Ялт-Йолт» журналлары арасында ниндидер бәйләнеш булганлыгына да шикләнү урынсыз. Мин ышанам: әгәр кем дә булса әлеге басмаларын җентекләп тикшереп чыкса, ул кеше, журналлар арасындагы рухи якынлыкны ачыклау белән бергә, уртак материалларга, бер журнал икенчесеннән күчереп баскан төрле әсәрләргә дә юлыгачак.

Китерелгән дәлилләргә таянып, шуны әйтергә мөмкин: татар әдәбияты белән әзербәйҗан әдәбияты арасындагы, Габдулла Тукай белән Сабир, Җәлил Мәмәдкули-задә кебек әзербәйҗан язучылары арасындагы бәйләнешләр без уйлаганнан күп тирәнрәк булган. Бу бәйләнешне, бу уртаклыкны, бу бердәмлекне Тукай һәм Сабир күтәргән иҗтимагый мәсьәләләргә бәйләп тикшерү кулайрак булыр шикелле. Тукай халкына булган чиксез мәхәббәтен менә нинди ялкынлы юлларда белдерә:

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаит, милләтем;
Сыйххәтеңдер — сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер — гыйлләтем.

Сән мөкатдәс, мөхтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән;
Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем.

---

[1] Сабирның барлык шигырьләрен һәм Ж. Мәмәдкули-задәнең бер шигырен әзербәйҗан теленнән Әхмәт Исхак тәрҗемә итте.

[2] Шигырьнең хәзерге телгә юлга-юл күчермәсе:

Шөкерләр булсын, гасырыбызның яшьләре уянып тордылар.
Без — бу мәгърифәт гасыры сараеның балалары һәм ияләребез.
Милләтнең яшь каһарманнары каләмгә сарылдылар:
Элеккечә кайгы-хәсрәт һәм ачынуларга урын бармы хәзер?

...Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы ламәхаль;
Бу хыялаттан кәлер, гәр кәлсә мәҗнүниятем.

Халыкка тирән мәхәббәт хисләре белән сугарылган шундый ук ялкынлы юлларны «Мулла Насретдин» журналында да очратабыз:

Милләт күпме таланса да, минем ни эшем бар?!
Дошманнарга баш орса да, минем ни эшем бар?!
Ватанның уллары эшсез һәм чарасыз калсын,
Хурлык, түбәнлек баткагы үз эченә алсын,
Тол аналар, хәер сорап, ут эчендә янсын,
Фәкать минем дан, шөһрәтем һаман үсә барсын!

Милләт күпме таланса да, минем ни эшем бар?!
Дошманнарга баш орса да, минем ни эшем бар?! [1]

Жанрлары ягыннан аерылсалар да, аларның һәр икесе бер үк 1906 елда язылган, һәр икесенең рухы, яңгырашы бер. һәр ике шагыйрь бер үк нәрсә турында сөйлиләр, бер үк идеяләрне үткәрәләр. Дөрес, һәрберсе үзенчә сөйли, һәрберсе үз манерында, үз стилендә яза. Әгәр уртак идеяле ул шигырьләрне стильләре ягыннан детальләп, җентекләп тикшерергә тотынсак, һәр әсәрнең үзенә генә хас гаҗәеп күп шигъри бизәкләрен, поэтик интонацияләрен табар идек.

Шушы фикерне конкрет мисалларда исбатлау йөзеннән, Тукай белән Сабирның охшаш проблемаларга, бер үк мәсьәләләргә багышланган кайбер шигырьләрен чагыштырып карыйк. «Сорыкортларга» (1906) исемле шигырендә Тукай болай ди:

Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев, вастрок бар бит;
Куярлар астырып дарга, ятып тор бер дә кузгалмай.

Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмый;
Нидәндер җаннарым бу куркулардан бер дә сызланмай.

Хәзер шул юлларны Сабирның «Булмый» (1907) исемле шигыре белән чагыштырыгыз.

Дәшмә, беркемгә бер сүз әйтмә, диләр,
Хак сүзне мин әйтми үтә алмыймын.
Күз күргәндә, исән чакта акылым,
Кояшка «Янма!» дип әйтә алмыймын.
...Үлсәң үл, юкка көчең түкмә, диләр,
Дөреслек юлын мин тиеш табарга, —
Шул юлдан мин читкә китә алмыймын!

Мин югарыда китерелгән өзекләргә тәфсыйллы анализ ясарга җыенмыйм. Болай эшләү мәкаләнең күләмен артык киңәйтер иде. Детальләп өйрәнүгә яшь галимнәр алынырлар һәм татар әдәбияты белән әзербәйҗан әдәбияты, Тукай белән Сабир иҗатлары арасындагы бәйләнешләрне, уртак моментларны ныграк, тирәнрәк ачарлар дип уйлыйм.

Хәзер, бераз алгарак китеп, Тукай белән Сабирның ислам диненә, мөселман руханиларына багышланган әсәрләренә күз салыйк. Дөресен әйтергә кирәк, шагыйрьләрнең берсе дә коеп куйган атеист түгел. Тик сез аларның мөселман руханиларын фаш иткән әсәрләренә карагыз: күпме нәфрәт, ачу хисе аларда. Әле 1906 елда ук, муллаларга мөрәҗәгать итеп, Тукай болай язган иде.

Итеп мәсҗетләрн базар, гавамә саттыңыз әгъмаль;
Сатып гокбал дөньяя, хәкыйкать улдыңыз бәккаль.

Сезең әуладыңыз сездән хәрыйслык алдылар мирас;
Ала карга кеби, сез җифәләргә улдыңыз дәллаль.

---

[1] Күпләр бу шигырьнең авторы Сабир дип уйлыйлар. Безнең уебызча, аны «Мулла Насретдин» журналының редакторы Җәлил Мәмәдкули-задә язган булырга тиеш. *А. Ш.*

...Халыкны аздырып, яшь каһарманнардан итеп бизар,
Аларны кұстәреп динсез, ниһаять улдыныз дәҗҗал.

Ике елдан шундый ук рухтагы шигырьне Сабир да иҗат итә. Менә аның кайбер юллары:

Дингә өндисең илне, малың өчен,
Хәтәр туфан ул динең, изге ата!

Эшең күңелендәй кара — буяу сөртеп,
Агармас күңелең синең, изге ата!

Акча китермәсә намаз-ураза,
Аңа төкерер идең, изге ата!

Бу шигырьләрне янәшә куеп карау җитә. Уртак идея, уртак фикерләр, хәтта бер төрлерәк әдәби сурәтләү чаралары. Ә бит алар, әгәр шулай әйтергә яраса, дөньяның төрле почмакларында, төрле елларда, төрле телләрдә, һәрберсенең үз шәхси йөзе, үз стиле булган ике мөстәкыйль шагыйрь тарафыннан иҗат ителгәннәр. Шул ук вакытта иҗтимагый интереслары, максат-омтылышлары һәм карашлары белән бер-берсенә никадәр якын бу бөек шагыйрьләр!

Тукай һәм Сабир хезмәт халкының танылган әдипләре иде. Алар гади халыкның кайгы-газапларын уртаклаштылар, аның хыял-өметләре белән янып яшәделәр. Алар чын гуманистлар, ярлы халыкның якын дуслары иделәр. Алар кискен ачу, тирән нәфрәт белән байларга, сәүдәгәрләргә каршы чыктылар, дингчеләрнең, буржуаз милләтчеләрнең һәм сатлык язучыларның чын йөзен фаш иттеләр. Һәр ике шагыйрь буржуаз җәмгыятьнең бозыклыгын шәхси милекчелектә, акчага табынуда күрде. Мисал рәвешендә, Тукайның «Алтынга каршы» (1907) исемле шигырен хәтергә төшерик.

И тәгалә! Җир йөзеннән алчы бу алтынны, ал,
Яндыручы бу мөкатдәс җирне бу ялкынны ал!

Бу халыкны шул бозадыр, шул котырта, аздыра;
Ялтырап күзләрне чагып, тугры юлдан яздыра.

Һәр тараф, һәр җирдә халкың шул металлның бәндәсе;
Күрмиләр хакны, чөн алтын һәр хакыйкать пәрдәсе.

Сабирның шул елда ук язылган бер шигыре дә «Акча» исемле. Менә ул:

Туганнан бирле, әй акча, сиңа омтыла күңел!
Табынсам да синең алда көн һәм төн, гаҗәп түгел.
Күңел ачам мәҗлесләрдә синең белән генә гел.
  Синсез бу дөньяның әһлен ничек ышандырасың?
  Ахмакларны синсез ничек үз ягыңа борасың?

Җаным тынмый, синең өчен халыкны таламасам,
Күземне йомалмыйм, сине сандыкка салалмасам...
Җыйма акча, аша, диләр, бер туйганчы, ичмасам!
  Гашыйкларны гашыйклыктан ничек баш тарттырасың?
  Ахмакларны синсез ничек үз ягыңа борасың?

Бу ике шигырьнең идея ягыннан охшаш, шигъри бизәкләре ягыннан якын булулары шулай ук әллә каян кычкырып, сизелеп-күренеп тора.

Буржуаз җәмгыятьтә намуслы кешеләргә тормыш никадәр авыр, читен булуы турында Сабир да, Тукай да бер төрле үк язалар. Менә Тукай шигыре. Исеме — «Дөньяда торыйммы? — дип киңәшләшкән дустыма».

...Зинһар, иптәш, хаклык сөйгән булып йөрмә,
Ялган сөйлә, күрмә зиндан, күрмә төрмә;
Тип! Дөньяда ач-ялангачларны белмә,
Иске дөнья тузанын ит күзгә сөрмә!

Тор дөньяда: иманың сат, вөҗданың сат,
Шулай торсаң, гомерең үтәр бигрәк ансат;

Алдаучылар, кяферләргә дөнья җәннәт:
Гомрең үтсен рәхәт-рәхәт, ансат-ансат.

Мәгълүм инде, мин кушканча тормыйсың син,
Нифак берлә ялган сөйләп йөрмисең син;
Җаннан куркып, куян төсле дер-дер тетрәп,
Чын мәсләкне арлы-бирле бормыйсың син.

Үл! Туфрак бул, кайт аслына, аслың яхшы;
Ханҗәр берлән күкрәгеңә касдың яхшы;
И җир шары! Нидән, белмим, хак сөйгәнгә,
Мең кат синең өстеңнән дә астың яхшы.

**Гаделсез дөньяга кырыс хөкем бу. Шундый ук шигырь Сабир әсәрләре арасында да бар.**

Җаның чыкса да тәннән, янма идең,
Янып уйланма, ялкынланма идең!
Ачы агуны бал төсле йот идең,
Үзеңне ахмак әйткәнчә тот идең!

Аның боерганына баш и идең,
Башыңа аның йөгәнен ки идең!
Яманны яхшыдан нигә аердың?
Бөтен ил йоклаганда, нигә тордың?

Кур инде тынгысызлыкның җәзасын,
Ишет үзеңне ләгънәтләү сәдасын!

**Бу ике сатирик әсәр авторларның ни дәрәҗәдә якын фикердәш, алар поэзиясенең туганлык җепләре белән никадәр якын бәйләнгән булуы хакында сөйли. Фикер агышы, ризасызлык рухы шулкадәр охшаш, аларны бер үк автор иҗат иткән әсәрләр дип кенә уйларга мөмкин. Һәм әгәр шундый ике шигыйрьнең әдәбият, язучының тормыштагы урыны турында карашлары да тәңгәл килә икән, бу — бер дә гаҗәп түгел.**

**«Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар, бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!» — дип яза Тукай үзенең бер шигырендә. Икенче шигырендә исә, каләмгә мөрәҗәгать итеп, түбәндәге фикерне әйтә:**

Караны яз кара дип һәм игътираф ит акны ак,
Җепне җеп дип язмалый сән һәм ушандак такны так.

Бакма һич кәс хәтренә, милләтең дәртенә бак!
Бәддога — явыз догая һәр заман асма колак.

**Сабирның «Шигъри мон» исемле шигырендә дә шундый ук фикер уздырыла.**

Шагыйрьнең төп эше халыкны яклау булмый ни булсын?
Илне сөю — шушы сафлыкны саклау булмый ни булсын?

Гаделлекнең олы юлы буйлап бар, читкә тайпылма,
Бару аннан — сират күпереннән атлау булмый ни булсын?

Бәлаләр килсә дә башка, сынатма, түз! Шулай итсәң,
Хакыйкать тарафыннан сиңа мактау булмый ни булсын?

**Ике шагыйрь иҗаты арасындагы бәйләнешләрне тирәнтен өйрәнү — киләчәк эше. Алар иҗатын яхшырак аңлау һәм аңлату өчен, киләчәктә һәр ике халыкның социаль тормыш шартларын да, милли традицияләрен дә ныклап өйрәнерләр. Боларны белми торып, алар иҗатындагы бәйләнешләрнең характерын да, һәр ике шагыйрьнең үз милли әдәбиятларын үстерүдәге рольләрен дә дөрес аңлау һәм бәяләү шактый кыен. Тикшерүчеләрне мавыктыргыч эш, кызыклы ачышлар көтә. Ә андый тикшеренүчеләр табылачагына мин шикләнмим.**

◆◆◆

# КӘРИМ СӘГЫЙД АРХИВЫННАН

*Габдулла Тукай үзенең истәлекләрендә: «Петербургта минем бишәр еллык иптәшләр: Кәбир Бәкер, Габделкәрим Сәгыйдовлар бар»[1], — дип яза. Шуларның соңгысы минем әти.*

*Кәрим Сәгыйд (1883—1939) — татар халкының Бөек Октябрь революциясенә кадәрге әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый тормышында шактый актив катнашкан журналист, тәнкыйтьче, соңыннан укытучы һәм Фәннәр академиясе системасында гыйльми эшче. Ул халкыбызның Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан кебек атаклы әдипләре белән якыннан таныш һәм дус булган. Вакытлы татар матбугатында «Кәрим Сәгыйд», «К. Сәгыйд», «Петербург корреспонденты», «К. С.» һәм башка имза, псевдонимнар белән язылган мәкаләләр байтак очрый. Алар, нигездә, тарихи-иҗтимагый һәм әдәби мәсьәләләргә багышланганнар.*

*Язу эшендә тәртип, төгәллекне ярата торган кеше булганга, әти аерым-аерым дәфтәрләргә тормышта үзе күргән һәр вакыйга турында төрле мәгълүматлар теркәп барган. Кызганычка каршы, аның ул дәфтәрләренең барысы да бүгенге көнгә кадәр сакланмаган. Исән калган кулъязмалары арасында Габдулла Тукай белән танышу, очрашулары турында язылган бер истәлекнең караламасы бар. Ул моңарчы беркая да басылмаган.*

*«Тукай тормышыннан истә калганнар» дип исемләнгән әлеге кулъязма истәлек төрле форматтагы кәгазь битләренә гарәп хәрефләре белән язылган. Язылу вакыты төгәл билгеле түгел.*


*ЭНЖЕ СӘГЫЙДОВА,*
педагогия фәннәре кандидаты.

## Тукай тормышыннан истә калганнар[2]

Габдулла әфәнде Тукаев белән минем арадагы мөнәсәбәт 1905 елдан башлана. Ул вакыт мин Оренбургта, ул Уральскида иде. Шул вакыт мин «Фикер» белән «Әлгасрелҗәдит»кә язган нәрсәләремә карата аңардан өч-дүрт мәртәбә хат алдым. Мөнәсәбәт фәкать шуннан гына гыйбарәт иде. Ул көннән бирле минем тормышта төрле-төрле үзгәрешләр булып үткәнгә, табигый, аның хатлары сакланмаган, югалганнар. Калса да: «Ялгыз «Чүкеч» белән «Уклар» журналы Кучум хан гаскәренең коралы төсле, «Вакыт» белән «Фикер» газеталары Кучум ханның исламияткә өндәгән фәрманнары кебек» дип язган җөмләләре генә онытылмыйча, хәтердә калганнар.

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 томда. IV том. Казан. 1956 ел. 153 бит.
[2] Кулъязмадагы тыныш билгеләре бүгенге кагыйдәләр нигезендә куелды. Кайбер гарәп-фарсы сүзләре хәзерге укучыларга аңлаешлы сүзләр белән алмаштырылды. Истәлек бераз кыскартылды. **Редакция.**



*Истәлекнең беренче бите.*

Ул вакыт мин Тукай белән күрешеп танышырга муаффыйк булмадым. Чөнки берәр ел үткәч тә, мин Хивага, ул Казанга китеп, аралар тагын да ераклашты. Шуның өчен Габдулла әфәнде Тукаевның ул вакытларына карата бу урында бер сүз дә әйтмим. Тик кайсыбер исемдә калганнарны теркәп китү белән генә чикләнәм. Әһәмияте булса — бик тә гүзәл, булмаса — миннән бер хатирә.

1910 елда мин Казанга кайтканда, Габдулла Тукаев анда «Болгар» номерларында тора, ул вакытта инде аның берничә шигырь мәҗмугалары да чыккан, исеме дә тарала төшкән иде. Шундый бер шөһрәткә каршы, мин аны сүзен батырып сөйли торган калын һәм саф тавышлы, зур гәүдәле, «солидный бер господин»дыр дип хыял итә идем.

— Вакыты бар микән? Мин күрешер идем! — дип, Мәхмүд Мәрҗани[1] аркылы үзеннән рөхсәт сорадым. Кердем. Күрешеп бик озак сөйләшеп утырдык. Каймаклап, рәттән ике самовар чәй эчеп бетердек. Хыялымның дөрес чыкмавына бераз эчем пошса да, үткен хиссиятнең тупас гәүдәдән өстен һәм артыклыгын игътибарга алып, үземне-үзем юаттым. Төрле сүзләр арасында чын иттереп, Тукай үзен Казан китапчыларының обижать итүләреннән зарланды да:

— Безнең урамга килерсез әле, мин сезнең кирәгегезне бирермен, — дип, йодрыгын селкеп куйды.

Моннан соң Тукай белән еш-еш күрешә торган булып киттек. 1910 елның җәй башында, «Милләт» матбагасында «Күңелле сәхифәләр» дигән рисаләсе басылган вакытта, «Милләт» конторындагы утырышта үзенең фәкыйрьлегеннән, хәяты өчен бербер хезмәт йөкләргә тели алмавыннан, күзенең зәгыйфьлегеннән, гомумән, сәламәтсезлегеннән ачынып: әйләнәмдәге дус-ишләрнең «кәеф мәҗлесләре» белән гомерем үтәри дип, зарланган кыяфәт белән үзенең Казаннан китәргә карар биргәнлеген сөйләгән иде. Шулай булса да, ул үзенең сөйгән, шуның белән бәрабәр, туйган Казаныннан һич тә аерыла алмады. Ул үзенең хисенә урын таба алмый иде. Кайда караса да, бер ертык,

[1] Язучы Мәхмүд Галәү.

кайда гына утырса да, бер китек күрә, күнелен йөздерерлек бер дингезгә очрый алмый иде. Шуның өчен ул һич тә бер-берсенә ябышмый торган көлке сүзләр белән мәҗлес үткәрә, үзенең нечкә хисен анламый торган дөньядан, адәмнәрдән мыскыл итеп көлә, гөнаһсыз хайваннарга, мәгъсум сабыйларга карап шатлана һәм алар белән уйный, кәҗәләр, бәрәннәр, песиләр белән сөйләшә, артыгракка китсә, үзенең шигыре, үзенең гыйшкы белән гарешкә аша иде.



## ТУКАЙНЫҢ ПЕТЕРБУРГТА ҮТКӘН КӨННӘРЕ

Габдулла әфәндегә, сәламәтләнер өчен, иң әүвәл, Казаннан китәргә, аннан соң зур докторларга, тәҗрибәле профессорларга күренеп дәваланырга кирәк иде. Моның өчен дә муаффыйк бер урын Петербург дип табылды. Янәдән хәзерге көндә Петербургтагы мөхтәрәм затларымыздан берничәсе 1912 елның башында Петербургта «Сүз» исемле татарча бер газета чыгармакчы булып та йөргәннәр, менә бу ике мәсьәлә бергә буталганнар иде. Габдулла әфәнде үзе бу мәсьәләнең эчендә, һәммәсеннән хәбәрдар, һәммәсенә разый, шулай итеп, Петербургка килергә тели иде. Ушбу кыш көнендә булган күнелсез бер вакыйга әлеге газетаны чыгару юлында бераз уңайсызлык итте. Шул сәбәптән, Тукайның килүе дә кичекте. Ул инде язын Троицкига китеп, җәй буенча кыргыз[1] даласында кымыз эчеп, бераз сәламәтләнгәч, көз көнендә Петербургка килмәкче булды. Шул ният белән март аенда Казаннан Уфага китте. Анда баргач, әле кымызга иртәрәк икән, Троицкига киткәнче Петербургка барып, докторларга күреним, кышкы мәсьәлә белән дә бераз танышып кайтыйм, дип уйлады. Ул, үзе хаста булса да, рухы, җаны, хисе белән мин культурный шәһәр кешесе, шау-шу яратам, мәҗлес сөям дип, тиз генә (Петербургка — Э. С.) телеграмма сукты да юлга чыкты.

Уфадан аны кадерләп озатучы булмаган. Юлда 3 класс вагонында бик кысен булган. Бигрәк тә Мәскәү белән Петербург арасындагы халык күплеге хаста Тукайны кысып үтерә язган. Мәскәүдән чыккач, Петербургка килеп җиткәнче, бәйләп өлгертә алмам дип, нәрсәләрен дә чишмәгән. Кесәмдәге юклы-барлы акчамны алырлар дип, йокысын да йокламаган. Аңардан юлчылар шикләнеп беткәннәр. Бер урыс, аның кыяфәтенә гаҗәпләнеп карап торган-торган да: «Син кытаймы яки барышнямы?» — дип сораган. Тукай аңарга каршы: «Кесәмдән ширпы чыгардым да, бу ширпымы яки таумы? дип сорадым. Эш шуның белән бетте», — ди.

Тукай Петербургка килгәч тә, Муса әфәнде Бигиев[2] ханәсенә төште. Аңарга Петербург сихерле пәри шәһәре кебек тәэсир итте. Ул аның бөек диварларын сәддән Искәндәргә[3] охшатты. Бакчадагы агачларын урам себеркесе төсле, фаэтоннарның йомшак резиновый шиннарын татарның киез итеге кебек, Невский урамы татар баеның түр сәкесеннән дә пакь икән, диде...

Габдулла әфәнде Петербургка килгәч тә Муса әфәнде ханәсенә төште дидем. Муса әфәнде ул вакытта, хатыны вә бала-чагалары белән, 4—5 бүлмәле бер квартирада тора иде. Бу квартир аның үзе өчен житәрлек булса да, читтән кунак-фәлән килеп төшкән вакытта аерып бирерлек артык бер бүлмәсе юк иде. Шуның өчен Тукайны, хөрмәтләп, үзенең түр бүлмәсенә урнаштырды. Ул бүлмә — аның эш вә язу һәм уку бүлмәсе дә. Ул анда Тукайга ятак ясады. Муса әфәнде әлеге шул «между прочим» йокысын да, Габдулла әфәндегә иптәш булыйм дип, шул бүлмәнең идәненә ятып йоклады. Бар нәрсәләрен Тукайга биргәч, үзе пальтосын ябынып ята торган иде. Габдулла әфәнде авырып яткач, тәмәке дә тарткач, әлбәттә, Муса әфәндегә ул бүлмәдә хезмәт итү кыенрак булгандыр. Тукай моны сизенгән. Аның өстенә Тукай, никадәр авыру булса да, бер җирдә бикләнеп ятуны яратмый, төрле җиргә йөрисе килә. Күңел ачуларын сагына. Муса әфәндене исә болай итәргә вакыты юк. Ул үзе ханәсендә торып кына хөрмәт итә. Хөрмәт иткәндә дә ихтирамын артыграк иттереп җибәрә. «Әфәндем, әфәндем! Боерыгыз» дип, «машалла» дип, өй эчендәге һәммә вәк-төякләргә мүһәйә

---

[1] Казакъ даласы.
[2] Муса Бигиев — Петербург мулласы, Октябрьдан соң эмиграциягә китә. Редакция.
[3] Александр Македонский валы.

тора[1]. Тукай табигате мондый нәрсәләрне күтәрә алмый. Чөнки аның хиссияте бик назик. Ул шагыйрь. Аның һаман да төрле җирләргә йөрисе килә. Муса әфәнде алып барган яки барачак 3—4 төрле җир аның өчен кызыклы түгел. Вакарьлы кешеләр аңарга компания була алмыйлар. Ул андый кешеләрнең: «Син курай уйный беләсеңме?» дип, кәефләрен бозарга гына ярата. Муса әфәнде ханәсенә Тукайны зиярәт итәр өчен төрле татар курсисткалары, үзенең тәгъбиренчә, «телсез студентлар», хатын-кызлар, аристократлар киләләр. Муса әфәнде һаман да: «Машалла, бойырыгыз», ди. Тукай исә кабул итми. Чөнки аның табигате, үзенә мәгълүм бер фәлсәфә белән, мондый хәлләрне яратмый. Ул хатын-кызлар мәҗлесен, төрле кокеткаларның, «телсез студентларның» сүзләрен, тәмсез, күңелсез, киләксез эш дип кенә атый. Аңарга икенче нәрсә кирәк. Ул нәрсә Муса әфәндедә юк, табылмый. Менә шуның өчен Тукай, Муса әфәнде ханәсеннән китеп, үзенә аерым бер бүлмәгә урнашмакчы була. Шул ният белән Муса әфәндедән минем, Кәбир Бәкернең, Шакир Мөхәммәдъяровның адресларын үтенә. «Тагын нинди яшьләр бар» дип, һәммәсен сораша. Муса әфәнде моңарга каршы: «Миңа мәгълүм түгел», дип җавап биргәч, Тукайның кәефе китә. Өметсезлек белән авыруы тагын да көчәя. Муса әфәнде аны докторга алып бара. Бу да файда итми. Шул көнне Сафа мулла белән Кәбир Бәкер, нинди ният беләндер, тирәләрендәге бер студент аркылы, Тукайны үзләренә чакырталар. Тукай ялгыз, югарыдагы уңайсызлыктан котылу дәрте белән генә, аны-моны бер дә тикшермичә генә, Муса әфәнде ханәсеннән таярга омтыла. Бармакчы булып вәгъдә бирә. Муса әфәнденең моңарга, киләчәкне уйлап, бераз кәефе китә. Иртәгесен иртә белән Кәбир Бәкер Тукайны Сафа муллаларга алып китә. Анда граммофон уйнатып аның кәефен ачалар. Петербург мөселманнарының бер-берсенә дошман ике партиягә бүленгәнлеген сөйләп бирәләр. Мусалар синең исемеңнән файдаланып, сине эксплуатировать итмәкче булалар дип, аны котырталар. Әлеге газета мәсьәләсе Тукайның хәтеренә килә дә, бу сүзләрне ишеткәч, ул сагышка кала. Әҗәле якасында торган бер хастаны инандырасы кыен түгел бит. Хосусән, Сафа муллалар аңарга докторлар, тагы әллә нәрсәләр вәгъдә итәләр. Хөраҗәтләрен[2] күтәрәләр. Тукай бу эшләрнең төбендә чын ихластан булмыйча, дошманнарның күзен чыгарыр өчен генә эшләнгәнен сизенә алмый. Ул үзенең авыруы белән, Муса әфәнде бүлмәсендәге уңайсызлык белән исергән. Аның өстенә ул, үзе әйткәнчә, «Яшьнәмим дә, күкрәмим дә, утсыз инде күкрәгем» дигән хәлгә килгән.

Гакыйбәт[3], Тукай шул китүеннән Муса әфәндегә кире әйләнеп кайтмый. Кәбир Бәкер, Сафа мулла акчасына, Тукай өчен Казанский урамның 5 номерлы йортында[4] бер бүлмә алып, аны шунда урнаштыра. Муса өйдә юк вакытта, анда барып Тукайның нәрсәләрен ушбу бүлмәгә алып китерә. Әйтмичә-нитмичә генә кунагының үзеннән сызуы Муса әфәнде өчен тагын да кәефсез була. Шулай итеп, Тукай белән ике ара бераз бозыла. Ләкин Муса әфәнде үзенең ихтирамын һаман да югалтмый. Ул аны бу бүлмәгә килеп тә зиярәт итә. Мөселман агай-энеләргә Тукай хөрмәтенә бер мәҗлес ясарга тиеш дип аңлата. Тукайны иң әгъла бер шифаханәгә куйыйк, ничек кенә булса да, бер юлын табып, сәламәтләндерик, хөраҗәтен күтәрик, үземезнең халык шагыйрен вакытында тәкъдир итик дип киңәш итә. Әлеге кешеләр Тукайны ул мәҗлескә бармаска өндиләр. Муса әфәнде белән Лотфи (Исхаков — Э. С.) үзләре килеп чакырсын, диләр. Гакыйбәт, Тукай бара. Аш-су мәҗлесе була. Алтмыш сумлар микъдары иганә бирелә. Ләкин Муса әфәнденең киңәше җиренә җиткерелми. Бу ноктага килеп җиткәч, гаеп, һич шөбһәсез, ике тараф өстенә дә йөкләнә. Муса әфәнде дә, Сафа да гаепле. Муса әфәнде дәрвиш, Сафа мулла аның дәрвишлегеннән файдалана. Ләкин Тукайны бу турыда каралларга һичбер юл юк. Чөнки ул бу вакытта авыруы белән башы әйләнгән бер исерек, шагыйрьлегеннән бәндәлеге өстен иде.

Тукай Казанский урамда тора башлагач, аңарга аз-маз яшьләр килгәләде. Ул алар белән утырышып тәмәке тартты. Инде менә уңайсыз түгел, бу бүлмәдә аулак, теләгәнчә авырып ят, палас җәелгән юлы да — Муромцев юлы төсле бит, дия торган иде. Монда аны Сафа мулла лакейлары һич тә яныннан китмичә сакладылар. Кәбир

---

[1] Әзер булып тора.
[2] Расходларын.
[3] Соңыннан, аннан соң.
[4] Хәзерге Плеханов урамы.

Бәкер дә үзлексез янында булды. Тукай үзенең көчсез, дәрмансыз, минут саен абынып егылырга торганына карамыйча, күңеле һаман да «кәефле җирдә» утырырга ярата иде. Шуның өчен Кәбир Бәкер белән ашкынган җирләренә, Муса әфәндедә табылмаган нәрсәләрне эзләргә чыккалап кергәли иде.

Бер мәртәбә, үзенең теләве буенча, Кәбир Бәкер белән икәү култыклап минем бүлмәгә алып килгән идек. Бик җәелеп, рәхәтләнеп утырды да, гадәте буенча бәйләнешсез генә көлдереп: «Вота шуннан соң авырта башлый ди аягы сыерныкы!» — дип куйды. Моның белән ул мишәрләрдән көлә иде.

Тукай бүлмәсендә ятканда, үзенең хасталыгына ачуланып, мин дә Петербургка килдем, дегет чиләге дә килде дип, үз-үзеннән көлә иде дә: «Алла бүрегә бәхет бирсә, тешен сындырып бирә шул», — дип әрни. Ләкин соңыннан бәхет өметен югалту — үзе бер бәхет ул дип, үзен-үзе юата иде.

Тукайның Петербургка килүенә ун көннәр үткәч, авыруы тагын да куәтләнде. Бик каты йөткерә, бик нык какырык килә башлады. Өметсезлек, әҗәл аның күз алдында торалар иде. Мөрәҗәгать ителеп, доктор язулары белән алынган даруларның берсе дә файда бирмәде. Сафа мулла да вәгъдә иткән докторларны рекомендовать итә алмады, Муса әфәнде дә үзенекен эшләмәде. Шулай итеп, Тукай ике арада калгач, гакыйбәт, Шакир Мөхәммәдъяров университет докторы господин Польны китереп күрсәтте. Поль, Тукайда булмаган авыру юк, әгәр дә гомерен бераз сузу мәтлүп булса, тизрәк Петербургтан җылы якка озатырга кирәк дип, мәслихәт бирде. Бер көн үткәч, Тукайны кире Уфага озаттык. Сафа мулла билет алып бирде. Муса әфәнде вокзалга озатырга төшмәгән иде. Һич шөбһәсез, минә шушы тәэсирләр белән булырга кирәк, Тукаев моннан соң инде Петербургка килмәм дип китте...

Габдулла әфәнде Петербургта бөтенесе 13 көн торды. Киткән вакытта Петербургтагы иң соңгы ризыгым дип, чыкмаган тавышы белән нәрсәдер сөйләпме, такмак әйтепме, вокзалда сыра эчте. Кәбир Бәкер Мәскәүгә кадәр озата китте. Бу вакыт апрельнең ахырлары иде. Мин моннан соң мәрхүм Тукайны күрә алмадым. Сагынып укырга язган шигырьләре генә калды. Шул күрешүдә ул минем белән мәңгегә аерылды. Актык сүзе: «Сау бул», — иде.

— Сау бул, Тукай, үлсәң дә, сау бул, җаным, синең бит исемең САУ...

Менә бу минем язганым хәзергә бер хатирә генә. Ләкин ул киләчәктә тарих язучы өчен бер материал булыр. Өмет шуңарга баглый...

*К. С.*

# БЕР РӘСЕМНЕҢ ТАРИХЫ



1946 елда мин, Урта Азия дәүләт университетында укыр өчен, Ташкентка килдем. Көннәрнең берендә, шәһәр урамнары буйлап йөри торгач, Мукими театры артындагы Шайхантохур базарына барып чыктым. Монда шәһәр халкы үзенең вак-төяк әйберләрен чыгарып сата икән. Шунда бер татар хатынын очраттым. Какча гәүдәле, сөйкемле йөзле бу хатынның өстендә иске, ләкин әйбәтләп юылган кием иде. Ул, җиргә газета җәеп, аның өстенә примус головкасы, тәмәке, төрле төстәге карандашлар һәм шуның ише әйберләр өйгән. Шулар янында тагын диңгез манзаралары, шәһәр күренешләре, урманнар төшерелгән дистәгә якын рәсем дә бар иде. Әнә шул рәсемнәрне күздән кичергәндә, мөлаем йөзле бер егетнең фотографиясен күреп калдым. Интеллигент кыяфәтле бу егет, ничектер, таныш кебек тоелды. Кайсыдыр китапта күргән мәшһүр кешенең сурәте, ахры, дип уйладым күңелемнән. Рәсемнең бер читендә гарәпчә язылган сүзләр игътибарымны тартты. Иҗекләп укып караган идем, аларны Габдулла Тукай язган икән. Мин, әлбәттә, татар әдәбиятының классигы, атаклы шагыйрь Габдулла Тукай әсәрләрен мәктәптә укып йөргән чакларда ук беләм, кайберләрен хәтта ятлаган да идем. Шунысы ачыкланды, бу рәсемен шагыйрь үзенең туганнарыннан яки дусларыннан ике кешегә бүләк иткән икән.

Мин хатынның төрле рәсемнәре арасыннан Габдулла Тукайның шушы фотосын алып киттем. Бераз соңрак, туганымның ярдәме белән (ул гарәпчәне танучы кеше иде) белдем: шагыйрь Габдулла Тукай рәсеменең аскы читенә үз кулы белән шушы сүзләрне язган икән:

«Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй вә Габдрахман әфәнделәргә ядкарь. 5 август, 1912 сәнә. Г. Тукаев».

Бу рәсем, Г. Тукайның иң яхшы һәм сыйфатлы чыккан портретларыннан булып, өстәвенә, шагыйрьнең үлеменнән бер ел яки ел ярым гына элек төшерелгән.

Г. Тукайның Татарстан дәүләт музеенда һәм Шәриф Камал музеендагы фотоларына охшаса да, ул аларның бер нөсхәсе генә түгел. Хәтта шулай булган тәкъдирдә дә, бусы аерым әһәмияткә һәм кыйммәткә лаек. Рәсемдә Тукайның автографы бар, шагыйрь аны үз үлеменнән аз гына элегрәк бүләк иткән.

Безнеңчә, Габдулла Тукайның автографлы бу фотопортреты бөек татар шагыйренең иҗатын тикшерүчеләр өчен яңа бер документ була ала.

Б. САЛИХОВ, таҗик әдәбияты белгече, филология фәннәре кандидаты.

**Рафаэль Мостафин**

# АЛМАН ИЛЕНДӘ

ДҮРТЕНЧЕ ОЧЕРК

## Моабит хәрабәләре янында



Буй-буй сызыклы шлагбаум колгасы күтәрелә. Нәзакәтле генә сәламләп, Германия Демократик Республикасының чик сакчысы без утырган машинаны битараф зонага уздырып җибәрә. Көнчыгышны Көнбатыштан, социалистик илләр лагерен «ирекле дөнья»дан бүлеп аерып торган берничә метр араны үтәбез.

Икенче шлагбаум алдында машина кабат туктый. Әмма илчелек машинасы икәнен шәйләүгә, озын буйлы полицай колганы күтәрә һәм иренеп кенә кул изи. Янәсе, уза бирегез... Мин документларда казынуларын, имза һәм фотоларны чагыштырып карауларын, һәрхәлдә, нәрсәгә дә булса бәйләнүләрен көткән идем. Юк икән. Полицай әнә, бөтен кыяфәте белән исе китмәгәнлекне күрсәтергә тырышып, артка борылды.

— Үзенә калса, кыланып маташуы, — ди юлдашым, Берлиндагы Совет илчелеге хезмәткәре Сергей Петрович Ануфриев.— Алар, янәсе, ике Берлин арасындагы чикне танымыйлар һәм танырга теләмиләр дә. Җай чыккан саен, шуны сиздереп калырга тырышалар.

Машинабыз халык белән тулы, шау-шулы урамнар буйлап чаба. Буяулы игъланнар, күз явын алырлык кибет витриналары, ерактан ук күзгә ташланып, игътибарны ирексездән үзләренә җәлеп итәрлек рекламалар, төрле төстәге, төрле төрдәге машиналар ташкыны, чуар төсләргә буялган бензин колонкалары — барысы да мин күз алдына китергәнчә, барысы да нәкъ китапларда язылганча, кинофильмнарда күрсәтелгәнчә. Сугыш эзләре бөтенләй диярлек күренми. Иске Берлинның бер-берсенә сыенып утырган биш-алты катлы соргылт яки кызгылт-көрән төстәге бинаus арасыннан хәзерге заман корылмалары — пыяладан һәм алюминийдан эшләнеп, төсле плиталәр белән бизәлгән унбишәр-егермешәр катлы яңа йортлар күтәрелә.

Рейхстаг яныннан узабыз. Өстәге катлар һәм үзәк гөмбәз тирәсе агач басмалар, ремонт вакытында куела торган төрле җайланмалар белән әйләндереп алынган. Ә аста ремонт эшләре инде тәмамланган. Мәһабәт колонналар, ялтырап-балкып торган зур тәрәзәләр, пөхтәләп себерелгән һәм су сибелгән асфальт юллар. Әйтерсең, Рейхстаг стеналары гомер-гомергә шундый хәлдә торган, аларда бомбалар сереме дә, снаряд һәм пулялар эзе дә, совет сугышчылары калдырган язмалар да — берсе дә булмаган. Сөйләүләренә караганда, Рейхстаг Көнбатыш Германиягә бик кыйммәткә төшкән. Аны ремонтлау өчен, немецлар шундый ук зурлыктагы 3—4 яңа бина салырлык акча тотканнар. Көнбатыш Германия хөкүмәте юкка гына юмартланмый, билгеле.

Германия Демократик Республикасы чигеннән дистә метрлар гына ераклыкта урнашкан бу бинада бундестаг утырышлары уздырыла, реваншизм рухындагы нотыклар сөйләнә...

Рейхстагны узып күп тә бармыйсың, җимерек кварталлар башлана. Күп кешеле зур каланың нәкъ үзәгендә шундый хәрабәләргә юлыгу, ничектер, сәер дә, хәтта уңайсыз да кебек. Сугыш чорыннан калган аерым җимерек урыннарны Көнчыгыш Берлинда да очраткан идем. Әмма мондыйны беренче кат күрәм. Түбәсез һәм түшәмсез стеналар, алар сөремләнеп, чәрдәкләнеп беткән... Тузан. Кирпеч ватыклары, вак таш өеме... Җил уйный, һавада күгәргән тимер исе. Ә менә бу йортның барлык стеналары җимерек. Таш баскычлар, һавага кадәр күтәрелгән, култыксасыз таш баскычлар гына торып калган...

Менә без эзләп килгән Лертерштрассе урамы. Шушы бәләкәй һәм тын урамның нәкъ башланган җирендә, шәһәр электропоездлары вокзалы (Берлин икегә бүленгәнлектән, Лертербанхоф вокзалы хәзер эшләми) янында гына Моабит исемле хәрби төрмә урнашкан булган [1]. Машинаны туктатып, җиргә төшәбез. Каршыда кызгылткөрән кирпечтән эшләнгән биек, нык койма; ул инде тора-тора сөремләнеп беткән. Тигез аралар калдырып, очлы башлы, кай яклары белән урта гасырларда салынган замокларны хәтерләткән каравыл каланчалары ясалган.

Таш койманың тышкы ягыннан берничә генә метр ераклыкта, акация куакларына яшеренебрәк, тагын бер койма сузыла, монысы чуеннан эшләнгән. Ике койма арасында шактый иркен бушлык, чебен очып узса да күренерлек. Кирпечтән гөмбәзләп эшләнгән төп капка. Исеме шулай гади генә булса да, чынында ул үзе бер зур гына бина булган. Хәзер яртылаш җимерек. Кайчандыр авыр тимер капкалар утырган таш баганалар гына торып калган. Мөгаен, Җәлилне дә шушы юлдан йөрткәннәрдер. Ябык машинага утыртып гестапога илткәндә, бу шыксыз гөмбәзләрне ул да күреп калгандыр, билгеле...

Төрмәнең киң ишек алды буп-буш. Тик аргы башта гына нидер төзеп маташалар. Аяк астында кирпеч ватыклары, таш өемнәре; бетон плитә һәм өрлек кисәкләре, башларыннан күгәргән арматура тимерләре тырпаеп тора. Урыны-урыны белән чүпчар өемнәре астыннан тигезләп шомартылган зур-зур плитәләр күренеп тора. Плитәләр арасыннан яшь үлән шытып чыккан. һавага чыгарганда, тоткыннарны шул юлдан йөрткәннәрдер, күрәсең: Андрэ Тиммерманс сөйләгән иде... Үзләрен шомартып бетергән төрмә башмакларының эзен бу таш плитәләр әле бүген дә саклыйлардыр кебек.

Билгеле булганча, 1945 елның апрелендә һөҗүм итеп килүче совет солдатлары нәкъ шушы төрмә ишек алдында Муса Җәлилнең ниндидер китап битенә язып калдырган хатын тапканнар иде. Анда шагыйрь үзен үлемгә хөкем итүләрен хәбәр иткән, туганнарына, каләмдәш дусларыннан Фадеевка, Тычинога һәм башкаларга соңгы сәламен тапшыруны үтенгән иде.

Сугыш бетеп күп тә үтми, язучы Юрий Корольков, ул вакытта «Правда» газетасының Берлиндагы хәбәрчесе, төрмәнең исән калган төшләрен карап йөргәндә, 382 камераның стенасында түбәндәге язуны таба:

«Без кырык үлем аша үттек, әмма буйсынмадык.

Муса Җәлил».

Шушында, салкын таш капчыкта ятканда, тимер бик артында үлемсез Моабит шигырьләре язылган.

Әкияттәге серле йомгак булып
Тәгәрәде тормыш сукмагым,
Озак бардым, ахры, көн батканда
Шушы йортка арып туктадым.

---

[1] Берлинда шул ук исемдә тагын бер төрмә, Эрнст Тельман һәм башка патриотлар газап чиккән граждански төрмә бар. Шәһәрнең бер үк микрорайонында урнашкан булсалар да, асылда аларның һәрберсе мөстәкыйль төрмә. Сугыш азагында хәрби төрмәгә бомба эләгә һәм биш почмаклы йолдыз рәвешендә салынган бинаның бер канаты җимерелә. Калган өлешен сугыштан соң сүтеп алалар. Моабит төрмәсенең икенчесе исә әле дә эшли.

Әкияттәге дию патшасыдай,
Йорт хуҗасы чыкты каршыма.
Балта аскан, бөркет үләксәсен
Бүрек итеп кигән башына.

...Әкияттәге серле йомгак булып
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда.

Һәм менә, җырлары эзеннән барып, мин шагыйрь соңгы кат тукталган урынга килеп җиттем. Әмма үзен тапмадым. Батырлыгына шигъри һәйкәл булып, җырлары, үлемсез җырлары гына калган...

Аңа, «һәр йөрәкле Гейне гашыйгына», бөтен авырлыкларны, фашист җәлладларының һәртөрле җәзаларын үз җилкәсендә татырга туры килгән. Шигырьләренең берсендә, сызланып һәм әрнеп, шагыйрь болай яза:

Кая соң, сез, Гейне һәм Марксны
Тыңлап үскән мәгърур егетләр?..


Ул чагында Җәлил үзе: күп булса ун-унбиш ел вакыт узар һәм бүтән немец егетләре аның хакында фильм тудырырлар дип, уена да китермәгәндер, билгеле. Эрих Мюллер сценариесе буенча эшләнгән ул фильм «Кызыл ромашка» исемле. Аны Германия Демократик Республикасында һәм башка демократик илләрдә миллионнарча тамашачылар карады. Муса Җәлилнең немец теленә тәрҗемә ителгән шигырьләре ГДРдагы вакытлы матбугат битләрендә басылды, аерым җыентыклар булып чыкты. Шагыйрьнең «күтәрелсен Тельман трибунага, Маркс, Гейне кайтсын иленә» дигән изге теләге дә тормышка ашты. Дөрес, әлегә Германиянең бер яртысында гына. Кем белә, бәлки, менә монда — элекке төрмәнең киң ишек алдында — күренекле татар шагыйренең якты истәлегенә багышлап һәйкәл ачылыр көнгә дә ерак калмагандыр.

## Көнбатыш Берлин төрмәсендә

Моңарчы хәтта фоторәсемен генә күргәнем булмаса да, Тегель төрмәсенең тәрәрәвешендә салынган зур бинасын ерактан ук танып алдым. Җәлил оешмасының бер члены, шушы төрмәнең элекке тоткыны Фәрит Солтанбеков аның хакында күп сөйләгән иде.

...Үзәктән һәр дүрт якка таба, рәт-рәт булып, исәпсез-сансыз камера ишекләре тезелеп киткән. Дүрт катлы төрмәнең коридоры этажларга бөтенләй бүленмәгән: астан өскә кадәр шыр ачык. Югары катлардагы камераларга менү өчен озын баскыч куелган, һәр катның камера ишекләре турыннан буйдан-буйга тар гына галерея сузыла, ике галерея арасына (тоткыннар, сикереп, үз-үзләрен үтермәсен өчен) тимер чыбыктан ясалган ятьмәләр куелган. Төренең нәкъ уртә бер җирендә сакчы урыны, шуннан төрмәнең бөтен коридорларын күзәтеп була. Бөтен төрмә, әйтерсең, бер сулыш белән яши. Үлемгә хөкем ителгән тоткыннардан кемне дә булса җәзаларга алып китәләр һәм ул, аскы каттан торып, башка камералардагы тоткыннар белән саубуллаша башлыймы, яки надзирательләр берәр үзсүзле әсирне кыйнарга керешәләрме — бу хәлләр минуты-секунды белән бөтен төрмәгә тарала. Һәм тоткыннар тонык гөрелдәп, үзләренең нәфрәтләрен белдерәләр. Кычкырып сөйләшергә, надзирательләр белән әрепләшергә, хәтта аларга караңгы чырай күрсәтергә дә ярамый. Андый тоткынны карцер көтә. Карцер дигәннәре исә төрмә подвалындагы боз идәнле бер чокыр. Басыйм дисәң — баш тия, утырыйм дисәң — идәне шакшы. Карцерга элэктеңме, аннан чыгу юлы бер генә: я төрмә лазареты, я кабер. Кеше белән дыңгычлап тутырылган төрмәдә шуңа күрә һәрвакыт шомлы тынлык хөкем сөрә.

Төннәрен Берлинны утка тота башлауга, котлары алынган надзирательләр подвалларга йөгерешәләр. Шул минутларда гына төрмә иркенләп бер шаулап кала. Француз, рус, немец һәм полякча сүзләр яңгырый — Европаның барлык халыкларын-



*Берлиндагы Тегель төрмәсе.*

нан диярлек вәкилләр бар бу төрмәдә. Берәүләр, зенит туплары залпын һәм бомбалар шартлавын җиңәргә теләгәндәй, тәрәз аша күрше камерада утыручы иптәше белән сөйләшергә тотына. Кайсыдыр «Зәңгәр яулык» җырын башлый, кемнәрдер Гитлерны каргый. Сүз диңгезе арасыннан татарча әйтелгән җөмләләр дә ишетелеп кала: «Якташлар! Иделдән кем дә булса бармы? Җавап бирегез!» Төнге һөҗүм бетә, надзирательләр урыннарына кайта һәм төрмә тагын тынып кала.

Тегель төрмәсендә Җәлил оештырган яшерен группа членнарыннан Гайнан Курмаш, Габдулла Баттал, Әхмәт Симаев, Рушат Хисаметдинов һәм Фәрит Солтанбеков утыра. Хисаметдинов та, Солтанбеков та Мусаның үзен бирегә очратмаганнар. Әмма тоткыннар арасында аның шигырьләре йөргән, ул шигырьләр кулдан-кулга күчкән.

Әйе, инде бирегә килгәнче үк Тегель төрмәсе хакында мин байтак әйбер белә идем. Әмма бу кадәр үк зурдыр дип уйламаган идем. Коточкыч зурлыктагы бинаның бер канатында гына да рәшәткәле 140 ка якын тәрәзә санадым. Төп бинадан тыш та, төрмә ишек алдында әллә никадәр корылмалар бар бит әле. Биек кирпеч торбалы пар казаны, кер юу урыны һәм кухня, сакчылар өчен махсус бина һәм административ корпус — ниләр генә юк монда! Төрмә коймасының тышында ук надзирательләр һәм эшчеләр өчен салынган дүртәр катлы йортлар тезелеп киткән. Дөресен әйткәндә, бу үзе тышкы дөньядан бүленеп-аерып алынган кечерәк бер шәһәр.

Төп капкага якын киләбез. Кирпечтән матурлап салынган зур капка, аның өстендә готик стильдәге бәләкәй-бәләкәй манаралар. Чисталап себерелгән асфальт юл, чәчәк түтәлләре, кызыл кирпечтән эшләнгән койма кырында очлары тигезләп кыркылган агачлар үсеп утыра. Тыштан караганда, төрмә бик тыныч, хәтта сөйкемле күренә.

Мин фотоаппаратка тотынам, әмма юлдашым: кирәкмәс, ди. Эшли торган төрмә, Көнбатыш Берлинның иң куркыныч җинаятьчеләре шунда ябылган. Кем белә, андый бер объектны рәсемгә төшерергә ярыймы, юкмы... Тирә-якка күз салам. Якында кешекара күренми. Капкалар артында да шылт иткән тавыш юк, әйтерсең, тирә-юньдәге һәрнәрсә үлеп беткән. Баксаң, тимер капкада күз кадәрле тишек бар һәм шуннан безне күзәтеп торалар икән. Нәкъ Җәлил язганча:

Әкияттәге төсле тимер капка,
Күз кадәрле тишек капкада.
Дию карап һәр көн шул тишектән,
Корбаннарын санап мактана.

— Әйдәгез, барып, рөхсәт сорап карыйк, — дим. — Бәлки, төрмәнең үзенә үк кертерләр.

Сергей Петрович иңнәрен генә җыера. Янәсе, кертәләрме соң?.. Сәфәргә чыкканчы ук ул Көнбатыш Берлиндагы төрмәләрнең берәрсенә керергә рөхсәт артыннан йөреп караган иде инде. Файдасы гына булмады. Моның өчен Сенат рөхсәте кирәк. Һәм андый эш бик озак эшләнә икән. Йөреп-йөреп тә нинди җавап килә бит әле...

Ахыр чиктә Сергей Петрович түзмәде, берни дә чыкмаячак, менә күрерсең, дигән төс белән капкага таба китте. Аның зур тимер капкаларга якынлашуы булды, әйтерсең, шуны гына көтеп торганнар, капкаларның берсенә уеп эшләнгән бәләкәй ишек ачылды һәм хәрби киемле кеше, тәкәллефле генә тон белән, эчкә үтүебезне үтенде. Һәм ни булганын аңлап өлгергәнче, безне эчке якка кертеп, бәләкәй ишекне бикләп тә куйды. «Мин бер сорауга да җавап бирмим, — дип әйтә диде Сергей Петрович, аның сүзләрен миңа да тәрҗемә итеп. — Өлкән сакчыга мөрәҗәгать итәргә куша».

Проходнойда ярым караңгы, дымлы һәм салкынча. Готик стильнең һәм архитектура бизәкләренең эзе дә юк. Ян якларда зур тимер капкалар, өстә дымланып, каралып-сөрсеп беткән таш гөмбәз. Безне бирегә уздырган сакчы үз эше белән мәшгуль, ул яңадан кеше күзе зурлыгындагы әлеге тишеккә сырышкан. Әмма мин һаман сәер бер хистән арына алмыйм: үзебезгә күренмичә генә, безне күзәтәләр, ныклап һәм җентекләп капшыйлар төсле. Караңгылыкка ияләшә төшкәч, стенадагы тәрәзәгә һәм аның артында утыручы чытык йөзле хәрби кешегә күзем төште. Югарыда стеналарга көзгеләр тезеп чыгылган, кайсына гына карама, аларның һәрберсендә әлеге чытык йөзле, хәрби киемле кеше белән очрашасың. Бирегә үз ихтыярың белән һәм бик аз вакытка кергәнеңне дә беләсең, барыбер шомландыра, ничектер, куркыныч. Иптәшеннән аермалы буларак, өлкән сакчы бер дә елмаерга, тәкәллефләнеп маташырга җыенмый. Ул, бик төпченеп һәм бик озаклап, Сергей Петровичның илчелек паспортын тикшерә, кайбер нәрсәләрне язып ала. Кемнәр сез, ди, нишләп йөрисез, ди... Сергей Петрович, барлык түземлеген җыеп, аңлатырга тотына: без, янәсе, төрмәне фотога төшерергә һәм, әгәр рөхсәт булса, камераларны карарга теләр идек; ярамый икән, ул чагында сакчы әфәндене мәшәкатьләп торырга уйламыйбыз. Әмма сакчы безне төрмә эченә кертергә дә, чыгарып җибәрергә дә ашыкмый. Бераз көтәргә кушып, тәрәзә капкачын яба да, кайларгадыр, кемнәргәдер шалтыратырга тотына.

Зарыктырып минутлар уза. Бик эшлекле кыяфәт белән урамнан хәрби киемле төрмә эшчесе керә, пропускысын суза, кулына номер сугылган картон кисәге һәм бер бәйләм ачкычлар тотып, капка артына кереп югала. Бераздан төрмә ишек алдыннан капка төбенә кара-көрән төстәге ябык машина килеп туктый. Шофер янына утырып килгән сакчы тәрәзә артындагы кешегә документларын күрсәтә, тегесе аларга нindiдер билгеләр ясый, җентекләп машинаны тикшерә, бары шуннан соң гына капкадан чыгарып җибәрә. Машина узуга, шалтырап, капкалар ябыла. Без елмаешып куябыз: ничек кенә ычкынырга инде моннан. Шул чак каяндыр биленә ачкычлар таккан бер сакчы килеп чыга. Өлкәне пышылдап кына аңа ниндидер боерыклар бирә. Аннан безне дәшеп ала һәм, номерлы картон биркалар тоттырып, сакчы артыннан барырга куша.

Төп бина кырыннан узабыз. Дикъкать белән рәшәткәле тәрәзәләргә карыйм, ләкин берни дә күренми. Койма буйларында торучы сакчыларны һәм үз эшләре белән анда-монда йөгерүче берничә эшчене исәпләмәгәндә, төрмә ишек алды буп-буш. Һавага чыгарганда тоткыннарны йөртә торган мәйдан, күрәсең, каршы яктадыр. Түргә салынган дүрт катлы бинага якынлашабыз. Сакчы, тимер ишекне ачып, безне эчкә уздыра һәм аларны яңадан әйбәтләп бикләп ала. Буш коридор буйлап күпмедер баргач, өченче катка күтәрeләбез. Мин гаҗәпләнеп калам: искиткеч чисталык, больницаларда гына була торган тынлык хөкем сөрә. Ап-ак түшәм, көрән-зәңгәр төскә буялган стеналар, ялап алгандай чиста идән [1].

---

[1] Соңыннан бу хакта мин танылган немец җырчысы Эрнст Бушка сөйләдем. Ул үзе дә фашист төрмәләрендә байтак газапланган кеше. Чисталык-пөхтәлекнең сере бик гади икән. Төрмә бинасы баштанаяк тоткыннар көче белән җыештырыла, бу эшкә салкын караучыларны үтергәнче кыйныйлар иде, ди.

Сакчы безне стеналары буйлап ниндидер шкафлар тезелгән бер бүлмәгә алып керә. Төрмә канцеляриясе булса кирәк. Тәрәзә каршындагы тәбәнәк өстәл артында яшь кенә секретарьша утыра, ул ниндидер эш белән мәшгуль. Безне урта яшьләрдәге кеше каршылый; өстендә ап-ак якалы күлмәк, пөхтәләп тегелгән соры костюм, чуар төстәге галстук таккан. Башын безнең якка ия төшеп, гозеребезне тыңлый. Сергей Петрович яңадан Муса Җәлил турында сөйли, бирегә ничек эләгүебезне аңлата. Җәлилнең кайсы камерада утырганын беләсезме, дип сорый немец. Белмәгәч, бик аяныч дигән була, баш чайкый. Аннан, гафу үтенеп, каядыр чыгып китә.

Ул чыгып киткәннән соң да, күпме вакыт узды инде... Без аптыраша ук башладык. Сенат рөхсәтеннән башка чит ил кешеләрен төрмәгә кертергә ярамаганлыгын белмиләрме әллә? Бәлки, очрактан файдаланып, безне берәз тоткарлап торырга һәм шул арада никди кешеләр булуыбызны тәгаенләргә уйлаганнардыр? Чыннан да, төрмә белән кызыксынып йөрүебез шик уятырга бик мөмкин ләбаса.

Ярты сәгатьләп вакыт узгач, пөхтә киемле кешебез, ниһаять, кайтты. Ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыккан, сез бирегә ялгыш эләккәнсез, төрмәне күрәсегез килсә, сенатка мөрәҗәгать итегез, ди. Кергән юл белән үк безне кире чыгаралар. Артта соңгы капка ябылуга, рәхәтләнеп иркен сулыш алабыз.

## Шпандау төрмәсе

Шпандауны чак кына узып китмәгәнбез. Әлеге дә баягы тышкы матурлык алдый язды: очлы башлы манаралар, төрле рәсемнәр белән бизәлгән кәрнизләр, түбәсе чирәп белән капланган керү юлы. Ләкин төрмәнең алгы ягы гына шулай чибәр икән. Аз гына янга табарак уздыңмы, каршыңда, йөзләрчә рәшәткәле тәрәзәләре белән, кара-көрән төстәге шыксыз биналар пәйда була. Кай яклары беләндер алар фабрика корпусларын хәтерләтәләр. Чыннан да, фабрика, үлем фабрикасы.



*Көнбатыш Берлин. Гитлер диктатурасы вакытында һәлак булган тоткыннар истәлегенә куелган мемориаль стена. Аның янында һәрвакыт яшь немецларны күрергә була.*

Сугыштан соң Шпандау халыкара төрмәгә әйләнә һәм немец җинаятьчеләренең иң әшәкеләре шунда ябыла. Язмышның шаяруы шул буладыр инде: кайчандыр фашизм корбаннары иза чиккән төрмәдә соңыннан фашистларның үзләренә утырырга туры килә. Әмма, вакытлар үтү белән, аларны бер-бер артлы иреккә чыгаралар, хәзер анда гомерлек ябылуга хөкем ителгән Рудольф Гесс кына ята. Гитлер заманында меңнәрчә тоткыннар газапланган галәмәт зур төрмәдә нибары бер тоткын калган.

Төрмәне, чиратлашып, дүрт ил — СССР, АКШ, Англия һәм Франция солдатлары саклый. Шуңа күрә, алдан ук, төрмәгә безнекеләр эшләгән айда килергә планлаштырган идем. Ләкин комендатурада ук миңа күңелсез хәбәр әйттеләр. Кагыйдә буенча, төрмәгә чит кешеләр бөтенләй кертелми икән. Һәм егерме ел буена анда бер генә чит кеше дә булмаган. Ялынып, ялварып ка-

радым, әмма файдасыз. Шулай да, тиздән төрмә директоры (алар барысы дүртәү, һәр илдән берәр директор) Павел Степанович Лазарев килә дигәч, тагын бер тырышып карарга, аның белән сөйләшергә булдым.

Безне кызыл почмак сыманрак бер бүлмәгә алып киттеләр. Өстәлләрдә рус һәм немец телләрендәге газета-журналлар, шахмат такталары, доминолар. Без килгәнне ишетеп, берничә офицер керде. Тын алырга да бирмичә, туган ил хакында сорашырга тотындылар: илдә нилә бар? Һавалар ничек? Мәскәүдән күптән чыктыгызмы? Башкала театрларында нинди спектакльләр бара?.. Без, үз чиратыбызда, алардан Берлин турында, Шпандау төрмәсе, төрмәдәге хәлләр турында сораштык.

Тора-бара Гесс турында сүз чыкты. Рудольф Гесс нацистлар хөкүмәтендә иң күренекле фигура саналган: фашистлар партиясендә Гитлерның урынбасары, империянең Яшерен совет члены, оборона эшләре буенча министрлар советы әгъзасы. Эшләре Нюрнберг процессында каралган хәрби җинаятьчеләр исемлегендә Рудольф Гесс Герингтан кала икенче урында торган. 1940 елның маеннан 1943 елның декабрена кадәр ул Освенцимдагы үлем лагеренең коменданты булып эшләгән. Шул чорда газ камераларына гына да 2,5 млн. артык кешене озаттырган. 500 меңләп әсир авырудан һәм ачлыктан үлгән. Болары — немецларның рәсми статистикасында китерелгән саннар гына әле. Чынында исә Рудольф Гесс 4 миллионлап кешене җәзалаткан, дип сөйлиләр.

Дүрт миллион! Күз алдына китерергә дә куркыныч. Исәпләп карадык. Гесс үтерткән кешеләрдән аккан канны тотыру өчен, һәрберсе меңәр литр сыйдырышлы галәмәт зур унике мең чаң кирәк булыр иде. 12 миллион литр кеше каны... [1]

Нюрнберг процессында Гесскә мондый сорау бирәләр:

— Әйтегез әле: гитлерчылар хәтта кечкенә балаларны да крематорий мичләрендә терелэй яндырдылар, дип сөйлиләр. Шул дөресме?

— Дөрес, — ди Гесс, күзен дә йоммыйча. Аңлатып та бирә хәтта:

— Эшкә ярамаганлыктан, кечкенә балалар, әлбәттә, үтерелә иделәр. Хатыннар үз балаларын, итәк асларына тыгып булса да, яшерергә маташалар, ә без, тапкан очракта, тартып ала һәм юк итә идек.

Күз алдына китерергә тырышып карадым: шул чаклы кешенең канын суырган, яшь балаларны утка атарга сәләтле бу аждаһа нindирәк кыяфәттә икән? Әмма күргән кешеләрнең сөйләвенә караганда, Гессның тышкы кыяфәте бер дә алай коточарлык, куркырлык түгел, ди. Хәзер ул тоныкк күзле, бик бетешкән хәлсез бер карт икән. Вөҗдан газабы кичереп тә азапланмый, күрәсең. Борчылганы бер дә сизелми, диләр. Гадәтләнгән бер тәртип белән яши бирә: билгеләнгән вакытта йокыдан тора, билгеләнгән вакытта иртәнге, төшке һәм кичке ашларны ашый, билгеләнгән вакытта йокларга ята, ди.

Директор Лазаревны мин Муса Җәлилнең совет поэзиясе тарихындагы роле, миллионнарча укучыларның аңа мәхәббәте хакында кайнар нотык сөйләп каршыладым. Ләкин директорга нотык бернинди тәэсир ясамады кебек. Минем бөтен дәлилләремә каршы бер сүз белән җавап бирде: «Ярамый булгач, ярамый».

— Аңлагыз, — дим аптырагач, — әле яңа гына, элекке итальян тоткыны Рениеро Ланфредини ярдәме белән, шагыйрь утырган камераның номерын ачыкладык... Чыннан да...

— Яңа гына, имеш, — ди директор, борын җыерып. — Без моннан алты ел элек ачыкладык инде аны: Җәлил башта 157 нче номерлы камерада утыра, аннан 53 нче камерага күчерәләр...

Менә бу яңалык ичмасам! Ланфредини 53 нче камерада, чыннан да, Муса белән бергә утыра. Ә 157 нче камера хакында беренче ишетүем.

— Ә сез боларны кайдан белдегез?

— Төрмә архивындагы документлардан.


— Алар саклангганмыни?

— Үз күзләрем белән укыдым. Димәк, сакланган була инде.

— Һәм алар белән танышырга да мөмкинме?

---

[1] Врачлар аны психик авыру дип тапканнар, шуңа гына Гесс дардан котылып калган.



*1933—1945 елларда гитлерчылар меңнәрчә кешеләрне шушында җәзалап үтергәннәр.*

— Юк. Бөтен архивны Көнбатыш Берлин сенатына тапшырдык. Әлегрәк кызыксынырга иде...

— Әлегрәк... Кем уйлаган бит...

Күпме язып карадык, Көнбатыш Берлинның юстиция эшләре советнигы: «Шпандау төрмәсе документларында җәлилчеләрнең исем-фамилияләре теркәлмәгән», дип җавап бирә торды. Әгәр, директор раслаганча, төрмә архивы чыннан да исән икән, ниндидер өмет чаткысы кала әле: бәлки, җәлилчеләр турында яңа документлар килеп чыгар[1], бәлки, алар белән җәзаланган өч билгесез кешенең исем-фамилияләре ачыкланыр...

— Һич югы, Җәлил утырган камераларны үзегез бер карап-тикшереп чыгар идегез, — дим мин, бирешергә теләмичә. — Бәлки шагыйрьнең васыяте яки шуныңише бераз язу калгандыр.

— Карадылар һәм берничә тапкыр. Берни дә табылмады. Булган очракта да, алар хәзер күпьеллык сөрем, дым һәм тузан астында калган. Күп урыннарда штукатур җимерелгән. Юк, хәзер бик соң инде.

Соңгы чиктә әлеге камераларның рәвешләрен ачыкларга тырышып карыйм. Директор иңнәрен генә җыера. Бөтен камералар бер төсле үк. 2 м $\times$ 3 м зурлыгындагы бүлмә. Цемент идән. Штукатурланган кирпеч стеналар. Өстә 80 см $\times$ 100 см зурлыгындагы тәрәзә. Аңа беләк калынлыгындагы тимерләрдән, стенага кертеп, рәшәткә ясалган. Тимердән эшләнгән җыелма кроватьлар, идәнгә беркетелгән ике утыргыч. Тәрәзә турында аста бетон плитә, ул өстәл хезмәтен үти. Бер почмакта — бәдрәф. Камераның бөтен җиһазы әнә шулар...

## Европаның җәһәннәме

Яссы түбәле, кирпечтән эшләнгән тәбәнәк бина. Эчтән тимер япкычлар белән бикләнә торган рәшәткәле берничә тәрәзә. Капкалары каерып ташланган ике ишек урыны; алар, ни өчендер, янып торган крематорий мичләрен хәтерләтәләр. Плетцензее төрмәсенең ишек алдындагы шушы бәләкәй корылманы Европаның җәһәннәме дип йөртәләр. Гитлер рейхының политик тоткыннар өстеннән чыгарган суд карары шушында җиренә җиткерелгән. Тоташ стена белән барак икегә бүленгән.

[1] Андый документлар, чыннан да, табылды. Алар турында киләсе санда укыгыз.

Соры төстәге цемент идән, шома итеп штукатурланган стеналар һәм түшәм. Мәетләрдән аккан кан җиңелрәк юылсын өчен, стенаның бер өлешен ак кафель белән каплаганнар. Шул төшкә үк су краннары куелган. Стенага берничә тимер ыргак беркетелгән.

Шушы шыксыз залда фашизмның мактанычы һәм горурлыгы — камилләштерелгән механик гильотина торган. Бер кешене җәзалау өчен җиде секундтан унсигез секундка кадәр вакыт киткән.

Уртача — 11 секунд.

Тоткыннарны кан сеңеп һәм меңнәрчә корбаннар гәүдәсе белән шомарып беткән калын такталарга йөзтүбән яткырганнар да, агач кыскычлар белән муеннарыннан эләктереп куйганнар. Үткен итеп кайралган механик пычак сизелер-сизелмәс кенә селкенеп алган — өзелгән баш читкә тәгәрәгән. Миңа шулкадәресен дә сөйләделәр: җәлладларга хезмәт хакы кеше башыннан түләнә торган булган. Шуңа күрә алар гильотинада җәзалауны артыграк күргәннәр. Тиз дә, мәшәкатьсез дә. Җәлил шигырьләрен бөтен тирәнлеге белән мин менә шушында, Плетцензее төрмәсендә генә аңладым:


Соңгы җырым палач балтасына
Башны токан килеш язылa...

Әйе, шагыйрь җырларын палач балтасы астында язган. Юк, бу шигъри чагыштыру гына түгел, кырыс, рәхимсез чынбарлык.


Билгеле булганча, Дрезден шәһәренең II нче империя суды карары буенча, җәлилчеләрнең уникесе дә гильотинада җәзаланырга тиеш була. Ул чагында Юрытко Ланфрединига ни өчен татарларның барысын да астылар, дип сөйләде икән? Немец дусларыбыз ярдәме белән бу мәсьәлә дә ачыкланды.

Хикмәт менә нәрсәдә икән. Җәлилчеләрне 1944 елның 25 августында җәзаларга тиеш булалар. Ә 18 августта төрмәгә бомба эләгә. Җәзалау барагының бер өлеше җимерелә, гильотина сафтан чыга. Шуңа күрә август ахырларыннан сентябрь урталарына кадәр гильотинада җәзаланырга тиешле тоткыннарның барысын да асалар.

Баракның икенче яртысына чыгабыз. Ярым түгәрәкләп эшләнгән ике тәрәзәдән бүлмәгә тонык яктылык төшә. Элек монда дөм караңгы булган, тәрәзәләрне сугыштан соң гына тишкәннәр. Өстә бүлмәнең буеннан-буена корыч өрлек сузылган, аңа кыс-



*Плетцензее төрмәсендәге җәзалап үтерү урыны.*



*Плетцензее төрмәсендәге гильотина. Фашистлар тоткыннарның башларын шушында кискәннәр.*

ка-кыска чылбырлар беркетелгән, һәр чылбыр очында тимер ыргаклар, аста — кечкенә сәхнә сыман мәйдан: асу урыны. Аңа күтәрелү өчен баскыч ясалган булган. Асу урынын да, баскычларны да хәзер сүтеп ташлаганнар. Ул урында тере чәчәкләрдән үрелгән зур венок тора. Ал тестөге тюльпан яфраклары, әйтерсеңлә, кан тамчылары. 1943 елның 25 августында шушы цемент идәннәр буйлап Юлиус Фучик соңгы кат узган, тагын бер елдан Җәлилнең һәм аның иптәшләренең гомере өзелгән. Сөйләүләренә караганда, җәза алдыннан һәр тоткын соңгы өч теләген үтәргә хаклы булган. Төрмә руханиен чакырырга, туганнарына хат язарга һәм теләгән ризыгын сорарга. Ләкин җәлилчеләрне җәзалаганда, урта гасырлардан ук килә торган бу гадәтне саклап маташмаганнар — сугыш ахыры якынлашкан саен, җәлладларга эш арткан. Кая анда кәнителләнеп маташырга, тоткыннарның исем-фамилияләрен теркәп барырга да вакыт тимәгән.

Тоткыннарны ничек җәзалаганнар соң? Гитлер җәлладлары (аларның күбесе әле бүген дә исән, Көнбатыш Германиядә яши) бу турыда сөйләргә яратмыйлар, дәшми калуны артыграк күрәләр. Әмма 1944 елның 20 июлендә, Гитлерга һөҗүм оештыруда гаепләнүчеләрне җәзалаганда, Плетцензее төрмәсенә журналистлар һәм кинорепортерлар кертелә. Гитлер җәзалау процессын пленкага төшерергә куша. Шул хәлләрне үз күзләре белән күргән кешеләрдән берсенең хикәясе америка публицисты Р. Аленның «Дүртенче рейхтан Хойзингер» («Прогресс» нәшрияты. Мәскәү. 1967 ел) исемле китабында да китерелә.

«Без элек чын кабахәтлек, бозыклык һәм дәһшәтнең нәрсә икәнен белми идек, хәзер беләбез. Ул хәлләрне күргәч, чәчләр үрә торды, нәфрәттән тамаклар кипте. Әмма тынычланырга һәм барысын да рәттән сөйләп бирергә рөхсәт итегез.

...Чүпрәк-чапракларга киенгән, агач башмаклар сөйрәгән сигез кешене, үлемгә хөкем ителгән сигез мескенне керттеләр, һәм операторлар шул коточкыч финалны төшерә башладылар. Төрле планда төшерү өчен, аппаратлар залның төрле урыннарына куелган иде. Асу урыны күз камаштыргыч дәрәҗәдә якты. Озын һәм куркыныч ул урын алдан кара пәрдә белән капланган. Шуның каршына җәзаланучыларны тезеп куйдылар. Витцлебенны өстерәп «сәхнәгә» алып менеп киттеләр.

Башкалар көтә.

Беренче ыргак турында тукталып, фельдмаршалны бил тиңентен чишендерәләр... Муенына элмәклап ясалган фортепьяно кылы салдылар. Кылны тимер ыргак аша элек-

терел алдылар... Һәм икенче башыннан тартып, гәүдәсен югары күтәрделәр дә, кинәт ычкындырдылар, фельдмаршал түбән очып төште. Шулай байтак газаплагач, шыр ялангач калдырып чишендерделәр, аннан тагын асып куйдылар: җаны чыгып беткәнче, ул шулай җәфа чикте...

— Кешеләрне вәхшиләрчә газаплап буалар, — дип дәвам итә хикәяче, — тиз генә үләрлек тә булмасын, исән дә калмасын. Корбаннары озаграк җәфалансын өчен шулай эшлиләр. Кешеләр җиде, сигез, тугыз, аерым очракларда уникешәр минут үлә алмый асылынып торалар.

Хикәяченең тавышы үзгәрә. Куллары калтырый башлый, күзләреннән яшь ага. Ниһаять, ул дәвам итә:

— Көтеп торучылар, җәзалау процессын тулысынча күрмәсәләр дә, үлем ачысыннан газапланып җан бирүченең аякларын күреп торалар. Бу — көтеп торучыларны куркыту, аларга үлем сулышы өрү өчен кирәк. Шуның өчен дә пәрдә эшафотның аскы өлешен каплап бетерми. Мондый вәхшиләрчә җәзалауны Гитлер үзе, я булмаса Геринг яки Геббельс уйлап чыгаргандыр, мөгаен».


Шундый үлемне «елмаеп һәм ирләрчә каршылау» өчен күпме рухи көч, батырлык кирәк булгандыр. Кем белә, бәлки, нәкъ шуның өчен дә Юрытко җәлилчеләрне ничек җәзалауларын тәфсыйллап сөйләргә теләмәгәндер. Җәлилчеләр һәлак булып ярты сәгать үтүгә Ланфрединига татарларның бөтенесен дә астылар, ди ул. Соңга таба исә татарларны, ахрысы, аттылар бугай дип сөйли башлады. Мондый коточкыч үлем хакында сөйләп татар патриотларының туганнарын куркытмас өчен, төрмә попы аларны аттылар дип сөйләүне, бәлки, мәгъкульрәк күргәндер.



## «Кышны көтәм, йоклар өчен ябынып юрганын...»

Германиягә китәр алдыннан Әминә Җәлилова ире күмелгән җирдән бер уч туфрак алып кайтырга кушкан иде. Әмма җәлилчеләр күмелгән урынны, якынча гына булса да, ничек билгеләргә соң?

Плетцензее төрмәсенең каберлеге билгеле — ул Берлиннан көнбатыштарак урнашкан Дебориц дигән урында. Мин анда булдым. Биек булмаган койма, койма эчендә



*Бу залда гитлерчылар политик тоткыннарны асканнар.*

рәт-рәт булып сузылган каберләр. Кабер башларында кызыл кирпечләр. Аларда мәрхүмнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган һәм үлгән еллары күрсәтелгән. Исән чакта аларның һәрберсе үзенә бер характерлы, үзенә бер язмышлы кешеләр булгандыр. Зират тигезләгән: батырына да, куркагына да бер үк төсле кирпеч кисәге.

Урыны-урыны белән бер үк фамилия язылган 3—4, хәтта 7—8 кабер ташы очрый. Сөйләүләренә караганда, бер үк гаилә членнары икән. Еврейларны һәм коммунистларны, соңрак Гитлерга һөҗүм итүдә гаепләнүчеләрне шулай бөтен гаиләләре белән юк иткәннәр. Бер урында шундый унбер кабер санадык. Тикшерә торгач, алар ир белән хатын, аларның әти-әниләре, абыйлары, сеңелләре һәм балалары булып чыкты. Культуралы вәхшилек әнә шулай буладыр инде: башта соңгы кешесенә кадәр гаиләне үтереп чыкканнар, ахырдан, махсус җибәрелгән акча исәбенә, һәрберсенә таш яздырып куйганнар.

Бер генә кирпечне дә күздән ычкындырмаска тырышып, каберләр арасында байтак йөрдем. Ләкин Җәлил исеме дә, иптәшләре дә очрамады. Миңа хәтле Ш. Маннур белән Л. Небенцаль дә эзләп караганнар. Һәм шулай ук нәтиҗәсез. Л. Небенцаль шушы каберлектә гомере буе каравылчы булып торган немец картын эзләп тапкан. Карт биргә күмелгән кешеләрнең исем-фамилияләрен аерым журналга теркәп барган икән. Небенцаль үтенече буенча, журналын тагын бер тикшереп чыккан. Әмма җәлилчеләрнең исем-фамилияләре очрамаган.

Төрмә рухание Юрытко, татарлар күмелергә мөмкин булган урыннарның берсе рәвешендә, Зеебург тирын күрсәтте. Зеебург шәһәренең мэры Бригитта Свиерс ярдәмендә, мин ул урынны да эзләп таптым. Көнбатыш Берлин чиге буендагы тәбәнәк нарат урманы артында кечерәк кенә тигез урын бар. Хәзер аны сөргәннәр. Кайчандыр монда чәнечкеле тимер чыбык киртә белән әйләндереп алынган участок булган. Шәһәр халкын ул тирәгә якын җибәрмәгәннәр, якын барырга ярамый, атарга өйрәнә торган җир, дип аңлатканнар. Билгеле, күпләр аның нинди тир икәнен яхшы аңлаган. Төннәрен монда ябык машиналар килгән. Мылтык тавышлары ыңгырашулар, ләгънәт авазлары белән чиратлашкан.

Сугыштан соң монда үле гәүдәләр белән тулы зур чокырлар табылган. Махсус комиссия чокырларның берсен ачып та караган. Гади киемдәге гәүдәләр арасыннан, немец офицеры мундирындагы берничә мәет тә чыккан. Ихтимал, болар Гитлерга һөҗүм итүчеләр булгандыр.

Чокырлар хәзер куаклыклар белән капланган, каберләр өстенә яшь чыршылар, наратлар үскән. Монда кемнәрне күмгәннәр? Шушында атылганнарны гынамы, әллә башка урыннарда җәзалаганнарны да китергәннәрме? Бу кадәресен Бригитта Свиерс та белми. Әмма ул белешергә һәм хәбәр итәргә вәгъдә биргән иде. Чыннан да, ярты ел узмады, мин аннан хат алдым. Зеебург тиры Шпандау төрмәсенә караган булган икән. Кагыйдә буларак, Шпандау тоткыннары, кайда үтерелүләренә һәм ничек үтерелүләренә карамастан, шушында күмелгәннәр. Димәк, җәлилчеләрнең кабере дә шунда булырга мөмкин...

Җәлилнең «Гөл кабере» исемле бер шигыре бар. Анда ул үзен үлем җәзасы көткәнлеге турында яза. Әмма тормышның дәвам итәчәгенә тирән ышанып, болай ди:

> **Сулган гөл күк мин дә кышны көтәм,**
> **Йоклар өчен ябынып юрганын,**
> **Күнелегездә көлеп чәчәк атар**
> **Минем соңгы йөрәк җырларым.**

◇◆◇

Ибраһим Нуруллин

# МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК РЕАЛИЗМЫ ТУРЫНДА

КПССның XX съездыннан соң, аеруча А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты каршында реализм проблемаларына багышланган дискуссия булып үткәч, әдәбият фәнендә, шул исәптән татар совет әдәбият белемендә, иҗат методлары һәм юнәлешләре белән кызыксыну арта башлады. Әдәбият тарихын иҗтимагый фикер тарихының иярчене генә итеп карауга чик куярга һәм аны үз эчке закончалыкларыннан чыгып яктыртырга омтылуның бер күренеше иде бу. Х. Госманның «Бөек Октябрь социалистик революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе» һәм «Егерменче елларда татар поэзиясе» исемле күләмле хезмәтләрендә, Г. Халитның «Тукай һәм аның замандашлары» һәм «Революция тудырган геройлар» (икесе дә рус телендә) монографияләрендә, Х. Хәйринең «Социалистик реализм мәсьәләләре» һәм М. Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов» исемле китапларында реализм һәм романтизмга караган мәсьәләләр күтәрелә һәм күп кенә яктан яңача хәл ителә.

«Казан утлары» журналының узган елгы 8 санында Г. Халитның «Романтизмны һәм реализмны яклап» исемле мәкаләсе басылып чыкты. Мәкаләнең әһәмияте иҗат методы һәм юнәлешләрен ныклап торып өйрәнүгә чакыру белән генә чикләнми. Тәнкыйтьче татар совет әдәбиятында социалистик реализмның формалашу үзенчәлеге, бу процесста критик реализм һәм романтизм традицияләренең роле турында кызыклы һәм нигезле фикерләр әйткән. Автор социалистик реализмның формалашу процессын, каршылыклы тенденцияләргә күз йоммыйча, бөтен катлаулылыгында яктыртырга чакыра, бу өлкәдәге хезмәтләрдә урын алган гадиләштерү һәм догмаларны тәнкыйть итә.

Билгеле бер әдәбиятта социалистик реализмның формалашу үзенчәлекләрен ачу өчен иң элек шушы чор әдәби материалын өйрәнергә кирәк. Ләкин шул ук вакытта әдәби мирасны, аерым алганда элеккеге иҗат методы һәм юнәлешләрен, тикшерми торып, бу бурычны тулысынча үтәп чыгу мөмкин түгел. Мәгълүм булганча, күпчелек әдәбиятларда социалистик реализм эстафетаны критик реализм кулыннан алды. Шуның белән бергә, яңа чор әдәбияты кайбер бүтән иҗат юнәлешләренең, аерым алганда романтизмның, уңай казанышларын да үз тәненә сеңдерде. Әгәр социалистик реализмның беренче адымнары турында сүз йөртергә телибез икән, безгә, димәк, критик реализмның һәм башка методларның табигатен һәм характерын бик яхшы белергә кирәк. Кызганычка каршы, нәкъ шушы өлкәдә буталчыклар тулып ята.

Шактый киң таралган хаталарның берсе, әгәр шулай әйтергә яраса, критик реализмның сферасын артык киңәйтүгә кайтып кала. «Критик реализм» термины гамәлгә керүдән башлап соңгы елларга кадәр, мәсәлән, безнең татар совет әдәбият белгечләре татар әдәбиятында критик реа-

лизм XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килде дигән карашта тордылар [1]. Өстән караганда, болай дип раслауга нигез дә бар шикелле. Ул чор татар әдәбиятында яңа тип проза — повесть һәм роман жанрлары барлыкка килде, драматургия туды. Әмма, шуңа да карамастан, соңгы елларда әлеге караш, ягъни татар критик реализмының яралуын XIX гасырның икенче яртысына кайтарып калдыру, шик астына алына башлады. Кайбер әдәбият белгечләре XIX гасырда һәм XX гасыр башында өстенлек иткән иҗат методлары арасындагы аермага игътибар иттеләр һәм беренчесенә исем эзли башладылар. Ниһаять, тиешле термин да табылды: мәгърифәтчелек реализмы [2].

Критик реализм төшенчәсе белән саксыз эш итүнең ярамаганлыгын күрү өчен, бу иҗат методының асылын искә төшереп китик. Критик реализм баскычын үткән әдәбиятларның тәҗрибәсе һәм әдәбият фәненең соңгы казанышлары безгә болай ди: критик реализмның төп билгесе кешене тирәлеккә, ягъни социаль-экономик һәм иҗтимагый-политик мөнәсәбәтләргә бәйләп күрсәтүгә, дөресрәге, шуның җимеше итеп сурәтләүгә кайтып кала. Әдәбият критик реализм баскычына күтәрелсен өчен кимендә түбәндәге өч шарт кирәк: яшәп килүче җәмгыятьтәге каршылыкларның сизелерлек дәрәҗәгә җитүе; әдәбиятның элеккеге чорларында күпмедер реализм традицияләренең булуы; иҗтимагый һәм эстетик фикернең, шулай ук иҗтимагый фәннәрнең билгеле бер дәрәҗәгә ирешкән булуы (җәмгыятьнең эчке табигатен һәм закончалыкларын ачып салып, ахыр чиктә аны инкарь итәргә этәргеч ясарлык дәрәҗәгә). Җыеп әйткәндә, критик реализм — кешеләрдә гомумән табыла торган аерым кимчелекләрне генә түгел, бәлки яшәп килүче иҗтимагый тәртипләрнең үзләрен тәнкыйтьли торган, изүче стройның нигез ташларын какшата торган реализм ул.

Без соңрак күребез: XIX гасырның икенче яртысындагы татар мәгърифәтчелек әдәбияты бу таләпләргә җавап бирә алмый иде әле. Әнә шул әдәбиятның иҗат методын ачыклау юнәлешендә эшләүче галимнәр, һичшиксез, дөрес юлдан баралар. Ә менә кайбер тугандаш халыкларның, аерым алганда Урта Азия республикаларының, әдәбиятчылары һаман әле «критик реализм» терминына ябышып яталар. Мин бередә төрки телендәге әдәбиятларның мәгълүм чорларын үлчәүгә салырга һәм бер-берсенә каршы куярга җыенмыйм. Әйтергә теләгәнем шул гына: үз әдәбиятларының XIX гасырга караган чорларында ук критик реализм күрергә теләгән иптәшләрнең дәлилләре ышандырмый. Голәм Кәримов, мәсәлән, XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башы үзбәк әдәбиятын күздә тотып, болай ди: «...анарда критик элемент, сатира барлыкка килде, аның реализмы критик характер алды» [1]. Үзбәк телендә чыккан китабында исә бу чор әдәбиятының иҗат методын ул ачыктан-ачык критик реализм дип атый [2]. Әмма Г. Кәримов үзе ук XIX гасыр ахыры һәм XX йөз башы үзбәк әдәбиятында яңа тип проза һәм драматургия юк иде, дип белдерә. Поэзиядә исә, дип яза ул, «шаблон сурәтләү чаралары, риторика, үткән заман әдәбиятының аерым формаль алымнары хакимлек итә, поэзия әле үзенең «реалистик эчтәлегенә туры килерлек яңа формаларны тудыра алмаган иде» [3]. Күренә ки, Г. Кәримов үзенә-үзе каршы килә.

Казакъ әдәбияты белгечләре критик реализм аттестатын бирүдә шулай ук юмартлык күрсәтәләр, аларның дәлилләре шулай ук ышандыра алмый. Казакъ әдәбияты тарихын өйрәнү эшенә зур өлеш керткән З. С. Кедрина Абай белән Алтынсаринны — ә боларның иҗаты XIX гасырның икенче яртысына карый — ничаклы критик реализм вәкилләре итеп күрсәтергә тырышмасын, ахыр чиктә, реверанслар ясыйясый булса да, мондый нәтиҗәгә килә: «Әнә шул хәл (үгет-нәсихәтчелекнең көчле булуы — И. Н.) революциягә кадәрге ка-

---

[1] Кара: Л. Җәләй. Татар драматургиясенә алтмыш ел тулу уңае белән («Совет әдәбияты» журналы. 1947 ел. 11 сан); Татар әдәбияты. XX йөз. Дәреслек хрестоматия. Төзүчеләре М. Гайнуллин һәм Җ. Вәзиева. 1947 ел. 435 бит; Х. Хәйри. Татар әдәбияты тарихын өйрәнү мәсьәләләренә карата («Совет әдәбияты» журналы. 1955 ел. 11 сан); К. Ф. Фасеев. Из истории татарской передовой общественной мысли. Таткнигоиздат. 1955 ел. 48—49 битләр; Х. Мөхәммәтов. Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеяләре. Таткнигоиздат. 1961 ел. 53, 55, 122 битләр.

[2] История татарской советской литературы. Рус телендә. «Наука» нәшрияты. 1965 ел. 18 бит.

[1] Вопросы узбекской литературы. Ташкент. 1959 ел. 353 бит.

[2] Г. Кәримов. Узбек адебиети тарихи. Ташкент. 1966 ел. 56 бит.

[3] Вопросы узбекской литературы. 353 бит.

закъ әдәбиятында критик реализм метод буларак туып өлгерде дип расларга мөмкинлек бирми»[1].

Ф. Касыйм-задә, рус әдәбиятыннан үрнәк алып булса кирәк, әзербайҗан әдәбиятында критик реализмның формалашуын хәтта XIX гасырның беренче яртысына күчерә. Әмма шул ук вакыт бу чор әзербайҗан әдәбиятында, дип яза ул, «феодаль-крепостнойлык мөнәсәбәтләренең нигезләре тәнкыйть ителмәделәр»[2]. Чынбарлыкның иң мөһим якларын ачмый торган һәм, димәк, җәмгыятьнең нигезләренә кагылмый торган критик реализмны, әлбәттә, күз алдына китерү кыен.

Үз әдәбиятыбызга кайтыйк.

XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятында критик реализмның әле формалашырга өлгермәгәнлегенә тәмам ышану өчен, ул чорда иҗат иткән прогрессив язучыларның иҗат принципларын һәм бу принципларны билгеләүче факторларны күздән кичерергә кирәк. Бу күзәтү шулай ук XIX гасыр ахыры һәм 1905 елгы революция алды елларында өстенлек иткән иҗат методының асылы нидән гыйбарәт? Ул методны мәгърифәтчелек реализмы дип атау дөресме? сорауларына җавап бирәчәк.

Мәгълүм булганча, XIX гасырның икенче яртысында татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм мәгърифәтчелек идеологиясе формалашты. Әмма ул Белинский, Чернышевский һәм Добролюбов исемнәре белән бәйле революцион-демократик эчтәлекле мәгърифәтчелек түгел иде. Әгәр шулай әйтергә яраса, моралистик мәгърифәтчелек иде ул. Татар мәгърифәтчеләре җәмгыятьне үзгәртеп коруның төп коралы итеп мәгърифәтне алга сөрделәр. Алар фикеренчә, мәгърифәт чаралары ике зур эш башкарырга тиеш. Беренчесе — фәнни-техник прогресска булышу; икенчесе — кешеләрнең аң һәм гамәлләренә югары әхлак нормаларын сеңдерү. Әнә шул караш мәгърифәтче язучыларның әдәби-эстетик карашларын да билгеләде.

Безнең мәгърифәтчеләр әдәбиятның ролен ничек аңладылар, аның бурычын нәрсәдә күрделәр соң? Бу сорауга җавап бирүдә безгә А. М. Горький ярдәмгә килә. XVIII гасыр рус мәгърифәтчелек әдәбиятын күздә тотып, бөек әдип болай дигән иде: «Әдәбиятка педагогик күзлектән карау, аны әхлак төзәтү, кешене тәрбияләү чарасы итеп санау факты бозык әхлакны фаш итә торган комедияне әдәбиятның бүтән төрләреннән алгарак кую һәм Екатерина заманасында чыккан тәрҗемә һәм оригиналь мәсәлләрнең гаять күплеге белән дә раслана»[1].

Әдәбиятның иҗтимагый роле мәсьәләсендә татар мәгърифәтчеләре 1905 елга чаклы нәкъ шул караштa тордылар. Күп дәлилләрнең берсен генә китерәм. З. Һади үзенең «Бәхетсез кыз» хикәясен язарга керешү сәбәбен түбәндәгечә аңлаткан иде: «Шул фаҗигале вакыйгалардан (тормышта булып тора торган вакыйгалардан — И. Н.) беренә охшатып, бер хикәя тасвир идеп, хөрмәтле укучыларыбызга тәкъдим идәрем... Яман эшләрнең яманлыгы күз алдында күрелгән кебек күренер, укучы егетләр вә кызлар гыйбрәт алып, начар эшләрдән сакланып, яхшылыкка мәхәббәтләре артыр, х о л ы к л а р ы т ө з ә л е р (ассызык минеке — И. Н.), дип өмет иделер»[2].

XIX гасырның икенче яртысында формалашкан иҗтимагый һәм эстетик фикер кешенең җәмгыятьтәге урынын, аның тирәлеккә бәйләнешен аңлауда каршылыклы концепциягә китерде. Мәгърифәтче язучылар, бер яктан, тәрбия максатыннан чыгып, барлык җаваплылыкны кешенең үз өстенә салырга, кешенең бәхете яки бәхетсезлеге аның үзеннән, белем һәм әхлак дәрәҗәсеннән килә дип белдерергә тиеш булдылар. Икенче яктан исә, алар кешене тәрбия җимеше итеп карыйлар һәм, димәк, тирәлекнең ролен азмы-күпме таныйлар иде. Бу концепциянең беренче ягы язучыларны үгет-нәсихәткә, дидактизм һәм рационализмга этәрсә, икенче ягы исә реализмга таба әйди иде.

Мәсьәләнең әнә шул ике ягына конкретрак тукталып, башта мәгърифәтче язучыларның кеше образларын тудыру һәм сюжет кору принципларын карап китик. Аларның уңай геройлары, мәсәлән, кагыйдә буларак, һәр яктан килгән, житеш һәм камил. Муса Акъегет-задәнең «Хисаметдин менла» (1886) повестеннан Хисаметдин, Гайса Зурколаков һәм Әбүзәр бәк,

---

[1] Социалистический реализм в литературах народов СССР. Фәннәр академиясе нәшрияты. 1962 ел. 304 бит.

[2] Очерки по истории азербайджанской литературы XIX века. Азгосиздат. 1962 ел. 24 бит.

[1] А. М. Горький. История русской литературы. Гослитиздат. 1939 ел. 14 бит.

[2] З. Һади. Сайланма әсәрләр. Таткнигоиздат. 1957 ел. 73 бит.

Г. Ильясиның «Бичара кыз» пьесасыннан Җанбай, З. Бигиевның «Гөнаһы кәбаир» (1890) романыннан Җиһангир, Г. Камалның «Бәхетсез егет» (1899) пьесасыннан Әхмәт һәм Гайшә, Ш. Мөхәммәдовның «Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе» повестеннан Гали Акчурин, З. Һадиның «Бәхетсез кыз» һәм «Җиһанша хәзрәт» әсәрләреннән Гайшә, Габбас, Хәсән мулла һ. б. персонажлар моңа мисал була алалар.

Мәгърифәтче язучыларның тискәре персонажлары исә чагыштырмача җанлы һәм тормышчанрак. Әмма бу персонажларның да күбесе берьяклылык һәм схематизмнан бөтенләй ук азат түгелләр. Язучылар кешеләрдә очрый торган күп кенә әшәке сыйфатларны тискәре персонажларга җыеп, туплап бирергә омтылалар. Мәсәлән, «Бичара кыз»дагы Җантимер аңгыра, аңгыра гына да түгел, ямьсез, ямьсез генә дә түгел, әчкече. Тискәре образларның ышандыру көче төрле дәрәҗәдә булса да, шул ук хәлне без телгә алынган барлык әсәрләрдә дә очратабыз. Менә З. Бигиевнең Габденнасыйры һәм бертуган Галиевләрс, М. Акъегетнең Сибгатулласы, Ш. Мөхәммәдовның Галиәкбәр бае һәм байбәтчә Хәсәншасы («Яфрак асты...»), Р. Фәхретдиновның Хикмәт хаҗие («Әсма») һәм З. Һадиның Ибәт абзагае («Бәхетле кыз»), Җиһанша хәзрәте һ. б.

Кыскасы, персонажларны тап икегә — уңай һәм тискәрегә бүлү, беренчеләренә ал, икенчеләренә кара буяуларны мул куллану — мәгърифәтче язучыларның кеше образы тудыру принциплары өчен менә нәрсә характерлы.

Сюжет кору принципларына килгәндә исә, барыннан да элек күзгә ташланган нәрсә шул: тискәре һәм уңай персонажлар арасындагы конфликт, кагыйдә буларак, соңгыларының җиңүе белән хәл ителә. Уңайлар тантана итә, ә тискәреләр я хурлыкка кала, яисә язмышлары фаҗига белән очлана. Югарыда саналган әсәрләрнең барысында да без шуны күрәбез.

Ни өчен шулай, ни өчен яхшылар бик яхшы, начарлар бик начар итеп күрсәтелә дә, яхшылар өскә чыгарыла? Хикмәт, алда әйтелгәнчә, мәгърифәтче язучыларның әдәбиятны әхлакый тәрбия чарасы итеп карауларында. Уңай персонаж — үрнәк өчен, ә тискәре персонаж гыйбрәт өчен тәкъдим ителгән шикелле, конфликтның чишелеше дә әхлак дәресе хезмәтен үти. Авторның әйтергә теләгәне шул: надан һәм әхлаксыз булсагыз, сезне дә әнә шулай хурлык яисә бәхетсезлек көтә. Күренә ки, без бирегә ярылып яткан дидактизм белән очрашабыз. Критик реализм «аттестаты» өләшүдә артык юмартлык күрсәтә торган әдәбиятчылар игътибарына шуны әйтәсе килә: әгәр XIX гасыр һәм 1905 елгы революция алды елларында иҗат иткән мәгърифәтче язучыларның иҗат методы әнә шул принциплардан гына торса, бу чорда критик реализм гына түгел, бәлки бернинди реализм да табып булмас иде. Бәхеткә каршы, кеше концепциясенең югарыда әйтелгән икенче ягы бу чор язучыларын реализмга таба этәрә иде. «Гөнаһы кәбаир» романы мисалыннан башлыйк. Әсәр, билгеле булганча, ике сызыктан бара: берсе Габделгафур шәкертнең тормыш төбенә төшү тарихы, икенчесе исә — сәүдәгәр хатыны Маһруйның юлдан язуына кагылышлы вакыйгалар.

Бу очракта Габделгафур тарихы аеруча характерлы. Башта язучы үз героеның әтисе турында кайбер мәгълүматлар бирә... Бу мулла дин кушканнарны үзе теләгәнчә боргалый, ришвәт ала, зур процент белән бурычка акча бирә һәм ике хатын белән тора икән. Димәк, Габделгафур үз өендә бик үк шәп тәрбия алмаган була. Казанда укый башлагач, Габделгафур, бозык шәкертләр тәэсирендә, акрынлап эчкелеккә бирелә һәм ахыр чиктә мәдрәсәдән куыла. Соңрак аферист һәм жулик Мәмәт белән бергә чиркәү басканда тотыла һәм төрмәгә эләгә.

Күренә ки, Габделгафурның түбәнлеккә төшүе — тирәлек нәтиҗәсе. Әмма тирәлек дигәнебез гаилә һәм мәдрәсә белән генә чикләнә. Татарларда укыту-тәрбия эшенең начарлыгын күздә тотып, З. Бигиев публицистик чигенештә үзе дә бу турыда әйтеп китә: «Габделгафур мәдрәсәя кәлән вакытта бәйлә шореб хәмер[1] идемү? дәю сөалә, әлбәттә: «Юк, юк! Мәдрәсәя кәлән вакытта бер дә андай нәмәрсәләрне белмәй иде. Мәдрәсәдә аракы эчәргә үгрәнде» җавабы вирермез».

«Хисаметдин менла» повестенда мәктәп тәрбиясе төп мәсьәлә итеп куелмаган. Шулай да автор, җае чыккан саен, тәрбиянең әһәмиятен искә төшерә тора. Шул ук Гайсаны алыйк. Ул бәр яктан да килгән, һәркемгә үрнәк булырлык эш кешесе, милләт дигәндә үлеп тора. Мондый сыйфатларга ия булуы белән ул кемгә яисә нәрсәгә бурычлы соң? Әлбәттә, тәрбиягә.

---

[1] Шореб хәмер — аракы эчүче.

Барыннан да элек әнисенә — бөтен шәһәр халкының хөрмәтен казанган изге хатынга. Мәрхүм этисе дә мактауга лаек кеше булган. Ул Гайсаны «мөселманча» һәм русча укыткан. Шуның өстенә Гайса соңрак фән һәм техникага караган рус китапларын үзлегеннән укып үзләштергән. Шунысы бик тә кызыклы һәм игътибарга лаеклы: мәгърифәтчелек әдәбиятында уңай геройларның ата-аналары, кагыйдә буларак, изге җаннар, идеаль кешеләр, ә тискәре персонажларныкы — бозык һәм наданнар. Әгәр дә З. Бигиев Габделгафурның этисенә Нәкәс (кешелексез) дигән исем биргән булса, хыянәт иткән хатынын кичерергә сәләтле, яхшы күңелле сәүдәгәр Җиһангирның этисен «алтмыш яшенә йитмеш яхшы карттыр» дип бәяли. Яисә Ш. Мөхәммәдовның «Җәһаләт яки Галиәкбәр агай» (1900) повестендагы ата белән аның улын алыйк. Галиәкбәр агай сәүдә эшендә фән казанышларына таянмавы һәм көне-төне типтереп йөрүе сәбәпле ахыр чиктә бөлә. Улы Миңлебай исә, кафе-шантаннарда исәпсез акча туздырып, атасына нык кына «булыша». «Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе» повестенда да шул ук хәл. Иске фикерле надан байның улы Хәсәнша — әлеге Миңлебайның икенче сыңары. Шул ук вакытта яшь булса да, милләт өчен күп нәрсә эшләгән идеаль капиталист — завод хуҗасы Гали Акчуринның этисе турында түбәндәгеләрне укыйбыз: «Сабынчы Муса агай үзе простой булса да, гакылы камил бер әдәм иде. Күп еллардан бирле сабын эшләп, унбиш мең тәңкә акча ясаган иде. Бердәнбер углы Галине әүвәл бик яхшы мәдрәсәдә мөселманча укытып, гимназиягә бирде». Р. Фәхретдиновның «Әсма» (1903) повестендагы мәкерле һәм усал Хикмәт хаҗиның улы начар авырудан үлә. Повестьның төп герое Әсма исә бозыклык базыннан да кер кунмаган хәлдә чыга. Чөнки ул идеаль ананың — кайчандыр әхлак ягыннан аксаштыргалаучы ирен дә чын кеше итә алган изге ананың кызы.

Кешенең формалашуын нигездә мәктәп һәм гаилә белән чикләнә торган тирәлеккә бәйләп күрсәтү З. Һади иҗатында аеручa калку гәүдәләнде. «Җиһанша хәзрәт» повестенда З. Һади, тирәлекнең роленә кагылып, түбәндәгеләрне әйтә: «Бала туган вакытта чын кеше булыр, кеше булуны теләр, ата-анасында инсаният[1] булмаса, баланың да инсанияте югалыр. Һәр нәкадәр инсан булмак юлында иҗтиһад итсә дә[1], юл күрсәтүчеләр булмаса, юлында адашыр да, нә инсан вә нә хайван улыр». Әнә шул караш З. Һади иҗатының буеннан буена кызыл җеп булып сузылып бара. Бу караш аның әсәрләренең формасына да тәэсир итми калмаган. Язучы гадәттә үз геройларының тормыш юлын, бала чак яки үсмер чакларыннан ук алып, картлык көннәренә, кайчакта исә үлемнәренә кадәр сөйләп чыга. Аннан килеп, барлык мәгърифәтчеләрдәге кебек үк, З. Һадиның уңай геройлары, кагыйдә буларак, әхлаклы һәм чагыштырмача мәгърифәтле ата-ана балалары. Дөрес, Гайшәнең атасы («Бәхетле кыз») — начар холыклы, надан һәм фанатик бер кеше. Аның каравы, анасы — изге хатын. Ул «гыйлем әһлене бик сөя» торган дәүләтле генә кешенең кызы булган икән. Бу кеше «гаять тә гүзәл вә нәфисә, күркәм холыклы, ачык йөзле» кызын тәрбияләү өчен өендә тол остазбикә асраган. Безнең Гайшә — әнә шундый хатынның тәрбия җимеше. Габбасның анасы да — «остабикәлекка ярарлык» хатын. Әнә шул хатын «Биктимер агайга насыйп булып, Габбасның вөҗүденә вә тәрбияле булуына сәбәп булган».

Башлангыч тәрбияне гаиләдә алган егет белән кыз соңыннан, зур тырышлык нәтиҗәсендә, һәр яктан килгән гүзәл кешеләр булып җитешәләр.

«Бәхетсез кыз» (1904) хикәясендәге Хәнифә исә, намусын саклап кала алмыйча, күп михнәтләрне башыннан кичерә һәм ахырда үзен-үзе үтерә. Кем гаепле? Хикәядән күренгәнчә, әнисе гаепле. Яшьлегендә сөю-сөешү мәсьәләләрендә шактый талымсыз булган бу хатын, кызын ялгыш адымнан саклыйсы урында, үзе үк егет белән кызга яшерен рәвештә очрашыр өчен шартлар тудыра.

Яисә менә «Мәгъсүм» (1905) повесте. Героебызның атасы турында әсәрдә мондый мәгълүмат бирелә: «Фәхри хәзрәт егет табигатьле, баһадир кыяфәтле, ачык йөзле, татлы сүзле, һәр нәрсәдән хәбәрле, вәгазьнәсихәте бик әсәрле, һәр эшендә тәдбирле[2] бер зат иде». Остазбикә — шулай ук изге җан. Ул, ире вафат булгач, барлык гомерен Мәгъсүмне тәрбияләп үстерүгә багышлый. Менә Хәят абыстай үзенең кадерле улын — исеменә лаеклы малайны[3] — зур мәдрәсәгә

---

[1] Инсаният — кешелек.

[1] Иҗтиһад итсә дә — тырышса да.
[2] Тәдбирле — уйлап эшләүче.
[3] Мәгъсүм — гөнаһсыз.

укырга җибәрә. Берничә ел эчендә мәдрәсә үз эшен эшли: тәүфыйклы, әдәпле яшүсмер акрынлап бозыла. Соңрак мәхәббәт мажаралары вакытында кыйналгач, мәдрәсәне ташлап авылына кайтып егыла, беркадәр авырып ята һәм үлеп китә.

Китерелгән мисаллар бер нәрсәне расдый: мәгърифәтчеләр эстетикасында реализмга хас тирәлек төшенчәсе бар икән. Дөрес, биредә бу төшенчәнең кысалары, күргәнебезчә, шактый тар. Әмма гаилә белән мәктәп «зур» тирәлекнең, ягъни кешене формалаштыра торган иҗтимагый мөнәсәбәтләр комплексының бер өлеше булып тора.

Әнә шул иҗат методын билгеләү өчен, бездә «мәгърифәтчелек реализмы» термины кереп бара. Билгеле, без уйлап чыгарган төшенчә түгел бу. Рус әдәбият белемендә «мәгърифәтчелек реализмы» термины инде гражданлык хокукы алды. Моңа ышану өчен, берничә галимнең фикерләрен китереп үтү файдалы булыр.

Көнбатыш Европа әдәбиятларын күздә тотып, С. М. Петров, мәсәлән, болай дип яза: «Мәгърифәтчелек реализмы кешенең иҗтимагый тирәлек тудырган аның шул тирәлеккә бәйләп карый. Ләкин XVIII гасыр реалист язучыларның тасвирында, шулай ук ул гасыр философларының карашларында, тирәлекнең үзен фикер идарә итә, ягъни һаман шул ук нәрсә — кеше мие» [1]. Икенче төрле әйткәндә, биредә дә тирәлек төшенчәсе экономик һәм социаль мөнәсәбәтләргә түгел, бәлки өскорма күренешләренә һәм идеологик факторларга кайтып кала.

«Мәгърифәтчелек реализмы, — дип яза Н. А. Гуляев, — бөтен дөнья реалистик сәнгатенең бер этабы ул». Аннары дәвам итә: «Мәгърифәтчеләр гадәттә үзләренең геройларын экономик бәйләнешләрдән аерып күрсәтәләр, аларны рухи яктан, күбесенчә, әхлак ягыннан гына тасвирлыйлар. Дөрес, еш кына, бигрәк тә Фильдинг һәм Смолетт романнарында кеше тарихи конкрет сурәтләнә, социаль шартлар белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә. Әмма «тирәлек» үзе тар алына, ул кагыйдә буларак кешеләрнең гаиләви һәм әхлакый мөнәсәбәтләренә кайтып кала» [2].

Я. Эльсберг, тирәлекнең ролен күз уңыннан ычкындыра төшсә дә, мәгърифәтчелек әдәбиятының бер сыйфатын дөрес билгели: «Мәгърифәтчеләрнең игътибар үзәгендә кешенең үзен чолгап алган әйләнә-тирә белән бәйләнеше түгел, бәлки тәрбия проблемасы тора» [1].

Күренә ки, рус теоретиклары реализм үсешендәге бер этапны мәгърифәтчелек реализмы дип атау белән бергә, аның төп билгесен кешене өскорма күренешләрен генә эченә алган тирәлек белән, башлыча гаилә мөнәсәбәтләре һәм җәмгыятьнең әхлакый нигезләре белән бәйләп тасвирлауда күрәләр.

XIX гасыр ахры һәм 1905 елгы революция алды еллары татар әдәбиятында да без нәкъ шушы хәлне күрдек. Бу чор татар әдәбиятында өстенлек иткән иҗат методын мәгърифәтчелек реализмы дип атауның хата булмаячагына шаять шик калмагандыр.

Шушы урында нокта куярга да мөмкин булыр иде, әмма мәсьәләнең тагын бер ягы бар әле. Язучының нияте белән ул тудырган әсәрнең эчтәлеге һәм объектив әһәмияте арасына тигезлек билгесе куярга ярамаган шикелле, мәгърифәтчелек эстетикасы белән мәгърифәтчелек әдәбиятын абсолют тәңгәл нәрсәләр итеп карау шулай ук мәсьәләне гадиләштерүгә китерер иде. Эш шунда ки, мәгърифәтче язучылар да бит тормыш материалы белән эш итәләр. Талантлы каләм иясенә эләккәндә ул материал мәгърифәтчелек иҗат принципларының чагыштырмача тар кысаларына сыеп бетмәве дә мөмкин. Теге яки бу персонажны тасвирлаганда, аның үз-үзен тотышын, эш-хәрәкәтен күрсәткәндә, язучылар кайчак, үзләре дә сизмәстән, чынбарлыкның хәлиткеч якларын эләктереп алалар, әйтик, кешенең язмышын билгеләүче төп факторга — экономик мөнәсәбәтләргә кагылып китәләр.

«Гөнаһы кәбаир» романындагы Ибраһим Галиев образы бу яктан гаять кызыклы. Карап торышка бу кеше һич тә явыз түгел. Әмма ул Маһруйның Якуптан булган баласын үтертә. Ник дигәндә, әнесе Якуптан калган мираска шушы бала варис булыр дип курка ул. Бу инде критик реализмның тавыш бирүе. Андый очракларны «Хисаметдин менла» һәм «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә», «Яфрак асты...» һәм «Яңа әсхәбе кәһәф» кебек әсәрләрендә дә табарга мөмкин.

---

[1] С. М. Петров. Реализм. «Просвещение» нәшрияты. 1964 ел. 84 бит.

[2] «Филологические науки» журналы. 1966 ел. 2 сан. 167 һәм 169 битләр.

[1] «Вопросы литературы» журналы. 1958 ел. 5 сан. 101 бит.

Ләкин XIX гасыр ахры һәм 1905 елгы революция алды еллары татар әдәбиятында тирәлек төшенчәсенә экономик факторларның үтеп керүе гомуми кагыйдәдән чыгарма гына булып тора. Мондый очракларны критик реализм элементлары гына итеп карарга туры килә.

Шулай итеп, беренче рус революциясенә кадәр татар әдәбиятында критик реализм метод һәм юнәлеш буларак формалаша алмады. Чөнки моның өчен шартлар өлгереп җитмәгән иде. Беренчедән, ул чакта реализм традицияләре җитәрлек түгел иде әле. XIX гасырда, әдәбиятны дин кочагыннан тартып алып, тормышка, социаль мәсьәләләргә таба борып кую бурычы гына көн тәртибендә тора иде. Мәгърифәтчелек реализмы, шул бурычны үтәп, критик реализмга мәйдан әзерләде, әдәбиятның яңа биеклеккә күтәрелүе өчен баскыч булып хезмәт итте. Икенчедән, җәмгыятькә тарихи күзлектән карауга, аның үзен өйрәнүгә, әйдәүче көчләре турында уйлануга этәрә торган иҗтимагый фәннәр, аерым алганда тарих, татарларда әле тиешле югарылыкка күтәрелеп җитмәгән иде. Өченчедән — бусы аеруча әһәмиятле — иҗтимагый һәм эстетик фикернең торышы ул чорда җәмгыятьнең нигезләренә тәнкыйть күзе белән карау өчен стимул бирә алмый иде. Мәгърифәтчелек эстетикасы исә, билгеле бер үсеш баскычында критик реализм өчен җирлек әзерләсә дә, тора-бара аның принциплары үгет-нәсихәтчелек һәм рационализмга таба этәргәнгә, әдәбиятның критик реализм югарылыгына күтәрелүен тоткарлый башлады. Димәк, иҗтимагый һәм эстетик фикердә яңа адым ясарга кирәк иде.

1905—07 еллардагы революция барышында һәм аннан соң татарлар тормышында әнә шул шартлар өлгереп җитте һәм үткән чорның критик реализм элементларына, һәм гомумән, мәгърифәтчелек реализмының уңай казанышларына таянып, рус классик әдәбиятыннан ярдәм алып, татар критик реализмы формалашты, метод һәм юнәлеш буларак ныгый, үсә башлады.

Ахыр килеп, бер сәер хәл турында да әйтми булмый. Мәгърифәтчелек реализмы төшенчәсе әдәбият белемендә, аеруча Урта Азия республикалары һәм Әзербәйҗанда шушы көнгә кадәр чын-чынлап гамәлгә кертелгәне юк. Ә бит феодализм таркала барып, капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша башлау дәвере өчен характерлы метод бу! Критик реализм төшенчәсенә җиңел карап, аны урынсызга тарткалап йөртүдән ваз кичәргә һәм «мәгърифәтчелек реализмы» терминына гражданлык хокукы бирергә вакыт түгел микән?

Тагын шунысы аянычлы: әдәбият тарихын ясалма атка атландырырга омтылучы күп кенә әдәбиятчылар мәгърифәтчелек реализмы турындагы сүзләрне үз әдәбиятларын түбәнсетү рәвешендә кабул итәләр. Әйтерсең лә, бу метод ниндидер бер эшкә яраксыз нәрсә, әйтерсең лә, аның Дидро, Лессинг, Фильдинг, Смолетт, Фонвизин һ. б. кебек бөек әдипләре булмаган! Ә бит оялмаска, киресенчә, горурланырга кирәк иде. Чөнки мәгърифәтчелек реализмы — әдәбиятның үсешендә зур казаныш, реализмның әле генә телгә алынган бөек язучыларның исеме белән бәйләнгән этабы ул.

*ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕНӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘСӘРЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ*

**Миләүшә Маннурова**

# ИБРАҺИМ ГАЗИ— ПОРТРЕТ ОСТАСЫ

**Әдәбият һәм сәнгатьтә бер дә искерми торган темалар бар: дөнья сугышлары, крестьян кузгалышлары, давыллы революция көрәшләре... Шулар сәнгать әһелләрен һәрчак үзләренә тартып торган. Бу аңлашыла да. Халыкның зурлыгы, рухи көче һәм күркәм сыйфатлары нәкъ менә олы кузгалышлар вакытында аеруча тулы һәм калку чагыла. Давыллы чор каһарманнар тудыра, үзенчәлекле характерлы, колоритлы шәхесләр тәрбияли. Тарихның зур борылыш пунктларына тукталып, дөньякүләм әһәмияткә ия вакыйгалар фонында халык массаларының үтә каршылыклы һәм гыйбрәтле язмышын сурәтләүгә багышланган сәнгать әсәрләре: пьесалар, роман-повестьлар үзебезнең татар әдәбиятында да байтак. Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар»ы — әнә шундый әсәрләрнең берсе.**

**«Онытылмас еллар» повестеның әдәбиятыбыз тарихында тоткан урынын ачыклау, анда күтәрелгән тема-проблемаларның, аерым мәсьәләләрнең ничек чишелешен яктыртуны үз өстебезгә алырга җөрьәт итмибез. Әсәрдә гаҗәеп тормышчан һәм оста сурәтләнгән дистәләрчә образлар бар. Аларга да тукталмыйбыз. Болары хакында да азмы-күпме язылды инде. Безне оста художник каләме белән тудырылган әнә шул дистәләрчә образларның бары берсе — матрос Федюшкин кызыксындыра. Күп кешеле, күп проблемалы бу әсәрдә аның үз урыны, вакыйгалар агышында бары ул гына башкарырга тиешле эшләр, бары ул гына тартырга сәләтле авыр йөк бар...**

**Революция көрәшләре. Никадәр дәһшәтле, очына чыккысыз каршылыклы һәм катлаулы булган алар. «Онытылмас еллар» да изүче сыйныфларны юк итү, яшь Совет дәүләтенең эчке һәм тышкы дошманнарын җимерү өчен барган рәхимсез көрәш сурәтләнә. Шул ук вакытта анда большевистик аңлылык белән стихиячелек, революцион дисциплина белән анархизм башбаштаклыгы, ачык бер максаты булган пролетариатның оешканлыгы белән бунтарьлык ирегә арасында да көрәш бара. Монысы да җитди һәм принципиаль көрәш. Ибраһим Гази әсәрендә партия вәкилләренең бу өлкәдәге эшчәнлеге дә тулы һәм ышандырырлык яктыртылган. Башка күп төрле эшләр башкару белән бергә, большевик Якуплар массалар аңындагы стихиячелек күренешләрен җиңәргә, Федюшкиннарны да тәрбияләргә тиешләр әле. Шулай әсәргә анархист һәм бунтарь табигатьле матрос килеп керә. Әйтергә кирәк, хәтәр килеп керә һәм укучылар игътибарын шунда ук үзенә юнәлтә.**

**Таң атып килә. Ялангачланып калган көзге кырлар буйлап, каршыдагы зур урманга таба хәрби отряд хәрәкәт итә. Бу — Шәрифҗан отряды. Алар Т. шәһәрендәге ашлык амбарларын коткарып калырга баралар. Шул чак атын кушаяклатып урман ягыннан чабып килүче разведка башлыгы Гыйльметдин күренә. Төсләре агарган Гыйльметдин, сүзләрен йота-йота, вакыйганы сөйләп бирә. «Урманны тикшереп йөргәндә, разведка кораллы кешеләр өстенә барып чыккан. Гыйльметдиннең егетләре: «Сез кемнәр! Ташлагыз коралларыгызны!» — дип кычкырганнар. Тегеләрнең бер усал чырайлысы, ике бармагын авызына кабып, колак тондыргыч итеп сызгырып җибәргән. Ул да булмаган, ат атланган, винтовка таккан кешеләр боларны чорнап алган. Бер матрос кыяфәтлесе, авызын чалшайтып, ат өстендә килеш боларга бомба белән кизәнгән: «Кузгаласы булмагыз! Юкса бетерәм!» Гыйльметдин атына кинәт камчы орып, бөҗраны өзгән дә чыгып чапкан»[1].**

**Бусы — Гыйльметдин күргән, аның манарасыннан торып язылган Федюшкин. Бе-**

---

[1] И. Гази. Онытылмас еллар. Повесть. Казан. 1964 ел. 314—315 битләр. Алга таба барлык өзекләр шушы басма буенча китерелә.

раз арырак киткәч, әлеге сәер матрос белән без үзебез дә танышабыз һәм якыннан танышабыз. «Васильев, үзенең яңа танышына карап, елмаймас җиреннән елмаеп җибәрде. Матросның бөтен кыяфәте: бил каешына тезеп таккан кара түгәрәк лимонкалары, тезенә хәтле төшеп торган агач кобуралы маузеры, кара бушлат өстеннән күкрәгенә аркылы-торкылы урап куйган патронташлары, авызын бер якка кыйшайтыбрак, үзен олы сымак тотып сөйләшүе Васильевта әллә нинди сәер тойгы калдырды» [316 бит].

Игътибар итегез. Биредә һәр бизәк никадәр күп мәгънәле, һәр деталь никадәр тирән мәгънәле! Тышкы портреты ук образның эчке дөньясына ишарә ясый: аның башкалардан аерылып торган үзенчәлекле холыклы, рухи каршылыклы кеше булуы хакында сөйли. «Кулакларны, белякларны» калтыратып торучы, конторларны дөмбәсләргә дигәндә «бервакытта да отказ бирмәүче» матрос, бөтен өязгә атаклы Федюшкин менә шушы инде.

Дөрес, Гыйльметдин уйлаганча ук куркыныч түгел икән үзе. Күренеп тора: бу коралларын да ул бизәк, уенчык итеп кенә таккан. Образга карата үз мөнәсәбәтен ачыклый төшеп, автор үзе дә елмая: «Матрос, атын тезгененнән тотып, урам фотографлары чаршавындагы картинага охшабрак басып тора иде». Әмма ни генә булмасын, Федюшкинның куе, ачык буяулар ярдәмендә язылган рәсеме ифрат отышлы, тормышчан һәм җанлы чыккан. Аның бөтен кыяфәте: кыланышлары, киеме, йөз сызыкларына хәтле чорның социаль мөнәсәбәтләрен чагылдыра, шул заман кешеләренә хас зәвык-гадәтләрне гәүдәләндерә. Әйтик, шул ук баштанаяк корал тагып йөрү гадәте егерменче еллардагы күп партизаннарга хас күренеш булган.

Бер килеп кергәч, сәер кыяфәтле шушы матрос әсәрдә сурәтләнгән күп кенә күренешләрдә катнаша, дөресрәге, повестьтагы вакыйгаларның уртасыннан уза. Аз-азлап автор аның тормыш юлын сөйли һәм әледән-әле геройны үз характерын ачардай төрле хәлләргә куя, төрле кешеләр белән мөнәсәбәткә кертә тора. Ул кешеләрнең Федюшкинга мөнәсәбәтләре дә төрлечәрәк. Анатолий, Гыйльметдин кебек солдатлар аңа күбрәк кызыгып һәм сокланып карыйлар. Шул ук нәрсә отряд башлыгы Шәрифҗанда да сизелә кебек. Икенче берәүләр исә, матросның кыяфәте һәм кыланышларына карап, сәерсенеп калалар, гаҗәпләнәләр... Шулай да, шәһәргә Якуп килгәнче, матросның башта без күргән рәсеме дә, аңа карата мөнәсәбәт тә әллә ни үзгәрми диярлек. Ул, билендәге бомбаларын чыңгыл-чаңгыл китереп, бер рәвештәрәк йөри бирә.

Менә Якуп кайтып төшә. Һәм шул моменттан алып мәсьәлә шактый үзгәреп китә. «... Моряк, Якуп каршында туры басып, якорьле кара тасмасы җилфердәп торган безкозырькасына кулын тидереп алды да фамилиясен әйтте. Аның билендә тезелеп киткән бомбаларга гаҗәпләнебрәк карап торган Якуп тегенең фамилиясен аңламый калды. Әллә Девушкин, әллә Фитюлькин — Якуп отып кала алмады. Менә шушы «әллә Девушкин, әллә Фитюлькин» аның китаплар тутырган авыр капчыгын ансат кына күтәреп җилкәсенә салды да, алар пароходтан чыга башладылар. «Бу нинди әкәмәт кеше!» — дип уйлап барды Якуп, Федюшкинның халык алдында шулай бомбалар тагып йөрүен килештермәде... Шушы кыяфәт белән, җитмәсә тагы атка атланып, пароход каршыларга төшкән булуын белеп алгач, Якуп бөтенләй чыраен ук сытты» [382 бит].

Тышкы кыяфәтеннән тыш, Якупка матросның эчке сыйфатлары, кайбер фикер-карашлары да охшап бетми. Революциянең асылын, төп максатларын егет үзенчәрәк, берьяклырак аңлап калган икән бит.

Ревком кешеләре өчен сайланган йорт хакында сүз чыккач, «матрос Якуп белән һич килешә алмаганын белдерде.

— Без инде подвалларда күп яшәдек, — диде һәм, бүтәннәр бу йорттан күчкән хәлдә дә, үзенең күчмәячәген әйтте» [383 бит].

Шулай да, егетнең батырлыгын, революция эшенә чиксез бирелгәнлеген Якуп үзе дә хупламый булдыра алмый. «Йөрәкле кеше күренә, — дип, матрос турында уйлап алды, — яшьләргә хас кайбер чатлы-ботлы яклары бар икән, тормыш бик тиз шомартыр. Кайсыбызда юк инде андый гына кимчелекләр!» [387 бит].

Әмма матросның чатлы-ботлы яклары, Якуп уйлаганча, алай тиз генә шомармый. Дөрес, ул күп батырлыклар эшли, беркем кулыннан килмәстәй авыр эшләрне уңышлы башкарып чыга. Шул ук вакытта күпме хаталана, никадәр зыян китерә. Үз белдеге белән Сарлан кулакларын һәм мулланы тотып аткач, ниһаять, түземиләр: матросны ревком утырышына куеп кыздыралар һәм, Колчакка каршы китә торган батальонга командир итеп, фронтка озатырга мәҗбүр булалар...

Аның каравы, әсәрнең нәкъ шушы өлешләрендә Федюшкин бермә-бер ачылып китә, аның портретына яңа штрихлар, яңа буяулар өстәлә. Шулар безне образның рухи дөньясына алып керәләр, аның карашлары, теләк-омтылышлары белән таныштыралар. Образ өстендә эшләгәндә, автор мөмкин булган барлык чаралардан иркен файдалана. Федюшкинның сөйләме дә, гәүдә тотышы һәм хәрәкәтләре дә барысы бер максатка — тулы канлы, ышандырырлык образ тудыруга хезмәт итәләр. Язучы иң кирәкле, иң характерлы һәм күп мәгънәле детальләр табарга тырышкан. Бу — Ибраһим Газиның озын-озын аңлатмалардан коткарган, укучыларга исә матросның эчке табигатен аңларга, җанлы рәсемен күз алдына китерергә булышкан. Федюшкин образын ачардай яңа детальләр эзләү белән бергә, автор бер кулланган детальләрнең аеруча характерлыларын еш кына кабат-кабат файдалана. Түбәндәге мисалларга игътибар итегез:

«Шәрифҗанның нииндер соравына каршы матрос, баягыча, а в ы з к ы р ы е б е л ә н р ә к е л м а е п [күрәсең, аның табигый елмаюы шулайдыр] җавап бирде» [316 бит].

«— Как, син минем отрядыма ышанмыйсыңмы! — Ул тагын авыз кырыен кыйшайтып елмайды. — Минем дезиртирларымамы!» (318 бит).

«Бу Федюшкин иде. Ул, авыз кырыен ямьшәйтеп, елмайгандай итеп, Хәлимнең иңбашыннан каптырып тотты...» (447 бит).

«Авыз кырыен кыйшайтыбрак елмаеп, кискен адымнар белән бүлмәгә килеп керде дә аю тәпиедәй куллары белән Шәрифҗанны дусларча кочып алды» (579 бит).

Шундый ук мисалларны тагын бик күп китерергә мөмкин булыр иде. Кабатланып килүче әлегә детальләрнең функцияләрен, рольләрен аңлау өчен шушы кадәресе дә җитәр кебек. Мисаллардан күренгәнчә, кабатланучы детальләр ярдәмендә язучы образның аеруча характерлы, төп сыйфатларына басым ясый, шул сыйфатларын тагын да күпертеп, калкурак сурәтләп бирүгә ирешә. Шуның белән бергә, һәр очракта да диярлек, кабатланучы детальләр Федюшкин портретына күпмедер күләмдә яңа мәгънә төсмерләре өстиләр.

Күз — күңелнең көзгесе, дигәннәр бабайлар. Матросның күз карашларын, йөзен тасвирлау аша гына да, Ибраһим Гази образга күпме җан өрә, аны тирәнрәк ачуга ирешә.

«Матросның күңеленә бу бик хуш килде: менә сез дә Федюшкинсыз булдыра алмадыгыз дигәндәй, бик канәгать төс белән карап, Шәрифҗанның сүз башлаганын көтте» (318 бит).

«— Алаймы, браток! — Федюшкинның күз карашлары җитдиләнеп китте...» (Шунда ук).

«Матрос, кинәт кабынып китеп, күзләрен әйләндереп салды. Алай һәрбер контр өчен әрни торган булсалар, к чорту... нкмәкне үзләре тәятсеннәр, ә Федюшкинны авылга кулаклар белән сугышырга җибәрсеннәр» (393 бит).

«— Нәрсә син минем артта басып торасың! — дип, Федюшкин кинәт кенә борылып, Шәрифҗанга сәерсенеп карады» (559 бит).

«Кинәт аның авыр карашлы усал күзләре Шәрифҗанга төбәлде» (Шунда ук).

«Табынның ахырынарак Федюшкинның кашлары бераз языла башлады, чырае да яктырды, кыскасы, Якупка күптән таныш булган мактанчыграк, анархистрак авыл егете Федяга әйләнде дә калды» (752 бит).

Күрәсез, кешенең рухи халәте, җаны, күңеле турында күз карашлары күп нәрсә сөйли алалар икән. Вакытына, урынына карап, алар әле мыскыллы елмаялар, әле аптырап сәерсенеп карыйлар, я булмаса, очкыннар чәчеп, усал ялтырыйлар... һәм һәр очракта да күптәннән таныш матросны күз алдына бастыралар, һәр очракта да аның портретына ниндидер яңа буяулар өстиләр.

Әйткәнебезчә, Федюшкинның портреты үсештә бирелгән. Киемендәге, үз-үзен тотышындагы теге яки бу ягын калкурак сурәтләп, яки, киресенчә, томалабрак калдырып, автор матросның әле бер сыйфатына, әле икенче сыйфатына басым ясый, безнең игътибарны шуларга юнәлтә тора. Шул ук вакытта, Якуплар, Шәрифҗаннар тәэсирендә, зур кыенлыклар белән, әкренләп һәм аз-азлап булса да, матросның характеры төзәлә бара, тормышка карашлары да тирәнәя. Бу исә аның портретына да җитди үзгәрешләр кертә. «Продкомиссар Федюшкин уптәләгән балалар кыяфәтендә урта бер җиргә баскан. Аның бөтен торышы: «Революция каршында тамчы да гаебем юк, белмим, ни өчен мине болай хурлыйлардыр», — ди кебек иде» (571 бит).

Менә бу балалар кыяфәтендәге матрос белән повестьның баштагы өлешләрендә күренгән, «Кузгаласы булмагыз! Юкса бетерәм!» дип, бомба белән кизәнергә яратучы Федюшкин арасында билгеле, зур аерма бар. Егет, ничектер, өшәнебрәк калган, басынкыланган кебек.

Әсәрнең соңгы өлешләрендә образ, гомумән, тыйнаграк, гадирәк буяулар белән язылган. Язучы игътибарын, күбрәк, геройның эчке дөньясына юнәлтә. Федюшкин тормыш турында, яшәүнең мәгънәсе турында уйлана, үзен биләгән каршылыклы фикерләрнең очына чыгарга тели. Анархист партизан, бунтарь матрос җитди һәм сабыр холыклы дәүләт эшлеклесенә әйләнеп бара сыман. «Шинель чабулары ачылып киткән зур гәүдәле Федюшкинны бу көннәрдә әле мәгариф бүлегендә, кием-салым складында, әле пристаньда очратып була иде. Кайда үгетләп, кайда ялынып, кайда өстәлгә сугып, ул киемнәр таптырды, балаларны юлга чыгар алдыннан мунча чабындырды, юлга дарулар булдырды, пароход китертте» (789 бит).

Әмма ни генә булмасын, Федюшкин Федюшкин булып кала. Көрәшкә ашкынып атлыгып торган кайнар йөрәгә аз гына да сүрелми, сыйнфый дошманнарга булган чиксез нәфрәте бераз гына да кимеми. Матросның тәвәккәллеген, революция эшенә бирелгәнлеген күреп сокланмый калу мөмкин түгел. Әйтерсең, көрәш, канлы бәрелешләр аңа эчке бер канәгатьлек, ләззәт тойгысы бирә. Ул нэпманнарны тизрәк туздыру нияте белән яна, бандитларга каршы көрәшә. Һәм шул көрәштә батырларча һәлак була.

Ибраһим Газиның башка күп кенә образлары кебек ук, матрос Федюшкин да зур эмоциональ тәэсир көченә ия. Моннан тыш, бу образ тагын бер ягы белән игътибарга лаек. Федюшкин — рус халкы вәкиле, татар әдәбиятында уңышлы сурәтләнгән рус образларының берсе. Шушы бер образ аша язучы чорның, тарихның сулышын чагылдыра, бөтен бер халыкның милли үзенчәлеген гәүдәләндерә алган. Һәм моны кеше тормышының тышкы якларында, биографиясендәге аерым фактларда күрсәтү белән генә чикләнмәгән. Геройның фикерләү рәвешендә, хисләрендә, дөньяга карашындагы үзгәлекләрдә, тел төзелешендә бирә алган.

— — ◆ — —

# ЯХШЫ ҖЫР СИРӘК ТУА



Җырда уңышка ирешү бик авыр. Мин татар совет поэзиясендә ел саен өч-дүрт популяр җыр язган шагыйрьне хәтерләмим. Яхшы җыр бик сирәк туган. Шуңа күрә җырда сан артыннан куарга ярамый. Җырны мин берәмләп саныйм. Һ. Такташның «Урман кызы», М. Җәлилнең «Сагыну»ы, Ф. Кәримнең «Кемгә сөйлим»е, Ә. Фәйзинең «Умырзая»сы дип... Яхшы җырның урыны да зур. Ул синең кайбер поэмаларыңнан әйбәтрәк хезмәт итә, чөнки көн саен яңгырый, көн саен халык телендә, халык күңелендә.

Гөлшат Зәйнашева җыр өлкәсендә эшли, язган җырлары шактый күп. Ләкин баягы таләптән килгәндә, аның иң таралган җырлары дип «Туган җирем Татарстан», «Китмә, сандугач», «Кояш гомере», «Күл буена килсәң иде», «Зәңгәр төймә», «Замандашыма»ны күрсәтер идем мин. Гадәттә мин күңелдә калганнарны шулай чүплим. Бу аз түгел. Зәйнашеваның җырда үзен табып, үсә барган чагы. Ул, һичшиксез, матур җырлар бирәчәк.

Г. Зәйнашева җырларының халыкка ничек хезмәт итүен белү өчен берәр атна авылларда булу да җитә, авылларга чыга алмасаң, радиога колак салу да җитә...

Берәүләр әйбәт-әйбәт поэмалар биреп ташлый, берәүләр үзен җырда көчле сизә. Бу халыкка хезмәт итүнең формасы гына. Җыр жанрында актив һәм уңышлы эшләгән шагыйрьләрне мин Союзга член итеп алу ягында. Гөлшат Зәйнашева моңа бик хаклы.

Сибгат ХӘКИМ

# УЙЛАНА, ЭЗЛӘНӘ



Фәнис Яруллин — командировкаларга йөреп, «тормыш өйрәнү»дән мәхрүм. Әмма ул кайберәүләргә караганда тормышка якын. Күңеле белән якын ул. Үзе дә тормышның бер күзәнәге булып, аның шатлыкларын тоеп, кайгылары белән сызланып яши. Бала чактан сеңеп калган, илһам чыганагы булган авыл тормышына органик бәйле ул. Иҗаты көннән-көн ачыла бару, фикерләре тирәнәя, офыклары киңәя бару перспективасын мин шунда күрәм. Ул тормыш күренешләрен кычкырып торган декорациягә әйләндерми, реаль, тыйнак буяулар, җылы буяулар белән эш итә, тормышның үзе кебек гади, үзеннән аерылгысыз сурәтләр таба. Шигырьләрендә дә, хикәяләрендә дә моның матур үрнәкләре шактый. Санап чыгу кирәкмәстер, алар күз алдында.

Язучыны яшәткән, каләмен йөрткән, иҗатына көч биргән нәрсә — үз халкының язмышы белән бер булып яшәве, хезмәт итүе. Бу сыйфатлар Фәнис Яруллинда бар.

Шунысына сөенәм — Фәнис турында ташлама ясамыйча сөйләп була. Иҗаты шул дәрәҗәдә. Үзенең дә холкы әйбәт — ихлас күңелдән, күзгә туры карап, кимчелекләре турында да сөйләшеп була. Ул аларны искә ала, җиңә бара.

Рухи көче, тырышлыгы, эшчәнлеге белән Фәнис Яруллин күпләргә үрнәк була ала. Аны СССР Язучылар союзына член итеп алу бик вакытлы булыр дип, чын күңелдән тәкъдим итәм. Олы максатыбызга баглап хезмәт итик.

Шәүкәт ГАЛИЕВ

## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ



## Шәүкәт Галиев

### Бармак-карандаш

Кар ак кәгазь каплаган —
Бөтен җирне аклаган.
Күп итеп языйм әле,
Рәсемнәр ясыйм әле!
Карандашым булмаса,
Бармагым бар лабаса!
Кояш ясадым карга,
Ясадым мин йортлар да,
Яздым үз исемемне.
Ник туктадың, дисеңме?
Бармак-карандаш туңа,
Авызга каптым шуңа...

### «Керпе гөл»

Кына гөлем бар,
Яран гөлем бар.
Чәчәкләрен гел
Өзә Гыйлемдар.

Сындыра тагын
Песиләр йөреп,
Яфрагын чәйни
Бәрән үрелеп.

Бик күп кудым мин,
Куып туйдым мин,
Беркөнне кактус
Алып куйдым мин.

Күрәм — бәрәнем
Авызын сузды,
Теле чәнчелгәч
Тиз генә сызды.




Мыраулап качты
Песи дә килгәч —
Кабыргасына
Чәнечке тигәч!

Тотуы булды
Энем тармагын,

«Абау!» — диде дә
Капты бармагын.

— Яратмыйм монысын,
Керпе гөл! — диде.
...Гөлләр шәп үсә,
Файдасы тиде!



## Яңа мылтык

Яңа мылтык кулымда,
Йөрим ишек алдында.
Тизрәк сыныйсым килә,
Атып карыйсым килә.
Чү, сугыша ике әтәч!
Безнең әтәч җиңмәгәч,
Икесенә дә аттым,
Сугышудан туктаттым.

Усалланган күрәсең,
Мәчем куа күгәрчен.
Ачуыма түзмәдем,
Мәчегә дә төзәдем...
Мыраулап башын тотты,
Күгәрченне онытты.

Тавыклар да тик тормый —
Кыяр түтәлен тырмый.
Бәтиләр дә узынган —
Кәбестәгә сузылган.
Бакчага таба чаптым,
Чапкан уңайга аттым.
Таралдылар, туздылар,
Бар да чыгып сыздылар.
Ә үзем җиргә яттым,
Шалканнарга да аттым,
Суганнарга да аттым,
Кишерләргә дә аттым!

Мазмаем әлсерәгән,
Әлсерәп хәлсезләнгән.
Рәхәтләнсен бер, дидем,
Аңарга да тидердем.

Анда атам, монда атам,
Тәрәзәгә дә атам!
Нәрсә? Кем, минме ватам?
Мин бит су белән атам!

## Төрле тавышлар



Өстәл өстендә
Төрле тавыш бар,
Бар да танышлар.

Күкәйне кабам,
Ишетеп калам:
— Кыт-кыт-кытыйк! — ди.

Сөткә дә карыйм,
Тавышын таныйм:
— Му-му, му-му! — ди.

Менә — колбаса,
Тыңла булмаса:
— Мык-мык, мырык! — ди.

Икмәк алганда
Тургай сайравын
Ишетәм анда...

## «Кәбестәсе кайда?»



Кәбестә күргәч Әлифә
Әрчеде кабыкларын,
Һәм көтте ашый торганы
Уртасыннан чыкканын.

Сүтте, сүтте, эзләгәнен
Табалмады шулай да:
— Кабыклары катлы-катлы,
Ә кәбестәсе кайда?

## Тәмле чәчәк

Җәүһәр чәчәкне
Җиләк дип белә,
Чәйнәп карый да
Тизрәк төкерә.

Җиләкләр табып
Карый да кабып,
«Тәмле чәчәк!» дип,
Көлә кул чабып.





## Алма

Алмагачлар
Чәчәк ата,
Каравылчы
Йоклап ята.

Алмалары
Аунап ята,
Каравылчы
Мылтык ата!

## Кызык

*Палиндром* [1]

Әнә,
Әнә,
Кырык
Качак —
Кырык
Карак
Ача
Шалаш.

Ала
Ипи,
Ала
Кабак,
Ала
Калак,
Ала
Кадак.

— Тот!
Тот!
Әһә,
Әһә,
Кырык
Казак
Ала
Наган...

Кырык
Качак —
Кырык
Карак
Ала
Калак —
Ата
Кадак,
Ата
Кабак!

Ава!
Ава!
Кырык
Казак!..

---

[1] Уңнан да, сулдан да бертерле укыла торган шигырь.

# АТАКЛЫ КЕШЕЛӘР ТОРМЫШЫННАН ЧЫН ХИКӘЯЛӘР

## Үз җәтмәсенә эләгә

Британияне немец фашистларының бомбага тотуыннан коткарып калган радиолокация аппаратурасын уйлап табучы инглиз физигы Роберт Вэтсон-Уаттны, машинасын артык кызу йөрткәне өчен, көннәрдән бер көнне Канада шәһәрләренең берсендә тотып алалар һәм штраф түләтәләр. Бу фактның шунысы кызык: галимне үзе уйлап тапкан радиолокация ярдәмендә тоталар.

## Шигырь кичәсендә

Әле генә үз шигырьләрен укыган шагыйрьгә залда утыручылардан берәү:

— Маяковский! Сез үзегезне коллективист булган пролетар шагыйре дип санайсыз, ә шигырьләрегезнең күбесендә: «Мин дә мин!» — дип язасыз, — дип кычкыра.

— Сез ничек уйлыйсыз соң, Николай патша коллективист булганмы? Ул бит һәрвакыт: «Без, Николай икенче...» — дип язган бит, — ди шагыйрь.

— Әллә сез безнең барыбызны да идиот дип беләсезме? — дип тагын кычкыра теге егет.

— Юк, юк, ник алай булсын, — ди шагыйрь, гаҗәпләнгән булып. — Ни өчен барыгызны да? Мин әле бу залда андыйның берсен генә күрәм.

## Сернең бәясе

Американың атаклы киноактрисасы һәм эстрада җырчысы Дорис Дейны, мәхәббәтләрен тәкъдим итеп, телефоннан бик күп ирләр борчыйлар. Шуңа күрә ул телефон кампаниясеннән үз телефонының номерын үзгәртүне һәм аны сер итеп саклауны үтенә. Номер үзгәртелгәч, берничә көн үтүгә, телефоннан шалтырату тагын да ешая. Кампания маһирлары «серле» номерны, сиксән доллар акча түләтеп, бик күп ирләргә яшертен саткан булалар.

## Доллар күп илдә

Хемингуэй белән сөйләшеп утыручы берәү язучыны Америка Кушма Штатларында доллар чиксез күп, аны һәркем күпләп эшли ала дигән фикергә ышандырмакчы булган.

— Әйе, чыннан да шулай, Америка акчага бик бай ил. Ләкин ул һәркемнең икенче берәүгә тиеш булган бурыч акчасы, — дигән Хемингуэй.

## Хәреф хатасыннан үлгән

Германиядә бер кеше авыруына яраклы рецептны китаплардан эзләп табып, үзен-үзе дәвалый икән. Аны караган врач Маркус Герц шул хәлне белгәч:

— Үлемегезнең сәбәбен мин хәзер үк әйтә алам. Сез хәреф хатасыннан үләчәксез, — дигән.

## Үч алды

Атаклы физик Нильс Бор әле Геттингендә укыган чагында, коллоквиумга әзерлексез килеп, бик йомшак чыгыш ясый һәм, үзен аклар өчен, елмаеп кына болай ди икән:

— Мин биредә бик күп начар чыгышлар ишеттем. Мин сөйләгәннәрне шуңа үч итеп әйтелгән фикер дип белүегезне үтенәм.

## Трамвайда

Бик таркау хәтерле Чапек трамвайда тирән уйга чумып бара икән. Кондуктор аның билетын сорый. Чапек кесәсенә тыгыла һәм кондукторга сәгатен чыгарып күрсәтә. Кондуктор да сәгатькә шулай ук уйчан гына карап ала да, язучыга честь биреп, китеп бара.

## Метафизика нәрсә?

Немец химигы Отто Ганадан: «Метафизика турында сез ничек уйлыйсыз?» — дип сорыйлар.

— Метафизика бервакытта да мәче аяк басмаган караңгы бүлмәдән кара мәче эзләү ул, — ди галим көлеп.

## Вакыт юк

Профессор Эйнштейннан интервью алучы бер журналист мондый сорау бирә:

— Вакыт белән мәңгелек арасында, сезнеңчә, нинди аерма бар?

— Акыллым, — дип сөйләп китә Эйнштейн, киң күңелләнеп, — әгәр минем ул аерманы аңлатырлык вакытым булса, сез аны аңлаганчы мәңгелек үтәр иде.

## Сүздә тору-тормау

Джек Лондон бер нәшриятка вәгъдә иткән кулъязмасын вакытында җибәрми. Түземсез нәшир аңа: «Әгәр егерме дүрт сәгать эчендә новеллагыз килмәсә, мин үз кулым белән сезне сүзегездә торырга мәҗбүр итәчәкмен. Тагын шунысын да кисәтеп куям: мин вәгъдәмдә каты торачакмын», — дип, ачулы телеграмма суга.

Нәшриятка язучыдан мондый телеграмма килә:

«Сэр, әгәр кулларым белән генә эшләсәм, мин дә һәрвакыт үз вәгъдәмне үтәр идем».

## Алтын бугаз

Бервакыт Америкага гастрольгә килгәч, Шаляпин Нью-Йорк таможнясында тикшерү үтәргә тиеш була. Багаж тикшерүче чиновникка чират торганда кайберәүләр Шаляпинны танып алалар.

— Атаклы Шаляпин, алтын бугазлы кеше ул, — дип пышылдый кемдер.

Шуны ишеткәч, таможня чиновнигы «алтын бугаз»ны хәзер үк рентгенга төшерергә дигән әмер бирә.

## Аеруча тырышлык

Җырчы Энрико Карузо чек белән зур сумма акча алырга банкка керә. Караса, кесәсендә бернинди документы юк. Кассир акча бирүдән баш тарта. Карузо аптырап кала, ул шунда ук ниндидер карарга килергә тиеш була. Һәм... банкта кинәт «Тоска» операсыннан ария яңгырый башлый. Җырдан туктауга, Карузога тиешле сумма акчаны китереп бирәләр.

Чыгып барышлый ул:

— Гомеремдә дә менә хәзергедәй яхшы җырларга тырышканым булмаган иде, — ди.

## Судта

Вена судларының берсендә модалы җырлар язучы ике яшь композиторның эше карала. Боларның һәр икесе, «ул минем музыканы урлады» дип, бер-беренә гаеп тагалар. Үзе музыканы белмәгәнлектән, судья эксперт чакырырга тиеш була. Бу эшкә композитор Ференц Легар алына.

Композитор ике кулъязма белән дә танышкач, судья аңа сорау бирә:

— Я, эксперт әфәнде, кем кемнән урлаган? — ди.

— Икесе дә Жак Оффенбахны талаганнар! — ди Легар.

## Яшел төс

Одесса шәһәре башлыгы адмирал Зеленый бервакыт цирк буфетында утырган артист Анатолий Дуровны күрә дә аңа торып басарга куша. Башлыкның дуамал, җүләр бер кеше икәнен белгән Дуров бер дә исе китмичә генә карап ала, урыныннан кузгалмый. Шунда шәһәр башлыгы үзен озата килгән чиновникка:

— Минем Зеленый икәнлегемне белдерегез әле шул надангa! — дип әмер бирә.

— Мин яшелләр белән эш итмим, ә менә өлгереп җитсәгез карап карарбыз, — ди моңа каршы Дуров.

Кичен исә циркта ул манежга яшел төскә буялган дуңгыз алып чыга һәм тамашачылар аны зур алкышлар белән каршылыйлар.

## Эчке дөнья

Бервакыт Чехов, врач буларак, Александр Максимович Горькийны карый. Шуннан соң Горький аңа:

— Я, доктор, хәзер минем сездән бернинди яшерен серем юк, минем бөтен эчке дөньямны сез белеп бетердегез инде, — ди.

— Гомумән алганда, шулай... Типографиядә эшләүчеләр дә үзләре тышлаган китапның эчке дөньясын нәкъ шулай беләләр...— дип җавап бирә Антон Павлович.

## Чын сәбәпче

Бервакыт Бернард Шоу чамасыз симергән юан бер кеше белән очраша. Әлеге симез кеше чандыр драматургка карый да:

— Сезнең кыяфәтегезгә карап чамаласаң, хәзер Англия тәмам ачлыктан интегә икән дип уйларга мөмкин, — дип куя.

— Ә сезгә карап, бу бәланең сәбәпчесе бары тик сез генә дип уйларлык, — дип җавап бирә Шоу.

## Ул сезнеке

Бервакыт бөтенләй бер тиенсез калган инглиз язучысы Оскар Уайльд үзенә бик зур илтифат белән ишек ачкан швейцардан:

— Сез миңа егерме франк акча биреп тора аласызмы? — дип сорый.

— Мәгез! — дип кулын суза швейцар.

Уайльд аның кулын этәрә дә:

— Алыгыз. Мин аны сезгә бирәм, — ди.

## Ике төрле көч

Рус язучысы һәм журналист В. А. Гиляровский авылда торган этисенә кунакка кайта. Көч күрсәтергә теләп, ул кисәү агачы тимерен тота да төенләп бәйләп куя. Инде картаеп барган этисе монын өчен улына һич ачуланмый, төйнәлгән тимерне тиз генә чишә дә турайтып урынына куя.

## Хатка җавап

Немец физигы Конрад Рентгенга хат килә. Ниндидер бер галиҗәнап аңардан берничә рентген нуры җибәрүне һәм шуны куллану буенча аңлатма язуны үтенә, ә үзенең исә галим янына килергә вакыты юклыгын белдерә.

Галим аңа мондый җавап хаты язып җибәрә: «Хәзерге вакытта, кызганычка каршы, нурлар юк. Булган очракта да аны сезгә җибәрүе бик кыен һәм катлаулы икәнен әйтергә тиешмен. Бердәнбер чара шул — сез миңа гәүдәгезнең рентген белән яктыртып карыйсы өлешен җибәрергә тиешсез».

## Бик күп сүз

Анатоль Франска дуслары бер стенографистканы тәкъдим итәләр.

— Кеше сөйләгәнне бик тиз язасыз икән сез? — дип куана язучы.

— Әйе, мин минутына йөз утыз сүз язам...

— Бик күп ич бу, җан кисәгем, ул хәтле сүзне мин кайдан алыйм? — ди Франс.

## Минимум һәм максимум

Бервакыт Тимирязев үзенең ассистенты белән скверда йөри икән. Ассистент куакларның чәчәксез калуын күргән дә, үзенең фәнни терминологияне белүе белән мактанырга теләп:

— Сез ничек уйлыйсыз, профессор, бу туфракта нинди матдәләр минимум? — ди.

— Нәрсә минимум икәнен белмим. Әмма чәчәк урлаучылар биредә максимум булганнар, — дип елмая галим.

## Галим рәхмәте

Астроном Савич лекциясенә бай семьядан чыккан булдыксыз бер студент килеп керә. Егет өстенә җайдак киеме кигән, кулына камчы тоткан.

— Мин сезгә үземнең зур рәхмәтемне белдерәм, — дип мөрәҗәгать итә аңа кафедрадагы профессор.

— Ни өчен? — дип аптырый студент.

— Биргә атка атланып кермәвегез өчен, — ди галим.

## Ул чәй эчми

Петербургның бер бае оста скрипкачы Венявскийны чәйгә чакырган һәм бер уңайдан скрипкагызны да ала килегез, дип әйткән.

— Скрипкам исеменнән сезгә зур рәхмәт әйтәм, ләкин ул чәй эчми бит, — дип, Венявский чакырудан баш тарткан.

## Гаҗәпкә урын юк

Бер мәҗлестә табигать галиме Эрнест Геккель поп белән янәшә урынга эләгә. Аштан соң тәмәке тартканда поп та сигара кабызасын өчен галим аңа янган шырпы суза, ләкин поп кулына кучүгә ут сүнеп китә.

— Җәмәгать, күрәсезме, фән уты сүнде бит, — ди шул чак поп, көлеп.

Геккель әйе дигәндәй баш ия дә әйтә:

— Гаҗәпләнерлек урын юк. Дин сүндергән утларның беренчесе түгел инде бу, — ди.

## Яхшы вино

Гамбургның бер купецы вино сортларын да бик яхшы белгән композитор Брамсны үз базыннан чыгарган иң яхшы вино белән сыйлый:

— Бүтән винолар арасында моны Брамс виносы дип атарга мөмкин! — дип мактана ул.

Брамс, винонын тәмен татып карый да хуҗага:

— Әгәр баздан Бетховен виносын алырга җибәрсәгез, яхшырак булыр иде. — ди.

## Тоташ резина

Каучуктан күкерт ярдәмендә резина эшләү ысулын ачкан америкалы Гудьир бик фәкыйрь кеше була.

Аның эше белән кызыксынган бер промышленник Гудьирны ничек табарга дип сорый.

Белгечнең күршесе аңа:

— Урамда резин бүрекле, резин чалбарлы, резин пиджаклы, резин башмаклы һәм эчендә бер цент та акчасы булмаган резин янчыклы кеше күрсәгез, шул үзе Гудьир булыр, — дип җавап биргән.

## Иң яхшы чара

Чамасыз симергән бер фабрикант атаклы врач Боткиннан:

— Сез подагра авыруыннан берәр яхшы чара белмисезме? — дип сорый.

— Беләм, көн саен бер сумлык кына ризык ашап торырга, ул бер сумны да үзең эшләп табарга кирәк, — ди Боткин.

## Корал сайлау

Микробиолог Луи Пастерны бер граф дуэльгә чакыра.

— Алай булгач, мин корал сайларга тиешмен. Менә ике колба: аның берсендә — чәчәк чире микробы, берсендә — чиста су. Граф шуларның берсен эчсә, мин икенчесен йотарга әзермен, — ди галим.

Дуэль, әлбәттә, булмый кала.

## Кызганычка каршы...

Урта кул бер музыкант яңа әсәрен Ференц Листтан тикшертә һәм «җырыгызда матурлык та, яңалык та бар» дигән бәя ишетә.

— Димәк, хөрмәтле маэстро, талант бар, — димәкче була музыкант. Ләкин композитор, аны бүлдереп:

— Кызганычка каршы, матурыгыз яңа түгел, яңагыз матур түгел, — ди.

## Оста үтерү

Бер яшь егет үзен инде камил актер дип саный һәм атаклы трагик Рыбаковка «Отелло»ны уйнап күрсәткәч:

— Соңгы күренештә Дездемонаны оста үтердемме? — дип сорый.

— Оста, ләкин Отеллоны син аннан да остарак итеп беренче күренештә үк үтерәсең, — ди Рыбаков.

## Ышану

Кырым сугышы вакытында башы өзелгән бер солдатны лазаретка китерәләр. Докторлардан берәү аптырап кала:

— Моны нишләтергә соң, башы юк ич? — ди.

— Бер дә курыкмагыз, башын әнә арттан күтәреп килиләр, хирург Пирогов әфәнде аны, һичшиксез, ялгап бирәчәк, — диләр солдатлар.

## Тел белмәсәң...

Карт Дюма Германиядә җәяүләп сәяхәт иткән чагында бер авылга туктый һәм өй хуҗасыннан гөмбә ашы пешертмәкче була. Немецча белмәве сәбәпле ул моны әйтеп аңлата алмый һәм бер кәгазьгә зур гөмбә сурәте сызып, хуҗага күрсәтә. Бераздан хуҗа Дюмага... зонтик кертә.

## Ашыгыч эш

Виктор Гюгоның бик ашыгыч бер эше була. Шул эшеннән аерылырга туры килмәсен өчен ул чәчененең бары тик ярты өлешен кырка да сакалының ярты ягын кыра. Ә кайчы белән пәкене ачык тәрәзәдән урамга ташлый. Моның белән язучы үзен чәч һәм сакал үскәнче өйдә утырып эшләргә мәҗбүр итә. Аның ашыгыч эше тиешле вакытка тәмам була.

## Күңел йомшару

Бөек трагик Мочалов бер кибетчедән бурычка ит ала. Кибетче исә бер кичне театрга килә дә Мочаловның сәхнәдә искиткеч яхшы уйнавын күрә. Шул вакыт күңеле йомшарган итченең бөтен театр залын яңгыратып:

— Ит өчен араны өздек! Бер тиен дә акча алмыйм! — дип кычкырганы ишетелә.

## Мәкаль һәм җавап

Ирек яклап шигырьләр язганы, шуларны җәмәгатьчелеккә укып йөргәне өчен Пушкинны, билгеле булганча, көньякка сөрәләр. Киевтән узышлый аңа бер дусты очрый.

— Ничек монда килеп чыктың әле син? — дип сорый дусты.

— Тел Киевка җиткерә! — дип, Пушкин аңа русча мәкаль белән җавап бирә.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Нури Арсланов**

**АК ТАҢНАР**

*Бәясе 92 тиен*

Шагыйрь Нури Арслановның «Ак таңнар» исемле бу җыентыгына төрле елларда язылган иң яхшы шигырьләре, җырлары һәм легендалары урнаштырылган. Җыентык шагыйрь Сибгат Хәкимнең «Каләмдәш дус» исемле кереш сүзе белән ачыла. Ледерин тышлык белән чыгарылган бу китапта шагыйрьнең фоторәсеме дә бирелгән.




**Галимҗан Латыйп**

**АДЫМНАР**

*Бәясе 53 тиен*





Шагыйрь Галимҗан Латыйпның бу җыентыгында замандашларыбызның уй-хисләрен, омтылышларын чагылдырган шигырьләре басылган. Китапта шулай ук шагыйрьнең популяр җырлары да кертелгән һәм авторның фоторәсеме урнаштырылган.

**Равил Фәйзуллин**

**МОНОЛОГЛАР һӘМ ДИАЛОГЛАР**

*Бәясе 19 тиен*

Яшь шагыйрь Равил Фәйзуллинның бу яңа җыентыгына хезмәт кешеләренең монологлары һәм диалоглары тупланган. Бер-беренә бик тыгыз бәйләнгән бу шигъри әсәрләр хезмәт иясе халкының тормыш турындагы, тынычлык турындагы уй-хисләрен чагылдыруга багышланганнар.




**Рәшит Гәрәй**

**ТӨНГЕ УЧАКЛАР**

*Бәясе 23 тиен*

Шагыйрь Рәшит Гәрәйнең бу җыентыгында соңгы елларда язган иллеләп яңа шигыре басылган. Ул шигырьләрдә лирик геройның туган җиргә кайнар мәхәббәте, хезмәт кешеләренә тирән ихтирамы чагыла.

Җыентыкка кергән шигырьләр бер-берсенә органик рәвештә бәйләнгән «Туган-үскән җирләрем» һәм «Походларда-юлларда» дигән бүлекләрдән тора.




**Габдрахман Минский**

**ИКЕ ПЬЕСА**

*Бәясе 30 тиен*

Габдрахман Минскийның бу китабында «Гөлчәчәк» исемле биш пәрдәле комедиясе һәм «Аналар» исемле



өч пәрдәле драмасы басылган.

«Гөлчәчәк» сугышка кадәрге колхоз авылы кешеләре тормышын яктыртуга багышланган, ә «Аналар»да сүз ана һәм бала, совет кешесенең мораль сыйфатлары турында бара.

Китапка кертелгән һәр ике пьеса да үзешчән сәнгать түгәрәкләре өчен, һичшиксез, яхшы ярдәмлек булыр.

## БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧ

Шигырьләр

*Бәясе 1 сум 32 тиен*

«Беренче карлыгач» исемле бу җыентыкка ундүрт яшь шагыйрьнең әсәрләре




тупланган. Һәр шагыйрьнең шигырьләре үзенә аерым китапчык итеп басылган һәм ул китапчыкларның һәркайсына аерым исем бирелгән. Әмма ул китапчыкларны аерым-аерым сатып алу мөмкин түгел, чөнки алар ундүрте дә бер капка урнаштырылган һәм шул кабы белән бергә генә сатылалар. Җыентыкның авторлары: Е. Уткин, Г. Рәхим, Д. Сирай, М. Садыйков, Т. Камалиев, Ш. Маннапов, З. Шәйхулов, З. Шәйхетдинов, Н. Хисамов, Х. Хөснуллин, Р. Зәкиев, И. Фазлуллин, Ә. Гайнуллин, Ф. Шәфигуллин. Җыентыкка кергән һәр китапчыкта аның авторының рәсеме һәм биографик белешмәсе бирелгән.

## ХАЛЫК ӘЙТСӘ, ХАК ӘЙТЕР

Әкиятләр, мәзәкләр, такмаклар, бәетләр һәм мәкальләр җыентыгы

*Бәясе 43 тиен*

Буе бер аршин,
Ине өч аршин;
Үрдәк дисәң, суда йөзә алмый.
Кеше дисәң, аягын суза алмый.

Бу табышмакны без әле шушы көннәрдә генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Халык әйтсә, хак әйтер» исемле китаптан алдык. Татар халкының ислам дине турындагы әкиятләре, мәзәкләре, такмаклары, табышмаклары һәм бәетләре тупланган бу җыентык Ф. Ахметова, Х. Гатина һәм Ф. Урманчиевлар та-




рафыннан төзелгән. Китапның тышлыгын һәм иллюстрацияләрен художник Т. Хаҗиәхмәтов эшләгән.

Хәмит Ярми

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ПОЭТИК ИҖАТЫ

*Бәясе 86 тиен*

Татар халык иҗаты әсәрләрен туплау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә күп кенә эшләр башкарылган булса да, ул иҗатны фәнни-теоретик яктан өйрәнү, тикшерү эше бездә әле башлангыч хәлендә генә тора дияргә була. Халык иҗаты әсәрләрен фәнни классификацияләү, һәрбер жанрның тарихи үсеш һәм идея-эстетик үзенчәлекләрен билгеләү, язма әдәбият белән халык поэзиясенең үзара бәйләнеше һәм фольклористика тарихын төзү кебек проб-





лемалар — бүгенге көндә нык лап өйрәнүне таләп итә торган җитди проблемалар. Хәмит Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» исемле бу китабы фольклористика фәне алдында торган әнә шул бурычларны өйрәнә башлауга багышланган. Китапның беренче бүлегендә автор татар фольклорын туплау һәм өйрәнү тарихы турында сүз алып бара. Икенче бүлектә әкиятләрне, өченчесендә бәетләрне, дүртенчесендә мәкальләр һәм әйтемнәрне, бишенчесендә табышмакларны, алтынчысында җырларны тикшерә. Китапның соңгы бүлегендә совет чоры татар халык иҗаты тикшерелә.

ХУДОЖНИК С. КАРПЕНКО РӘСЕМНӘРЕ



Кокушкино. Үшнә елгасы.

Кокушкино. В. И. Ленин яшәгән йортның бер бүлмәсе.





Совет районындагы яңа кварталлар.



Ленин бакчасында.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДИПНЕҢ КУПТОМЛЫГЫН ЧЫГАРУГА ХӘЗЕРЛЕК

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советының киңәйтелгән утырышы булды. Анда татар әдәбиятының классик язучысы, күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның бай иҗат мирасын туплау һәм өйрәнү мәсьәләләре каралды. «Г. Ибраһимовның иҗат мирасын җыю һәм өйрәнүдәге актуаль бурычлар» дигән темага доклад белән институтның гыйльми совет члены, филология фәннәре кандидаты М. Х. Хәсәнов чыкты. Докладта һәм чыгышларда олы әдипнең әдәби иҗатын, фәнни эшчәнлеген һәм тормыш юлын өйрәнү мәсьәләләре турында, якын елларда аның сайланма әсәрләренең унтомлыгын хәзерләү һәм бастырып чыгару хакында сүз булды, бу юлда конкрет чаралар билгеләнде.

Гыйльми совет утырышында Татарстан язучылар союзы, Татарстан китап нәшрияты вәкилләре катнашты.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ФОТОКУРГӘЗМӘСЕ

Шушы елның февраль-март айларында Казандагы республика дәүләт музеенда Бөтендөнья фотокүргәзмәсе булды. Анда барлыгы житмеш илнең фото осталары тарафыннан эшләнгән меңнән артык фоторәсем куелган иде. Күргәзмәне республикабыз тамашачылары бик яратып карадылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Татарстан АССР Верховный Советының 1968 елның 23 февралендә игълан ителгән указы нигезендә, совет культурасын үстерүдәге һәм хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдәге хезмәтләре өчен Минзәлә балалар музыка мәктәбе укытучысы **Борис Иванович Быковка**, Саба районының Туктар авылы китапханәсе мөдире **Шәмсурый Ильяс кызы Габбасовага**, Азнакай районының Әлкәй авылы китапханәсе мөдире **Сәлимә Хажи кызы Зәкиҗановага**, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсенең абонемент мөдире **Ефтилия Ксенофонтовна Ипполитовага**, Казан төзүче инженерлар институты китапханәсе мөдире **Дора Семеновна Кашинага**, Казан авиация институты фәнни-техник китапханәсе директоры **Маргарита Ивановна Михайловага**, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең библиография бүлеге мөдире **Елизавета Михайловна Мишинага**, Минзәлә район китапханәсенең абонемент мөдире **Мария Яковлевна Русаковага**, Лениногорск шәһәренең беренче китапханәсе мөдире **Раиса Ивановна Самойловага**, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең бүлек мөдире **Елизавета Григорьевна Рыжковага**, Арча районының Әтнә халык театры артисткасы **Галимә Гайнетдин кызы Сибгатуллинага**, Алабуга культура-агарту училищесы укытучысы **Василий Алексеевич Теренинга** һәм Мамадыш районының Кече Кирмән авылы китапханәсе мөдире **Нурфига Мөхәммәтҗан кызы Хәсәновага «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Шагыйрь Зәки Нури Казан шәһәренең Бауман районы мәгариф йортында карт большевиклар һәм пенсионерлар җыелышында катнашып, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде.

* * *

Нәби Дәүли Минзәләдә үткәрелгән район интеллигенциясе слетында катнашты һәм үзенең яңа әсәрләрен укыды.

* * *

Шәүкәт Галиев, Сафа Сабиров һәм Сәрьян Хәсәнов Питрәч районының Әлбәдән авылы клубында колхозчылар белән һәм урта мәктәп укучылары белән очрашу үткәреп кайттылар.

* * *

Нури Арсланов Казан шәһәренең 35 урта мәктәбендә үзенең «Зоя» исемле поэмасы буенча үткәрелгән укучылар конференциясендә катнашты.

* * *

Казандагы танк училищесы курсантлары белән очрашып, Риза Ишморат һәм Валерий Синев хәрби темага багышланган әдәбият хакында әңгәмә үткәрделәр.

* * *

Идрис Туктар Зеленодольск шәһәрендәге культура сараенда китап укучылар алдында чыгыш ясады.

* * *

Сибгат Хәким һәм Шәүкәт Галиев В. И. Ульянов-Ленин исемендәге университетның студентлар тулай торагында студентлар белән очрашып, татар әдәбиятының бүгенге торышы хакында сөйләделәр һәм үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

* * *

31 январьда Татарстан дәүләт музеенда «Чаян» журналы укучылары белән очрашу булды. Журналның 45 еллыгына багышланган бу кичәдә шагыйрь Шәүкәт Галиев тә чыгыш ясады, үзенең юмористик шигырьләрен укыды.

* * *

Язучы Эдуард Касыймов Алабугада район һәм шәһәр милиция хезмәткәрләре белән очрашып, аларга бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде. Үз иҗатына кагылышлы күп кенә сорауларга җавап бирде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан язучылар союзы Әлмәт бүлегенең 30 январьдагы утырышы 1967 елның әдәби йомгакларына багышланды. Анда бүлекнең җаваплы секретаре Г. Ахунов доклад ясады. Ул узган елны язылган һәм басылып чыккан әсәрләргә бәя бирде, бүлек бюросының оештыру эшләренә тукталды. Фикер алышуда Азнакай әдәбият түгәрәге җитәкчесе М. Хәсәнов, Лениногорск әдәби берләшмәсе җитәкчесе Ш. Бикчурин, яшь язучылар А. Хәсәнов, Ж. Рәхимов, М. Хәбибуллин, К. Булатова һ. б. катнашты. Утырыш төп игътибарны язган әсәрләрнең сыйфатын күтәрүгә, әдәби осталык мәсьәләләренә юнәлтте.

* * *

Әлмәт культура университетының журналистлар факультетында Г. Ахунов очерк турында әңгәмә үткәрде. Ул очеркларның төре, сюжеты, проблема күтәрү, тел чаралары хакында сөйләде. Әңгәмә «Знамя труда» газетасында басылган очерк һәм парчаларга нигезләп алып барылды.

* * *

Ә. Маликов Әлмәт районының Колшәрип авылында кош-корт фабрикасы салучы төзүчеләр һәм колхозчылар белән очрашты, яңа әсәрләрен укыды.

* * *

Р. Төхфәтуллин Әлмәтнең «Россия» кинотеатрында укучылар белән очрашып, «Гүзәллек нәрсә ул?» дигән темага бәседә үткәрде.

* * *

Әлмәтнең агач эшкәртү комбинатында Г. Ахуновның «Хәзинә» романы буенча рус телендә укучылар конференциясе үткәрелде. Конференциягә автор үзе дә катнашты, укучыларның сорауларына җавап бирде һәм соңгы елларда татар әдәбиятының прешкән уңышлары турында сөйләде.

* * *

Әлмәтнең «Чайка» кафесында шәһәр һәм район буенча комсомол конференциясенә җыелган яшьләрнең «Зәңгәр ут» кичәсе үткәрелде. Кичәдә Г. Ахунов нефтьче һәм колхозчы яшьләрне язучылар союзы исеменнән котлады. Әлмәт шагыйре Дм. Матвеев Муса Җәлил шигырьләрен һәм үзенең яңа язган әсәрләрен укыды. Яшь композитор Мәсгут Имашев Әлмәт шагыйрьләренең текстларына язган яңа җырларын җырлады.

* * *

Лениногорск әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышы шәһәр һәм район укытучылары белән берлектә үткәрелде. Анда китап уку һәм татар әдәбияты турында зур сөйләшү булды.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

Шушы елның 12 февралендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган күренекле язучы Фәтхи Бурнашның тууына 70 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде. Язучының тормышы һәм иҗат юлы турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин ясады.

Соңыннан артистлар көче белән бик яхшы концерт бирелде.

## ХАЛЫК ЯРАТЫП ТЫҢЛАДЫ

Зариус Шахморзаева исеме безнең республикада һәм илдә генә түгел, чит илләрдә дә билгеле. Ул — халыкара конкурслар лауреаты. Бу оста скрипкачының концертлары һәр кайда көтеп алына һәм бик уңышлы уза.

Казанда туып үскән З. Шахморзаева хәзер Мәскәүдә яшәсә дә, туган ягыбызга шактый еш кайткалап йөри, Татарстан музыкантлары һәм композиторлары белән тыгыз иҗади элемтәдә тора. Аның концерт программаларында, классик композиторлар әсәрләре белән беррәттән, Татарстан композиторлары әсәрләре дә шактый зур урын ала. Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхин кебек күренекле композиторларыбызның әсәрләре З. Шахморзаева башкаруында дөнья гизәләр.

Якташларыбызның иҗатын илебез халыкларына ирештерү, музыкаль культураларның бер-берсен баету эшенә үзеннән лаеклы өлеш кертүче бу скрипкачы быел да Казанда булып, Казан дәүләт Консерваториясенең концерт залында бик яхшы концертлар биреп китте. Казан тамашачылары якташыбызның ул концертларын зур кызыксыну белән тыңладылар.

## М. ХӨСӘЕН ШИГЫРЬЛӘРЕ КАЗАКЪ ТЕЛЕНДӘ

Алма-Атадагы «Язучы» нәшрияты шагыйрь Мәхмүт Хөсәен шигырьләрен казакъ телендә аерым китап итеп бастырып чыгарды. «Мин синеке, далам» исемле ул китапта басылган шигырьләрне казакъчага Казагстанның күренекле шагыйрьләре Җобан Мулдагалиев, Гафу Кайырбеков, Мозафар Әлимбаев, Кайрат Җомгалиев, Җакан Сыздыковлар тәрҗемә иткән.

## ИҢ ЯХШЫ ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ӘСӘРЛӘРЕ ӨЧЕН ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫНЫҢ МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘРЕН БУЛДЫРУ ТУРЫНДА

Ленин комсомолының 50 еллыгы хөрмәтенә һәм яшь язучыларның, композиторларның, художникларның, актерларның совет яшьләре турында югары идеяле һәм художество эшләнешле әсәрләр тудыруда иҗат активлыкларын тагын да күтәрү максаты белән, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты бюросы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә яшь авторларның югары идеяле һәм художество эшләнешле әсәрләр иҗат иткәне өчен Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге һәркайсы 500 сумлык өч премиясен булдырырга. **ПРЕМИЯЛӘР ТҮБӘНДӘГЕЛӘР ӨЧЕН БИРЕЛӘ:**

— Матур әдәбият, тәнкыйть, публицистика һәм журналистика өлкәсендәге иң яхшы әсәрләр өчен;

— Музыка сәнгатендәге иң яхшы әсәрләр өчен;

— Иң яхшы башкару осталыгы (профессиональ һәм халык башкаруы) өчен;

— Иң яхшы кинофильмнар (профессиональ һәм һәвәскәр, нәфис һәм документаль, тулы һәм кыска метражлы) өчен, режиссерлык, операторлык һәм актерлык осталыгы өчен.

2. Премияләрне ел саен 29 октябрьда — Ленин комсомолы туган көндә тапшырырга.

Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләр комитеты төзелде һәм аның составына республиканың Культура министрлыгы, Язучылар союзы, иҗат оешмалары һәм учреждениеләре, күренекле сәнгать эшлеклеләре, республика яшьләр газеталары, радио һәм телевидение комитеты вәкилләре кертелде. Комитетның председателе — ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре **Р. Д. ФӘРХИЕВ.**

## ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫНЫҢ МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘРЕ ТУРЫНДА ПОЛОЖЕНИЕ

1. Муса Җәлил исемендәге премияләр югары идея һәм художество эшләнешле һәм яшьләргә коммунистик тәрбия бирүгә булышлык итүче, социалистик реализм принципларына җавап бирүче һәм республика яшьләре тарафыннан танылган әдәбият һәм сәнгать әсәрләре һәм иң яхшы башкару өчен бирелә.

2. Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә әсәрләрне һәм эшләрне ВЛКСМның район һәм шәһәр комитетлары, Татарстан АССР Культура министрлыгы, иҗади союзлар идарәләре, газета һәм журналлар редколлегияләре, Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитеты, Татарстан китап нәшрияты, югары һәм урта махсус уку йортлары, шулай ук җәмәгать оешмалары һәм комсомол җыелышлары тәкъдим итә.

Әсәрләр һәм эшләр республика премияләре комитетына һәр елның 1 сентябренә кадәр тапшырыла. Премияләр агымдагы елның 29 октябренда, Ленин комсомолы туган көндә бирелә.

3. Тикшерү өчен кабул ителгән әсәрләрнең һәм эшләрнең исемлеге, киң рәвештә тикшерү максаты белән, премия бирүгә ике ай кала матбугатта игълан ителә.

Әгәр тәкъдим ителә торган әсәрләре өчен авторга яки башкаручыга инде республика яки союз күләмендә премия бирелгән булса, мондый кандидатура Муса Җәлил исемендәге премиягә тәкъдим ителми.

5. Әсәрләр яки эшләр премиягә өч тапкырдан артык тәкъдим ителми, шуның белән бергә, кагыйдә буларак, премиянең кабат бирелмәве искә алынырга тиеш.

6. Муса Җәлил исемендәге премиягә әдәбият, тәнкыйть, публицистика һәм журналистика әсәрләре тәмамланган хәлендә, алар матбугатта игълан ителгәннән соң гына, ә рәсем сәнгате, музыка, кино һәм театр сәнгате әсәрләре алар белән күргәзмәләрдә, матбугатта, театрларда һәм кинотеатрларда киң рәвештә танышканнан соң гына тәкъдим ителә алалар.

7. Коллектив кандидатуралар тәкъдим ителгәндә аның составына үзләренең катнашы белән әсәрнең әһәмиятен һәм идея-художество кыйммәтен билгеләгән төп иҗат итүчеләрне генә кертергә мөмкин.

Муса Җәлил исемендәге премияне алучыларга «Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты» дигән исем бирелә, диплом һәм почет билгесе тапшырыла. Лауреатларның исемнәре ВЛКСМ өлкә комитетының Почет китабына кертелә.

Лауреат билгесе күкрәкнең уң ягына — СССР орденнары һәм медальләреннән өскәрәк тагыла. Комитетның премияләр бирү турындагы карары ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы утырышында раслана.

Муса Җәлил исемендәге премиягә әсәрләр һәм эшләр тәкъдим итү тәртибе белән ВЛКСМның район, шәһәр комитетларында танышырга мөмкин.

Комитетның адресы һәм белешмәләр алу өчен телефоннар түбәндәгечә: **КАЗАН ШӘҺӘРЕ, ИРЕК МӘЙДАНЫ, 2, ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫНЫҢ МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘР КОМИТЕТЫНА.**

Телефоннар: 9-05-27, 9-05-41.



«Кранчы кыз Гөлсинә»

Т. Хаҗнәхмәтов.

аясе 40 тиен
Цена коп.

жемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

# Казан утлары

**(ОГНИ КАЗАНИ)**

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210